МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РФ
КАЗАНСКИЙ (ПРИВОЛЖСКИЙ) ФЕДЕРАЛЬНЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
Институт филологии и межкультурной коммуникации
Кафедра татарской литературы и методики преподавания

Ч.М. КУРАКОВА

# ИСТОРИЯ ЛИТЕРАТУРЫ НАРОДОВ ВОСТОКА
# ШӘРЫК ХАЛЫКЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫ

**Полный конспект лекций**

**Лекцияләрнең тулы конспекты**

Казань-2014

Казан- 2014

**Направление:** 032700.62 - Филология. Прикладная филология (Татарский язык и литература, информационные технологии)

**Учебный план:** “Прикладная филология” (Татарский язык и литература, информационные технологии, очное, 2013)

**Дисциплина: Б.3 Б.4.2**“История литературы народов Востока”(“Шәрык халыклары әдәбияты тарихы”) (бакалавриат, 3 курс, 6 семестр; очное обучение)

**Количество часов:** Всего 72 ( в том числе: лекции – 16, практические занятия – 32, самостоятельная работа - 24; форма контроля: экзамен ( 6 семестр))

**Аннотация***: Дисциплина "История литературы народов Востока" входит в раздел "Б.3.Профессиональный цикл. Вариативная часть" ФГОС - по направлению подготовки ВПО О32 700 - "Филология".Основное внимание в курсе уделяется основным закономерностям развития восточных литератур, выявлению их региональных особенностей. В предлагаемых лекциях достаточно подробно рассматривается классический период, период Возрождения разных литератур Мусульманского Востока: арабской, персидской, азербайджанской, узбекской, тюрко-татарской. Изучаются наиболее известные произведения Мусульманского Востока, в частности крупных классиков Средневековья.*

*“История литературы народов Востока” – курс, призванный расширить представления и знания студентов о периоде Возрождения разных литератур Мусульманского Востока, их связей и диалогических отношений.Подготовленныйматериал можно изучать самостоятельно, выполняя предлагаемые задания и проводя самоконтроль усвоения материала.*

**Аңлатма язуы:** *“Шәрык халыклары әдәбияты тарихы”курсының төп игътибары Шәрык халыклары әдәбиятының үсеш закончалыкларын барлауга, аларның төп үзенчәлекләрен, асыл сыйфатларын өйрәнүгә юнәлдерелгән. Тәкъдим ителгән лекцияләрдә Мөселман Көнчыгышы әдәбиятларының, аерым алганда, гарәп, фарсы, азәрбәйҗан, үзбәк һәм төрки-татар әдәбиятларының Яңарыш чоры, Урта гасыр классикларының иҗаты, аларның дөньякүләм яңгыраш алган әсәрләре шактый тирән барлана. Әлеге курс студентларның Шәрык мөселман халыклары әдәбияты хакындагы күзаллауларын киңәйтү, белемнәрен арттыру максатына хезмәт итә. Тәкъдим ителгән мәгълүматлар, әдәбият исемлеге белән танышып, биремнәрне чишеп, сорауларга җавап табып, курсны мөстәкыйль үзләштерү мөмкинлеге дә карала.*

**Темы:**

1. Введение в курс. История литературы мусульманского Востока. Особенности, основные направления.
2. Арабская литература эпохи джахилии.

3. Арабо-мусульманская литература эпохи халифатов.
4. Персидская литература эпохи Возрождения. Классический период.
5. Суфийская литература: история, различные направления, философские основы, тарикаты, макамы, иерархия учителей, образная система.
6. Тюркские литературы в контексте средневековых литератур Востока.

**Темалар:**

1. Курска кереш. Мөселман Көнчыгышы әдәбиятлары тарихы. Шәрык халыклары әдәбиятының асыл сыйфатлары, төп юнәлешләре.
2. Җаһилият чоры гарәп әдәбияты.
3. Халифәлекләр эпохасында гарәп мөселман әдәбияты.
4. Яңарыш чоры фарсы әдәбияты. Классик период.
5. Суфыйчылык әдәбияты: тарихы, суфыйчылык әдәбиятындагы юнәлешләр, фәлсәфи нигезләре, мәкамнәр, баскычлар, укытучылар иерархиясе, образлар системасы.
6. Урта гасыр мөселман Көнчыгышы әдәбиятлары контекстында төрки әдәбиятлар.

**Ключевые слова**: Литература Востока, Восточный ренессанс, возрождение, духовно-нравственная литература, философия ислама, суфийская литература, антропоцентризм, гуманизм, земная любовь, платоническая любовь, интимная лирика, касыда, ода, газель.

**Ачкыч сүзләр:** Шәрык әдәбияты, Шәрык ренессансы, яңарыш әдәбияты, дини-әхлакый әдәбият, ислам фәлсәфәсе, суфыйчылык әдәбияты, антропоцентризм, гуманизм, җир мәхәббәте, илаһи мәхәббәт, күңел лирикасы, касыйдә, мәдхия, газәл.

**Дата начала эксплуатации**: 1 сентября 2014 года

**Автор-составитель**: Куракова Чулпан Маликовна, кандидат филологических наук, доцент кафедры татарской литературы и методики преподавания ИФиМК КФУ, email: chkurakova@mail.ru

**URL:** http://tulpar.kfu.ru/course/view.php?id=1990

## ЭЧТӘЛЕК

Тема №1. Мөселман Көнчыгышы әдәбиятлары тарихы. Шәрык халыклары әдәбиятының асыл сыйфатлары, төп юнәлешләре ............................................. 5

Тема №2. Җаһилият чоры гарәп әдәбияты..................................................... 11

Тема №3. Халифәлекләр эпохасында гарәп мөселман әдәбияты.................... 29

Тема №4. Яңарыш чоры фарсы әдәбияты. Классик период............................51

Тема №5. Суфыйчылык әдәбияты ...................................................................70

Тема №6. Урта гасыр мөселман Көнчыгышы әдәбиятлары контекстында төрки әдәбиятлар .........................................................................................................86

Курсның төп төшенчәләрен туплаган глоссарий............................................118

Курска кагылышлы гомуми информацион ресурслар……………………….131

Имтихан сораулары……………………………………………………………139

**Тема №1. Шәрык халыклары әдәбияты тарихына кереш**

**Аннотация.** Әлеге лекция Шәрык халыклары әдәбияты хакында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Шәрык халыклары әдәбиятындагы төп юнәлешләр, Шәрык ренессансының асыл сыйфатлары мәсьәләләре карала.

**Ачкыч сүзләр**: Шәрык ренессансы, яңарыш әдәбияты, дини-әхлакый әдәбият, суфыйчылык әдәбияты, антропоцентризм, гуманизм.

**Методик күрсәтмәләр:**

- Лекция өлешендә теманың төп мәсьәләләре карала, иң әһәмиятле моментларга басым ясала.
- Теманы тагын да яхшырак ачу максатыннан төп һәм өстәмә әдәбият, текстлар, интернет ресурслар тәкъдим ителә.
- Теманы үзләштерүне тикшерү максатыннан якынча сораулар урнаштырыла.
- Сорауларга телдән дә, язмача да җавап әзерләргә мөмкин.

**Түбәндәге интернет ресурслар тәкъдим ителә:**

1. Понятие “Ренессанс” и проблема Восточного ренессанса // Рзакулизаде С. Закономерности развития восточной философии XIII – XVI вв. (регион ислама) и проблема Запад-Восток, 1983. // http:// www.livelib.ru (“Сохраняем знания”)
2. Культура в эпоху восточного Ренессанса (IX – XIIвв., XVв.) // http:// www.allbest.ru
3. Конрад Н.И. Запад и Восток. Статьи, 1969. // http:// www.twirpx.com/file/ 626803
4. Рахманалиев Р. Империя тюрков. Великая цивилизация. Мусульманский ренессанс и тюрки // ttp:// www.historylib.org / 54 (“Историческая библиотека”)
5. http:// www.gramotey.com (“Электронная библиотека “Грамотей”)

6. http:// www.tyurk.ru (“Симург – библиотека классической тюркской поэзии”)

**Әдәбият:**

1. Ганиева Р.К. Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. - Казань: Изд-во КГУ, 1988. - 173 с.
2. Ганиева Р.К. Философско-эстетические основы тюркских литератур средневековья // Татарская литература: традиции, взаимосвязи.
3. Мец А. Мусульманский Ренессанс. – М.: Наука, Восточная литература, 1973.
4. Рахманалиев Р. Империя тюрков. Великая цивилизация. Мусульманский ренессанс и тюрки.
5. Рзакулизаде С. Понятие “Ренессанс” и проблема Восточного ренессанса // Закономерности развития восточной философии XIII – XVI вв. (регион ислама) и проблема Запад-Восток, 1983.

## Глоссарий

**Антропоцентризм**– үзәккә кешене кую, кешене олылау дигәнне аңлата. Ренессанс әдәбиятының үзәгенә һәрвакыт Кеше куела. Кешенең акылына, хисләренә мәдхия укыла. Кеше Аллаһ белән бер дәрәҗәгә күтәрелә.

**Гуманизм** – кешелеклелек дигәнне аңлата. Гуманистик әдәбият кеше кыйммәте, кешелекле мөнәсәбәт мәсьәләләрен үзәккә куя. Кешегә карата кешелекле мөнәсәбәт, кешенең төрле яклап үсешен, шәхес ирекен, кеше бәхетен, кеше кадерен иң югары кыйммәт итеп караучы тәгълимат. Шәрык ренессанс әдәбияты гуманистик принципларга корылган.

**Дини-әхлакый әдәбият** - Коръән фәлсәфәсенә нигезләнгән, Аллаһның барлыгын һәм берлеген танырга өйрәтүче, Аллаһка сәҗдә кылуны, кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, әдәп-әхлак, миһербанлыкка, шәфкатьлелеккә, гаделлеккә һәм башка изгелекләргә өндәүче әдәбият.

**Ренессанс чоры -** иҗтимагый тормыш, мәдәният һәм әдәбиятның югары үсеш алган дәвере.

**Суфыйчылык әдәбияты** - Аллаһка мәхәббәт тәрбияләү, аңа якынаерга, ахыр чиктә  аның белән бергә кушылырга омтылуны максат иткән, үзәгендә - илаһияткә омтылган камил кеше образы торган әдәбият.

**Шәрык ренессансы**  - гарәп дөньясында бөек Коръән тәгълиматы белән туган, башка мөселман динле халыклар арасында иҗтимагый тормыш, мәдәният һәм әдәбиятның югары  үсеш алган дәвере. Шәрык яңарыш әдәбиятыАллаһны да, кешене дә олылауга корылган, гуманистик мотивлар беренче планда тора.

**Өйрәнү өчен тәкъдим ителгән сораулар:**

1. Шәрык әдәбиятларындагы төп юнәлешләр.
2. Шәрык әдәбиятларындагы ренессанс - яңарыш хәрәкәте .
3. Яңарыш әдәбиятының асыл сыйфатлары.

**Курска кереш**

Шәрык халыклары әдәбияты, әлбәттә, бик киң төшенчә. Ләкин бу курсны укыганда без аны төрле яклап чикләү юлына басабыз. Бердән, мөселман Көнчыгышы халыкларының әдәбияты күздә тотылса, икенчедән, шушы әдәбиятларның да зур үсеш кичергән -  яңарыш чорын өйрәнүне максат итәбез. Шуңа нисбәтле курс Урта гасыр гарәп, фарсы, төрки әдәбиятларынбарлау юнәлешендә алып барыла.

Урта гасыр Шәрык мөселман әдәбиятлары – бөек әдәбиятлар. Алар дөнья әдәбиятына Имрелкайс, Әлмөтәнәбби, Әлмәгарри, Рудакый, Фирдәүси, Низами, Нәсими, Гомәр Хәйям, Сәгъди, Хафиз, Фөзули, Нәвои кебек олы әдипләр биргәннәр.

Урта гасыр шәрык мөселман әдәбияты, аларның төрле канатлары гуманистик фикерләрне яклаганнар. Үзләренең кешелекле эчтәлеге белән алар бүген дә безне җәлеп итә.

## 1. Шәрык әдәбиятларындагы төп юнәлешләр

Шәрык әдәбиятында төп өч юнәлеш яшәп килә:

1. Дини-әхлакый әдәбият.

Ул Коръән фәлсәфәсенә нигезләнгән, Аллаһның барлыгын һәм берлеген танырга өйрәтә, фәлсәфә фәнендә бу күренешне әт-тәүхид дип атыйлар. Бу фәлсәфә буенча кеше Аллага буйсынырга, сәҗдә кылырга тиеш. Җирдәге һәрнәрсә Аллаһы Тәгалә әмере белән эшләнә,ягъни ул - иҗатчы, кешелекне, галәмне барлыкка китерүче.

2. Суфыйчылык әдәбияты.

Төп максаты - Аллаһка мәхәббәт тәрбияләү, аңа якынаерга, ахыр чиктә аның белән бергә кушылырга омтылу. Кеше башта шәригатьне өйрәнеп, аннары тәрикатьнең төрле баскычларын үтеп, үзен камилләштерергә, илаһияткә якынаерга тиеш. Шәрык әдәбиятында суфыйчылык эстетикасы зур урын алып тора, аның үзәгендә - илаһияткә омтылган камил кеше образы.

3. Дөньяви эчтәлекле яңарыш әдәбияты (яңарыш – ренессанс).

Әлеге әдәбият Алланы да, кешене дә олылый. Яшәешкә карата һәр адымда гуманистик карашларны яклый.

Шушы өч юнәлешне Аллаһның барлыгын, берлеген тану фәлсәфәсе һәм гаделлек идеяләре берләштерә. Гаделлек ул - мөселман мәдәниятендәге төп кыйммәт. Шуңа күрә Урта гасыр шәрык әдәбиятларында, шулай ук төрки-татар әдәбиятында да гадел патша, гадел җәмгыять мәсьәләләренә зур әһәмият бирелә.

## 2. Шәрык әдәбиятларындагы ренессанс - яңарыш хәрәкәте

Ренессанс – иҗтимагый тормыш, мәдәният һәм әдәбиятның югары үсеш алган дәвере. Ул - бөтен дөнья өчен хас күренеш. Төрле илләр, төрле халыклар яңарыш баскычын төрле чор-дәвердә кичергәннәр.

Дөнья әдәбиятындагы ренессанс хәрәкәте академик Николай Конрад фикеренчә, VII гасырларда Ерак Көнчыгышта, Кытай территориясендә барлыкка килә. Бу чорда Кытайда мәдәният һәм әдәбият зур үсеш кичерә.

һәм моны нигезләүдә борынгы төркиләрнең дә өлеше күп. Аннан яңарыш әдәбияты Шәрыкның башка җирләренә тарала.

Шәркый ренессанс хәрәкәте Кытайдагы яңарыш белән бер чорда гарәп дөньясында бөек Коръән тәгълиматы белән туа. Коръәннең үзәгендә дә гуманистик мотивлар беренче планда тора.

Әт-тәүхид фәлсәфәсе буенча галәмдәге, җирдәге бар әйберләр Аллага сәҗдә кылалар. Шул ук вакытта, Коръәннең "Йосыф" сурәсендә ай, кояш, йолдызлар Йосыфка да – кешегә сәҗдә кылалар. Бу – кешене олылау дигән сүз.

Фарсы-таҗик әдәбиятында ренессанс күренеше соңрак, IX гасырда Рудакый исемле шагыйрь иҗаты белән башланып китә. Ә төрки дөньяда яңарышны Йосыф Баласагунлы һәм Мәхмүт Кашгарыйлар башлап җибәрәләр. "Котадгу белек" ("Бәхеткә илтүче юл"), ("Благодарность знаний") әсәре кешегә карата кешелекле мөнәсәбәт тәрбияләүгә багышланган. Ренессанс заманында телләр белү мәҗбүри саналган, халыкларның аралашу зарурлыгын истә тотып, М.Кашгарый "Төрки телләр сүзлеге"н төзеп тәкъдим итә.

Яңарыш әдәбияты Идел буе Болгарында Кол Гали иҗаты аша үзенең барлыгын белдереп тора ("Кыйссаи Йосыф"). Идел буенда ренессанс хәрәкәте Алтын Урда, Казан ханлыгы чорында зур таралыш ала. Алтын Урда дәвере - төрки-татар яңарышының иң уңдырышлы чоры, әдәби үсешне бу чорда Котб, С.Сараи, М.Болгари, Харәзмиләр тәэмин итсә, Казан ханлыгы чорында иң югары ноктасы - Мөхәммәдьяр иҗатында күзәтелә.

XIV-XV гасырларда төрки әдәбиятлардан үзбәк әдәбияты зур үсеш кичерә. Аларда Дурбәк һәм Алишер Нәвои кебек зур шагыйрьләр мәйданга чыга.

Азәрбәйҗан төрки яңарыш вәкилләре - Низами, Хакани, Нәсими (алар, нигездә, фарсы телендә иҗат итәләр). Фөзули – азәрбәйҗан ренессансын тәмамлаучы шагыйрь.

Фөзули, А.Нәвои, Мөхәммәдьяр - Урта гасыр төрки ренессансының иң көчле өч вәкиле. Алар беренче төрки яңарыш әдәбиятының кульминациясен тәшкил итүчеләр һәм ишекләрен ябучылар.

Ренессанс хәрәкәтен барлыкка китерүче төп шартлар:

1. Дәүләтчелек.
2. Шәһәрләр булу.
3. Сәнәгатьнең һәм һөнәрчелекнең алга китүе, авыл хуҗалыгы, эчке-тышкы сәүдәнең үсүе, мәдәният, мәгарифнең югары дәрәҗәдә булуы.

Озак еллар дәвамында рус,Европа галимнәре Шәрык халыкларында ренессанс  хәрәкәте булмаган дип киләләр. Ләкин Шәрык халыклары ул баскычны феодализм дәверендә үк үтүләрен исбат итәләр.

## 3 Яңарыш әдәбиятының асыл сыйфатлары

1. Үткәндәге уңай традицияләрне торгызу (возрождение).
2. Гуманизм.
3. Антропоцентризм – үзәккә кешене кую, кешене олылау.

**Телдән җавап бирү өчен сораулар:**

1. "Шәрык халыклары әдәбияты" курсының предметын һәм объектын билгеләгез.
2. "Ренессансәдәбияты"на бәяләмә бирегез.
3. Шәрык ренессансы хакында ниләр беләсез?
4. Шәрыкне өйрәнүчетатар галимнәрен атагыз.
5. Шәрык ренессансының фәлсәфи-эстетик нигезләрен аңлатыгыз.
6. Шәрык ренессансының асыл сыйфатларын санагыз.

**Тема №2. Җаһилият чоры гарәп әдәбияты**

**Аннотация.** Әлеге лекция исламгача булган гарәп әдәбияты хакында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Җаһилият чоры гарәп әдәбиятындагы төп юнәлешләр, әдәби хәрәкәт вәкилләренең иҗат мирасы, асыл сыйфатлары мәсьәләләре карала.

**Ачкыч сүзләр**: җаһилият чоры, "Әл-Мөгаллакат", мөгалләка, бәдәви, равий, риса, касыйдә, мәдхия, фәхр, васыф, Әл-Мөхәлхил Әш-Шанфара, Тәэббата Шарран, Имрелкайс.

**Методик күрсәтмәләр:**

- Лекция өлешендә теманың төп мәсьәләләре карала, иң әһәмиятле моментларга басым ясала.
- Теманы тагын да яхшырак ачу максатыннан төп һәм өстәмә әдәбият, текстлар, интернет ресурслар тәкъдим ителә.
- Теманы үзләштерүне тикшерү максатыннан якынча сораулар урнаштырыла.
- Сорауларга телдән дә, язмача да җавап әзерләргә мөмкин.

**Түбәндәге интернет ресурслар тәкъдим ителә:**

http://arabliterature.ru/

http://ru.wikipedia.org/ (Википедия.Свободная энциклопедия)

http://www.vostlit.info (Восточная литература.Средневековые исторические источники Востока и Запада)

Арабская культура // http://dic.academic.ru/dic.nsf/bse/64704/(БСЭ)

Доисламская Аравия : религиозный, культурный, политический фон // http://www.ahmerov.com/book_1126_chapter_3_DOISLAMSKAJA_ARAVIJA_religioznyjj,_kulturnyjj,_politicheskijjfon.html (Библиотека Инокентия Ахмерова).

Татьяна Касьянова (Novikovskaya) "Доисламская арабская поэзия" //http://www.litsovet.ru/index.php/material.read?material_id=266203

Шидфар Б.Я. Образная система арабской классической литературы (VI–XII вв. // http://www.orientalstudies.ru/eng/images/pdf/b_shidfar_2011.pdf

Словесное искусство древних арабов (VI — середина VII в.) // http://www.textologia.ru

Верования арабов доисламского периода // http://www.azerislam.com/?lngs=rus&cats=40&ids=427

Гибб Х.А.Р.Арабская литература // http://bookitut.ru/Arabskaya-literatura.html

Гумеров И.Г. История арабской литературы //http://tulpar.kpfu.ru/course/view.php?id=107

**Әдәбият:**

1. Авхадиева А.И. Арабская литература джахилийского (доисламского) периода: Учебное пособие. – Казань, 2001. – 36 с.
2. Аравийская старина: Из древней арабской поэзии и прозы. – М.: Наука, 1974.
3. аль-Фахури Х. История арабской литературы [пер. с араб.]. В 2 томах. Т. 1. – М.: Изд-во иностранной литературы, 1959.
4. Фильштинский И.М. История арабской литературы. V- начало X века. – М.: Либроком, 2010.

**Текстлар:**

Арабская поэзия средних веков. – М.: Худож. лит., 1975.

Аравийская старина: Из древней арабской поэзии и прозы. – М.: Наука, 1974.

Из классической арабской поэзии. Пер, с араб. С.В. Шервинского; Вступ. ст., примеч., подстрочный пер. И.М. Фильштинского. – М: Худож. лит., 1979.

**Глоссарий**

**Җаһилият чоры-** (җаһил – надан д. сүз, ягъни наданлык чоры). Гарәп дөньясындагы исламга кадәрге чорны – җаһилият чоры дип атау гадәткә кергән.

**Бәдәви** - Гарәбстан ярымутравының төньяк өлешендә яшәүче күчмә халык, бу урынчылыктагы чүлне - бадия (чүл), ә анда яшәүчеләрне əһле бәдәви (чүл кешеләре) дип атаганнар.

**“Әйям әл-гарәб” -** бәдәви кабиләләр көнкүрешеннән алынган вакыйгалар турында тарихи хикәятләр тупламы.

**Гасабийя** - үз кабиләңә нык бирелгәнлек, тугрылык.

**Равий** – нинди дә булса мәгълумат таратучы, телдән сөйләүче чичән кеше. Җаһилият чорының әдәби истәлекләре равийлар эшчәнлеге нәтиҗәсендә генә сакланып калган.

**“Әл-Мөгаллакат”- (нәзакәтле, шедевр мәгънәсен аңлата)** җаһилият чорының иң камил саналган, энҗегә тиң җиде касыйдәсен беләштергән антология.

**Рәҗәз -** гарәп шигыренең иң гади үлчәме, башка шигъри үлчәмнәргә нигез салучы.

**Ринд –** (бродяга ) – сукбай.

**Рисә –**элегия, мәрсия һәм 50-100 бәетне үз эченә алган касыйдәләр, исламгача чор гарәп поэзиясенең төп композицион формасы.

**Сәдҗ-** рифмалашкан проза, гарәп шигырь төзелешенең башлангыч формасы.

**Касыйдә-** мактауга һәм тасвирга корылган гарәп әдәбиятындагы иң борынгы һәм композициясе ягыннан иң катлаулы поэтик форма. Касыйдәләр

бер-берсе белән аз бәйләнештә торган берничә структур кисәктән, өлештән тора. Касыйдәнең аерым өлешләре бары жанр формалары гына булып торалар, бары Урта гасырларда гына мөстәкыйльлек алалар. Касыйдә нигезен бәетләр (икеюллыклар) тәшкил иткән. Аларның рифмалары а а, б а, в а... принцибы буенча төзелгән. Касыйдәләр, классик шигырь формасы буларак, гаруз вәзеннәренең берсенә нигезләнеп язылганнар.

**Фәхр -** фәхрия , үз-үзеңне мактау, исламгача чор касыйдәсенең төп өлешен тәшкил итә.

**Мәдхия** – панегирик жанр, гарәп касыйдәсенең төп жанр формасы.

**Нәсиб -** касыйдәнең лирик башлам өлеше.

**Васыф** – касыйдәнең лирик башламнан соңгы тасвирөлеше, икенче төрле әйткәндә, пейзаж лирикасы.

**Бәһария** – язгы чәчәкләрне мактауны максат иткән, касыйдәнең бер жанр формасы. Шәрыкта аны “яз җыры” дип тә йөрткәннәр.

**Өйрәнү өчен тәкъдим ителгән сораулар:**

1. Чорга сыйфатлама. Гарәпләрнең иҗтимагый тормышлары, мәдәниятләре, диннәре.
2. Җаһилият чоры әдәби истәлекләре, шигърият вәкилләре.
3. “Мөгалләка”лар һәм аларның авторлары.
4. Гарәп шигъриятенең композицион формалары, жанр төрләре.

Гарәп әдәбияты дөнья сүз сәнгатенең мөһим һәм үзенчәлекле бер өлешен тәшкил итә. Бу әдәбият үзенең тамырлары белән бик борынгы чорларга барып тоташа һәм үзеннән соңгы чор сүз сәнгатенә, мөселман халыклары әдәбияты үсешенә көчле йогынты ясый. Аның туган урыны – Гарәбстан ярымутравы.

## 1. Чорга сыйфатлама. Гарәпләрнең иҗтимагый тормышлары, мәдәниятләре, диннәре

**Гарәбстан ярымутравының физик-географик шартлары.** Гарәбстан ярымутравының күп өлешен дала һәм чүлләр алып тора. Территориаль яктан эссе пояска урнашкан һәм илнең климаты, тәбәнәк таулы калкулыклы җирләрне исәпләмәгәндә, яхшылардан түгел. Яңгырлар бик сирәк ява, елгалар юк.

Гарәп кабиләләренең бер төркеме инде күптән югалган, сакланып калганнары бүген дә яшәүләрен дәвам итәләр. Ад, самуд, тасм, җәдис кебек кабиләләр бөтенләй югалганнардан. Галимнәр әйтүенә караганда, аларның телләре безгә килеп җиткән гарәп әдәби теленнән бик нык аерылган.

Сакланып калган кабиләләр ике төркемне тәшкил итәләр: кахтан һәм аднан кабиләләре. Кахтан гарәпләре – төп гарәпләр һәм алар хәзерге гарәпләрнең бабалары санала. Кабилә башлыгы – Яаруб ибн Кахтан була. Аларны икенче төрле "көньяк гарәпләре" дип тә йөртәләр. Аднанлылар инде төрле кабиләләр катнашып барлыкка килгән, аларны соңрак "низар"лар дип йөртә башлаганнар.

**Гарәпләрнең иҗтимагый тормышлары.** Гарәпләр күчмә һәм утрак тормыш алып барганнар. Утрак тормышлылар ярымутрауның көньягын биләгәннәр, җир эшкәртеп, игенчелек һәм сәүдә белән шөгыльләнгәннәр. Тора бара һөнәрчелек үсә, төрле тукымалар, тире эшкәртергә өйрәнәләр, бизәнү әйберләре җитештереп, чит илләргә чыгара башлы йлар. Утрак гарәпләр шәһәрләр, крепостьлар, храмнар, сарайлар төзиләр. Көньякта химриятлар (525 елга кадәр), лахмидлар (Гыйрак, башкаласы – Хира) дәүләте булган (б.э. 3 гасырыннан мөселман яулап алуларына кадәр яши). Лахмидлар фарсы (иран) патшаларына хезмәт итәләр. Юлбашчылары:Ән-Ногман I (400-418) – Хаварнак һәм Садир сарайларын төзетә (Низаминың "Җиде гүзәл" поэмасында нәкъ шушы патша турында сүз бара), әл-Мунзир III (505-554),

Амр ибн Хинд (554-569) – Хира шәһәрен шагыйрьләр һәм язучылар шәһәренә әйләндерә.

Гарәбстан ярымутравының төньяк өлешен - бадия (чүл), ә анда яшәүчеләрне әһле бәдәви (чүл кешеләре) дип атаганнар. Бәдәвиләр күченеп йөргәнлектән, махсус йортлары булмаган, чатырларда яшәп, дөя асрау белән шөгыльләнгәннәр, ит, сөт, йон һәм тире алганнар, аларны кием-салымга, финикка алыштыра торган булганнар, һөнәрчелек белән игенчелекне күралмаганнар. Корылык булганлыктан, кайда яңгыр яуса, шул тирәгә күченергә тырышалар. Кырыс чүл шартлары бәдәвиләр тормышын үз кануннарына буйсындырган: кабиләләр көтүлекләр һәм су чыганаклары өчен канкойгыч сугышлар алып барганнар, уңайрак шартларда тормыш итү өчен көрәшкәннәр. Үз кабилә законнарына гына буйсынып, үз гаиләсеннән һәм кабилә башлыгыннан тыш бер властьны да танымаганнар. Һәр кабиләдәге бөтен мөһим мәсьәләләрне үз юлбашчысы гына чишә, кабилә әгъзалары бер-берсен бик нык саклыйлар, яклыйлар. Үз кабиләләренә нык бирелгәнлек-гасабийя дип атала. Ир кеше- гаилә башлыгы, власте чикләнмәгән, ләкин хатын-кыз аның белән тигез хокуклы.

**Бәдәвиләрнең диннәре һәм мәдәниятләре.** Чүл гарәпләренең мәдәниятләре бик түбән, алар уку, гыйлем алырлык, яисә дин турында уйларлык дәрәҗәдә булмыйлар. Шулай да аларның яшәү өчен көрәшерлек тупланган тәҗрибәләре, медицина, ветеринария өлкәсендә бераз белемнәре дә була. Ә көньяк бәдәвиләр һөнәрчелек, игенчелек, хәтта архитектураны да үзләштерәләр. Табигать күренешләрен яхшы аңлап, аларны үзләренә хезмәт иттергәннәр. Шулай ук география, астрономия, астрология юнәлешендә дә беркадәр гыйлем, тәҗрибә туплаганнар. Кешенең тән тиресе буенча характерын билгеләгәннәр, тышкы кыяфәтенә нигезләнеп кабиләсен аерганнар. Кошларга таш ыргытып, багу бакканнар, әгәр кош куркып уңга китсә – яхшы киләчәк көтелә, сулга китсә – бәхетсезлек.

Диннәренә килгәндә, Йемен, Ясрибта яшәүчеләр исламга кадәр яһүди динендә, гассанидлар, хира мунзиритлары – христианнар. Ләкин гарәпләрнең күпчелеге күпаллалык белән мавыкканнар, потларга табынганнар, баштарак ташка, агачларга, чишмәләргә табынганнар, аларны җанлы итеп күргәннәр, табигатькә, йолдызларга, иң көчле культ Айга булган. Болар беррәттән, гарәпләрнең тагын 3 Аллалары булган:

Манат – Мәккә халкы табынган, уңыш һәм бәхет Алласы;

Лат- Таифә халкы табынган;

Узза – көрәеш кабиләсе.

Аллаһның – иң бөек зат булуына беркем дә шикләнмәгән, галәмне яратуын, көчен, кодрәтен таныганнар, ул алардан бик ерак булганга, табигатьтәге башка көчләргә табынганнар. Ләкин дин бәдәвиләр өчен артык зур роль уйнамаган. Шунлыктан язма әдәбиятта да аларның тотемнары хакында мәгълумат табып булмый.

Бәдәвиләрне үз кочагына алган дала һәм чүлләр алар өчен крепость ролен үти, аларны баскынчылардан саклый, халыкта бәйсезлек, ирек сөючәнлек тәрбияли, беркем алдында да баш имәскә, бер законга да бәйле булмаска өйрәтә. Алар искиткеч чыдам, көчлеихтыярлы, кайгыларны җиңел кичерәләр, ләкин тормыш шартларын җиңеләйтү өчен көрәшергә уйламыйлар.

Бәдәви – кыю, кырыс, сугышчан холыклы, я ул үзе һөҗүм итә, я аңа һөҗүм итәләр. Ул туктаусыз ерткычлар, табигать көчләре һәм чит кабиләләр белән көрәшә. Төп таянычы- кылыч. Алар бик кунакчыл, үзләре турында мактау сүзе ишетергә яраталар, яхшы фикер калдырырга тырышалар. Иптәшенә бик ярдәмчел, аннан да шуны таләп итә. Качакларга, мосафирларга якты чырай күрсәтәләр, сыйлыйлар, кунарга калдыралар. Үз сүзләрендә нык торучан, горур табигатьле кешеләр. Ярдәм сорап килгән кешенең үтенечен

үтәр өчен хәтта сугышка да күтәрелергә мөмкин. Дошманыннан һәрвакыт үч ала, беркайчан да гафу итми.

Чүл бәдәвиләренең исламгача тормышы “Әйям әл-гарәб” (“Гарәпләрнең көннәре”) исеме астында җыйналган җыентыкта тәфсилле яктыртылган. “Әйям әл-гарәб” бәдәви кабиләләр көнкүрешеннән алынган вакыйгалар турында тарихи хикәятләр тупламын тәшкил итә. Һәр кабилә үзенең яшәешендәге вакыйгаларга игътибарлы булган: кабиләләр арасындагы кечкенә бәрелешләр һәм зур сугышлар, олы җиңүләр турында хәбәрләр тарихи хикәятләр рәвешендә формалашканнар һәм, телдән-телгә күчеп, соңрак чорларга кадәр килеп җиткәннәр. Бу хәбәрләрне икенче төрле бәдәви гарәпләрнең үз үткәннәрен тарихи күзаллавы дип тә атарга мөмкин.

## 2. Җаһилият чоры әдәби истәлекләре, шигърият вәкилләре

Исламга кадәрге чорны – җаһилият чоры дип атау гадәткә кергән (җаһил – надан д. сүз, ягъни наданлык чоры). Бу чордан безнең көннәргә килеп җиткән әдәби истәлекләр бик аз. Ул дәвер әсәрләренең килеп җиткәннәре дә равийлар- ягъни телдән сөйләүчеләр эшчәнлеге нәтиҗәсе. Көрәеш кабиләсендә шундый сөйләүчеләрнең махсус төркеме булган. Алар бик күп шигырьләр белгәннәр һәм халык арасында шуларны сөйләп йөргәннәр. Шундый танылган равийлардан Махрам ибн Нәүфәл, Хувайтаб ибн әл-Газзә исемнәре билгеле. Ә ислам чорында Хаммад – әр-Равийә (771), Әбу Амр Исхан – әш-Шәйбани (821), Әбу Саид әл-Хәсән әс-Суккари (885) кебек данлыклы равийлар яшәгән.

Исламга кадәрге чордан безгә килеп ирешкән ядкарләр:

1) “Әл-Мөгаллакат” – төзүчесе Хаммад – әр-Равийә, 7 мөгаллактан тора.
2) “Әл-мөфаддалият” – сайланма әсәрләр, 128 касыйдәдән тора. Төзүчесе- әл-Мөфаддал Әд-Дабби.
3) Әбу Таммамның “Батырлык китабы” - “Әл-хамаса”.

4) Әл-Бухтуриның исламга кадәрге шигырьләрдән җыйган өзекләре.
5) Әбу әл-Фәраҗ әл-Исфаһаниның “Җырлар китабы”.
6) Ибн Кутәйбәнең “Шигърият һәм шагыйрьләр” китабы.
7) Ибн әш-Шадҗари, әбу Зәйд әл-Корәеш төзегән шигырьләр җыентыгы.

Бу истәлекләрнең күбесе аднан телендә, көрәеш кабиләсе диалектында язылган. Чөнки равийлар, нигездә, шул телдә сөйләгәннәр. Ә шагыйрьләрнең күбесе Йеменнан чыккан, алар арасында көрәешләр аз була. Макталырга, дан алырга теләү нәтиҗәсендә күп кенә равийларга кабилә тарафыннан дөрес информация бирелми, алар соңрак чорда үзләре язган әсәрләрне бабаларыныкы дип тәкъдим итәргә яратканнар. Коръән тәгълиматына каршы барып, шәригать кысаларыннан читтәрәк яшәеш алып баруларын күрсәтмәскә тырышалар. Кайвакыт равийлар үз әсәрләрен дә геройлары теленнән сөйлиләр. Хәтта кайбер шагыйрьләрнең булганлыгы да шик астына алына.

Җаһилият чорының иң күренекле шагыйрьләре арасында Әл-Мөхәлхил, Әш-Шанфара, Тәэббата Шарраннар аерылып тора. Алар иҗаты хакында берничә сүз.

**Әл-Мөхәлхил**– Адий ибн Рабига. Мөхәлхил- нәзек, нәзакәтле мәгънәсен бирә. Ул таглиб кабиләсеннән. Шагыйрьләр патшасы – Имрелкайсның абыйсы. Аның исеме гарәп дөньясында популяр, тарихи фактка нигезләнгән “Басуса дөясе өчен сугыш” әсәре белән бәйле.

Әл-Мөхәлхилнең 440 елда туган Ваил исемле Кулейб кушаматлы абыйсы була. Ул бәкер һәм таглиб кабиләләренең гаскәр башында торган. Тора – бара ул артык масаючан, тәкәббергә әйләнә, кабилә законнарын хөрмәт итми башлый. Ул утырып торганда, аның янынннан берәүгә дә үтеп китәргә, аның дөясе янында башкаларныкына утлап йөрергә ярамаган. Җәмилә исемле бәкер кабиләсе кызына өйләнә. Кызның 10 энесе була, төпчеге- Джасас. Тамим кабиләсендә аларның Басуса исемле апалары

яшәгән. Ерак булмаганлыктан, ул бик еш кына Джасаска кунакка йөргән. Үзе беләнбәләкәй дөячекле Сараб исемле дөясен дә ияртеп килештергән. Шулай бервакыт хатыны Кулейбка энесе Джасас белән мактана. Ачуы чыккан ир өйдән чыгып барганда, әлеге дөяне күреп ала да, аңа уктан ата. Хезмәтчеләренә өстәп җилеменә атарга боера. Дөя яралангач, озак кын чабулап йөри дә, егылып җан бирә. Кайгысыннан елаган апасына Джасас яхшырак дөя бирәм, дип тынычландыра. Ә Басуса мин 10 дөягә дә алыштырмас идем Сарабны дип, ризалашмый. Алайса мин иң яхшы дөяне атам дип, Джасас Кулейбның үзен үтерә.

Мөхәлхил абыйсы өчен үч алу максаты белән көрәшкә күтәрелә һәм ике кабилә арасында 40 елга сузылган дошманлык урнаша. 6 көчле сугыш була, гаскәр белән Мөхәлхил үзе идарә итә, 4 тапкыр җиңелә, икесендә өстен чыга. Ул махсус сугышчысын җибәреп Джасасны үтерттерә, моның өчен кулга алына, пленда вакытта 531 елда вафат була. Ике кабиләне Хира дәүләте җитәкчесе – Гомәр ибн Хинд дуслаштыра.

Мөхәлхилнең безнең көннәргә сакланып калган әсәрләре “Әл-хамаса”, “Җырлар китабы”нда урын алган. Шигырьләрендә абыйсы өчен үч алырга чакырган юллар, көрәшне тасвирлаган моментлар, дошманнарына үтергеч үч яңгырый. Аның поэзиясе кайгы белән сугарылган. Үз эчендә төп ике юнәлешне алып тора: 1) көчлелек, кыюлык, үз кабиләсе белән мактану, горурлану; 2) нечкәлек- нечкә күңеллелек, нәзакәтлек.

Шигырьләре бик эмоциональ, хисле, музыкаль аһәңгә ия. Әсәрләре аның эчкерсез, чиста күңелен ачып бирә. Ул һәрдаим абыйсын мактый, аның тиңсезлеген сөйли, аның элеменә аклану таба алмый. Гел абыйсына мөрәҗәгать итә, бик күп арттыру алымнары куллана.

**Әш-Шанфара** -– Сабит бин әл-Аус әл-Аздий. Туган елы һәм урыны билгеле түгел. Ул үз кабиләсендә тәрбияләнә, ләкин бик күп җәберләр, кимсетүләр күрә һәм ул туган җирләрен ташлап китеп, танылган зимагурга

әйләнә, урлаша, төрле сугышлар оештырып йөри. Бер урында озак тормый, яшәү урынын бик еш алыштырыла. Хатын-кызлар, балалар, хәтта ирләр дә аннан бик шүрләгәннәр. Эзәрлекләүләрдән качып, далаларда, тау куышларында яшәгән.

Риваятьләргә караганда, Шанфара сәлмән кабиләсеннән 100 кешене үтерәчәкмен, дип сүз бирә. Ләкин 99ына җиткәч, аның үзен үтерәләр. Әш-Шанфараның мәетен яныннан үтеп барган бер сәлмәнле, ачуы килеп, аңа китереп тибә. Ул кешенең аягына сөяк кереп, 100 нче кеше шул рәвешле җан бирә.

Шанфара үзеннән соң фәхр, хамаса жанрында язылган күп кенә шигырьләр калдырган, аларда ул үзенең батырлыкларын, көчен мактаган. Тавил үлчәмендә язылган 68 бәеттән торган “Ләмиятүл-араб” исемле касыйдәсе игътибарга лаек. Ул инглиз, немец, француз телләренә тәрҗемә ителгән.

Касыйдәсендә үзенең кабиләсен сүгә, ялгызлыгын тасвирлый, дуслары-кыргый җәнлекләр турында яза, шәхси батырлыклары, каһарманлыкларын бәян итә. Һәртөрле тормыш авырлыкларын үз җилкәсендә татыган, типкәләнгән шагыйрь җәнлекләрнең барлык җан ияләреннән дә акыллырак, миһербанлырак булуы хакында нәтиҗәләр ясый, аларны иң камил затлар саный. Ләкин һәрвакыт барыннан да өстенрәк итеп үз шәхесен куя. Ул бернигә дә мохтаҗ түгел, җир аңа түшәк тә, юрган да, ә барлык кирәк нәрсәне аңа куркусыз йөрәге, йомшак угы һәм авыр кылычы табып бирә.

Шанфара ачлыкны да бик горур кичерә, кешедән хәер алганчы, җир ашавың яхшырак дигән карашта тора. Беркайчан да хәер сорашмый, кызганганны яратмый, гайбәт сөйләүне- күралмый. Тышкы яктан тупас, кырыс күренсә дә, эчке табигате белән гаять хисчән, нечкә күңелле зат.

Әсәрләре аша бәдәвиләр тормышын, исламга кадәрге чорны күзалдына бастыра. Архаизмнар белән чуарланган булса да, шигырьләре сәнгати югарылыкка ия.

**Тәэббата Шарран** - Сабит ибн Җабир. 6 нчы гасырда яши, әш-Шанфара кебек үк сукбай шагыйрь. Ул да талаган, һөҗүм иткән, ләкин һичкайчан бәдәвиләр законы кысаларыннан чыкмаган. Бары үз кабиләсе дошманнарына гына һөҗүм иткән, үче булганнарны гына үтергән.

Тәхәллүс алу вакыйгасы хакында ике версия яши. Беречесенә караганда, имеш ул култык астына кыстырып сарык алып кайтып килгәндә, иптәшләре моны күреп: "ул култык астында усаллык, явызлык йөртә "Тәэббата шарран" дип сөрән салганнар. Шушы вакыйгага бәйле язылган әсәре әл-Исфаһаниның "Җырлар китабы"нда урын алган. Биредә ул үзен бик нык мактый, чама хисен дә оныта. Имеш, ул бары дошманнарның канын түгү турында гына уйлый, аның алдында барысы да баш ия, калтырап тора, аның аркасы бөтен кабиләсен сыендырып, дошманнардан саклый, дошманнарын "ник каршы чыктым" дип үкенер дәрәҗәгә җиткергәч, турап ташлый. Аны барлык хайваннар, җәнлекләр дә хөрмәт итә, һ.б.Икенче версия тәхәллүсне һәрвакыт култык астында кылыч йөртүенә бәйле дип билгели.

Горур сугышчы- шагыйрь мәдхияләр дә яза. Ләкин аның мактау шигырьләре киләчәктә мәйданга чыгачак сарай мәдхиячеләренекеннән аерылып тора. Үзен сурәтләү объекты белән һәрвакыт тигез куя һәм, беренче чиратта, аны кеше буларак түгел, ә үз кабиләсенең данлыклы көрәшчесе төсендә югары күтәрә.

### 3. "Мөгалләка"лар һәм аларның авторлары

Урта гасыр филологлар һәм комментаторлары җаһилият чорының күпсанлы әсәрләре арасыннан җиде касыйдәне, шедевр дәрәҗәсенә күтәреп, аерып куялар. Энҗегә тиң бу әсәрләрне "Мөгалләка" термины белән атыйлар. Легендаларга караганда, бу әсәрләрнең авторларын ел саен үткәрелә торган

Указ ярминкәләрендә хөрмәтли, ә әсәрләрнең текстларын дөя тиреләренә язып, иң кадерле урыннарга, храмнарга элә торган булганнар. Авторлары-исламгача чорның танылган бәдәви шагыйрьләре- Имрелкайс, Гантара, Ләбид, Зөхәйр, Тарафа, әл-Харис ибн Хиллиз, Амр ибн Кульсум. "Әл-Мөгалләкат"ны – төзүче Хаммад – әр-Равийә.

Борынгы гарәп поэзиясе бу чорда әле "индивидуаль стиль" төшенчәсеннән бик ерак тора, әсәрләр тел, тема, композициясе нисбәтеннән бер-берсеннән әллә ни аерылмый. Шулай да һәр мөгалләка авторының үзенчәлекле талантын ачык күрсәтә. Мисалга Тарафа һәм Гантара иҗатында героик мотивлар өстенлек алса, Зөхәйркүбрәк дидактик юнәлешне үз күрә.Әл-Харис ибн Хиллиз, Амр ибн Кульсум хикәяләү, эпик башлангычка мөрәҗәгать, Имрелкайс белән Гантарада мәхәббәт җырлары, Имрелкайс һәм Ләбид иҗатлары тасвир – пейзаж лирикасына маһирлыклары белән аерылып тора. Шул ук вакытта Ләбид бер генә гарәп шагыйрендә дә очрамаган – аучылык лирикасын башлап җибәрә.

"Мөгалләка" авторларының иң танылганнары – Имрелкайс, Гантара, Тарафа. Алар иҗаты хакында кыскача белешмә.

**Имрелкайс** – "шагыйрьләр атасы" санала.500 нче елда Нәҗдә туа, гаиләсендә, туганнары арасында дөньяның бар тәмен, рәхәтен тоеп, бик бәхетле тормышта яши. Шигырь язуга сәләте кечкенәдән үк үзен сиздерә. Аларда үз тормышындагы уенлы- җырлы кичәләр, күңел ачулар, маҗаралы вакыйгалар турында яза. Арада аның югары даирәсенә туры килми, килешми торганнары да очрый. Әтисе андыйлардан баш тартырга чакыра, ризалашмагач, улын өйдән куып чыгара. Далага чыгып китә, анда үзе кебек куылганнар белән аралаша, ауга йөри, шигырьләр яза, җырлы-уенлы кичәләр оештыра.

Имрелкайс әсәрләренең күпчелеге сакланмаган. Кечерәк шигырьләрен исәпкә алмаганда, 25 касыйдәне берләштергән "Диван"ы гына мәгълүм. Ул латин, немец телләренә тәрҗемә ителгән. Шулай ук ул "Мөгалләка" авторы буларак та билгеле.

Аның “Мөгалләка”сы тавил размерындагы 80 бәеттән гыйбарәт, аңа бик күп санда шәрехләр дә язылганлыгы билгеле. Язылу сәбәбе мәхәббәт белән бәйле дип санала. Имрелкайс Шурахбил исемле абыйсының кызы Унейзаны ярата, шушы кыз һәм аның иптәше хөрмәтенә үзенең иң кадерле дөясен дә суя, шушы очрашу хөрмәтенә касыйдә языла. Иэ элек шушы хәлләр бәян ителә. Аннары этисенең үлеменә кадәрге үз тормышы сурәтләнә. Касыйдә Унейзага мәхәббәт хисләрен, ауга йөрү картиналарын, илдән-илгә сәяхәтен күзалдына бастыра.

Имрелкайс мөгаллакасы бик яратып кабул ителә, аны камиллекнең һәм матурлыкның могҗизасы кебек югары күтәрәләр.

**Гантара** - Антара ибн Шаддад ибн Амр ибн Мугавия әл-Әбси, 525 — 615) әбсит кабиләсе башлыгы гаиләсендә туган исламгача чорның иң көчле һәм танылган шагыйрьләренең берсе. Көчле рухлы, нык ихтыярлы, сугыш уеннарында чыныгып үскән бу егет гомерен хәрби хезмәткә багышлый. Үз кабиләсенең данын яклап бик күп орышларда катнаша, аларны үзенең әсәрләрендә бик купшы гәүдәләндерүгә ирешә. Курку белмәс йөрәге, батырлыгы, фидакарьлеге аңа сөйгәне Әбланың мәхәббәтен яуларга юл ача. Мөгалләкаларындагы мәхәббәт темасы шушы кызга сөю хисләрен җырлау белән бәйле килеп керә һәм иҗатының иң күп өлешен алып тора.

**Тарафа** —Тарафа ибн әл-Габд ибн Суфьян ибн Мәлик әл-Бәкри – бәкер кабиләсеннән чыккан VI йөз уртасында яшәгән күренекле шагыйрь, иң көчле касыйдәләре белән “Мөгалләкат”тан урын алган иҗатчы. Гарәп шигърияте кануннары нигезендә иҗат итсә дә, героик мотивларга мөрәҗәгать итүе, сукбайлар, тибәрелгән кешеләр тормышын бөтен нечкәлекләре белән сурәтләве, төрле күңел ачулар, мәҗлесләрне тасвирлауга өстенлек бирүе аны башка каләмдәшләреннән аерып куя. Еш кына үзе алып барган тәртипсез тормыш һәм бу юлга төшергән хәлләр турында да акланган юллар да очрый. Ул – бик күзәтүчән характерлы һәм оста тасвирчы. Мөгалләкаларының күбесендә җитез, дәртле һәм бик тә якын, кадерле дөяне тасвирлаулар күзгә

ташлана, күп кенә галимнәр аның бу осталыгын югары бәялиләр һәм бу өзекләрне хрестоматия битләренә урнаштыралар.

**4. Гарәп шигъриятенең композицион формалары, жанр төрләре**

Гарәп әдәбиятында лирик жанрларга нигез булган шигырь төзелеше исламга кадәрге чорда ук формалаша. Башта рифмалашкан проза – ***сәдж*** барлыкка килә. Болар кабиләсенә куркыныч янаганда яисә кемнеңдер үлемен ишетеп, көчле рухи каршылыклардан, дулкынланулардан туган бәдәвиләрнең өндәмәләре рәвешендә була.

Рифмалашкан прозадан гарәп шигыренең иң гади үлчәме – ***рәджәз*** туа һәм ул башка шигъри үлчәмнәргә нигез салучы булып тора.

Исламга кадәрге чорда гарәп поэзиясенең ике төп композицион формасы барлыкка килә –***риса-*** элегия һәм 50-100 бәетне үз эченә алган ***касыйдәләр***.

Риса – мәрсия – үлгәннәрнең мәете өстендә җырлана торган сыктаулардан башлангыч ала. Гадәт буенча, бәдәвинең хатыны һәм кабиләдәге башка хатын-кызлар күмү вакытында җырлый торган булалар. Шушы сыктаулары белән хатын-кызлар ирләренең рухын үз янында тота дигән ышану яшәгән. Бу вакытта аны мактау белән беррәттән, үз кабиләсенең батырлыгына дан җырлана. Әлеге үлемнәрнең күбесе, күчмә халыкларның тормыш законы буенча, кабиләара канкоюлар нәтиҗәсе булганлыктан, мактау күп вакыт нәфрәт чәчү һәм үч алырга чакыру белән аралашып килә.

Гарәп әдәбиятында беренче риса җаһилият чорының иң күренекле җырчысы әл-Мөхәлхил иҗатында очрый. Аның үз абыйсы Кулейбка багышланган мәрсиясе билгеле. Ул Мөхәлхилнең абыйсы гына түгел, ә бәкер һәм таглиб кабиләләренең гаскәр башлыгы да. Ә гаскәр башлыгы исә һәр бәдәви өчен изге, хөрмәтле, кадерле зат булган. Димәк, беренче рисадән үк аның гади кешегә түгел, ә күренекле затларга багышланганлыгы күренә. Риса көчле сагыш, моң белән сугарылган. Шул ук вакытта горурлык, егетлек, батырлык темасы да күтәрелә.

Мәрсия жанрының генезисы белән бәйле рәвештә, үзләренең рисаләре белән танылган шагыйрьләрнең күбесе хатын-кызлар була. Шулар арасында

үзенең абыйсы, суләйм кабиләсенең юлбашчысы Сахрага багышлап язылган мәрсияләре белән шагыйрә әл-Хәнсә зур популярлык казана. Аның шигырьләренең нигезендә зур югалтулар китергән кайгы, авыр хәсрәт ята. Ул хатирәләр белән яши һәм бөтен нәрсә аңа абыйсын хәтерләтә, ә һәр хатирә аңа авырдан-авыр газаплар китерә. Гарәп әдәбиятында беренче тапкыр әл-Хәнсә мәрсияләрендә якты дөнья белән хушлашкан каһарманның юмартлыгына, кунакчыллыгына дан җырлана. Бу сыйфатлар Урта гасыр гарәп мәрсиячеләре иҗатында да дәвам иттерелә. Өммәвиләр чорыннан илаһи мәхәббәт җырчысы – Ләйлә әл-Әхъялийәнең сөйгәне Тәүбәгә, сәяси көрәш поэзиясе тарафдары Җәрирнең – дошманы һәм каләмдәше Фараздакка багышланган һәм күпсанлы традицион мәрсияләре барлыгы билгеле.

Гарәп әдәбиятында иң борынгы һәм композициясе ягыннан иң катлаулы поэтик форма – ***касыйдә*** санала. Беренче касыйдәләр җаһилият чорында ук барлыкка киләләр. Әдәбият галиме И.Фильштинский фикеренчә, жанрга нигез салучы булып әл-Мөхәлхил тора. Ә инде тәмамланган беренче касыйдә Имрелкайс “Мөгалләка”сында күренә.

Касыйдәләр бер-берсе белән аз бәйләнештә торган берничә структур кисәктән, өлештән тора. Шулай ук сюжет та, стиль дә төрле. Әлеге структур кисәкләр бары касыйдәне тыңлаучы бәдәвиләрнең күңелләрендә генә берләшә, бербөтенгә әйләнә. Чөнки ул аларның яшәешен, күңелләрен, хыялларын чагылдыра.

Жанр күзлегеннән караганда, касыйдә синкретик характерда. Касыйдәнең аерым өлешләре бары жанр формалары гына булып торалар, бары Урта гасырларда гына мөстәкыйльлек алалар.

Касыйдәнең лирик башлам өлеше – ***нәсиб*** дип атала. Нәсибтә шагыйрь үткәненә, мәхәббәте белән беренче очрашу һәм аның белән мәңгелеккә аерылышу кебек моңсу, сагышлы хатирәләргә алып китә, ягъни үзенең үткән мәхәббәтен хәтерендә яңарта. Аның белән үткәргән бәхетле минутларын сагына, мәхәббәт китергән ләззәтләр, газаплар исенә төшә. Сөйгәнен, очрашуларын тасвирлый, аерылу газабын сурәтли. Мәхәббәт шигырьләре

исламга кадәрге чорда аерым жанр буларак үсеш алмыйлар. Үзен хөрмәт иткән бер генә шагыйрь дә лирик башламсыз төп өлешкә күчми.

Лирик башламнан соң тасвир – ***васыф*** өлеше килә. Ул нәсибтән күпкә баерак. Монда әдип игътибарын тугры юлдашы – ат яки дөягә юнәлтә. Бу гарәпләрнең гореф-гадәтләренә бәйле, ягъни дөя – аларның яшәешендә зур роль уйнаган җан иясе. Шагыйрь аны бик тәфсилләп сурәтли: ул гаҗәеп көчле, искиткеч чыдам, сабыр мал. Аяклары нык һәм җитез, тиресе калын, энҗе кебек ялтырый. Шулай ук күп кенә касыйдәләрдә Гарәбстанның табигатен, чүл, дала киңлекләрен, флора-фауналарын, комсыз кояшны, суык төннәрне, ком бураннарын да тасвирлыйлар. Васыф икенче төрле – пейзаж лирикасы.

Исламга кадәрге чорда касыйдәнең төп өлешен ***фәхр***- үз-үзеңне мактау алып тора. Фәхрдә бәдәви шагыйрь үзен, эш-гамәлләрен, кабиләсенең, нәселенең батырлыкларын мактый. Батырлык, юмартлык, киң күңеллелеккә дан җырлана. Риса белән бик охшаш, анда вафат булган кеше макталса, фәхрдә кабилә герое – шагыйрь үзе була.

Касыйдәнең төп жанр формасы- ***мәдхия***. Аны шулай ук фәхр белән бутарга мөмкин. Мәдхия күп вакыт кабилә башлыкларына, идарәчеләргә, әмирләргә багышлана. Урта гасырларда мөстәкыйль жанр булып яши башлый. Гарәп әдәбиятында беренче мәдхия җаһилият чорының сукбай шагыйре Тааббата Шарран иҗатында күренә. Сукбайлыкта йөреп, язмышның ачы көлүләрен күп күргән горур табигатьле, тәкәббер Тааббатаның кемнедер мактап шигырь язуы гаҗәеп күренеш була. Ләкин аның мәдхиясе үзеннән соңгы сарай шагыйрьләренекеннән бик нык аерыла. Ул үзенең мактау объектын – туганы Шәмс ибн Мәликне үзенә тиң итеп, бер дәрәҗәдә сөйләшә, аны үз кабиләсенең данын йөртүчесе төсендә күрә. Аның мәдхиясе беренче чиратта бәдәвиләр батырлыгына дан җырлаган гимн булып тора.

Җаһилият чоры “Мөгалләка”лары да үзләрендә шактый гына мәдхияләр саклаганнар. Шундыйлардан Зөһәйр ибн әл-Сүлмәнең, Нәбига әз-Зөбьяни

каләменнән төшкәннәре игътибарга лаек. Алар да кабилә башлыкларын һәм идарәчеләрне мактау юлыннан баралар.

Ислам дине кабул ителгәннән соң мәдхияләр Аллаһы Тәгаләгә, Мөхәммәт пәйгамбәргә багышлап языла башлый. Бу чорда Кааб ибн Зөһәйр, Хассан ибн Сабит кебек мәдхиячеләр мәйданга килә. Өммәвиләр чорында исә халифәләрне данга күмүче махсус сарай шагыйрьләре пәйда була – әл-Әхтәл, әл-Фараздак, Җәрир кебек сүз осталары сәяси көрәш поэзиясе дигән юнәлешкә нигез салалар.

Гарәп әдәбиятында касыйдәнең лирик башлам өлеше нәсиб, алда әйтеп киткәнчә, шагыйрьнең яшьлек мәхәббәтен тасвирлый. Мәхәббәт китергән бәхетле минутлар, сөю-сөелү ләззәте, газаплар гәүдәләндерелә. Автор зур осталык белән сөйгәнен, аның матурлыгын сурәтли.

Гарәп әдәбияты белгече И. Фильштинский мәхәббәт темасына иҗат итүче беренче шагыйрь дип әл-Мөхәлхилне атый, ә кайбер галимнәр Имрелкайсны күрсәтә. Имрелкайсның мәхәббәт лирикасы беркатлы хисси характерда. Ул үзләренең очрашуларын, сөйгәненең тышкы кыяфәтен зур төгәллек белән тасвирлый. Моның белән ул гарәп шигъриятенә зур яңалык алып килә, аңа кадәрге авторларда бары дөянең генә матурлыгы калкуландырып сурәтләнгән була. Сөйгәненң муенын ак антилопа муенына, сумаладай кара чәчен хөрмә пальмасы җимешенә, зифа буен страуска тиңли. Антилопага (газәл) бәйле сурәтләү чарасы аннан соңгы шигърияттә нык популярлаша.

Сарай шагыйре Нәбига әз-Зөбъяни (6 гасыр) лирикасында сөйгән яр Кояш, энҗе белән чагыштырыла, шулай ук гүзәл кызны чәчәккә, гөлгә тиңләү дә беренче тапкыр шушы автор иҗатында күзәтелә. Гарәпләрнең яшәешендә мөһим роль уйнаган дөя изгеләштерелгәнлектән, күп кенә шагыйрьләр лирикасында сөйгән яр шул җан иясе белән янәшә куела. Беренчеләрдән булып мондый янәшәлек җаһилият чорыннан әл- Әгшаның “Хурайра белән хушлашу” касыйдәсендә күзгә ташлана.

Исламга кадәрге поэзиядә һәм гозрәитләрнең илаһи мәхәббәт җырларында, һәм шәһәр лирикасы вәкилләре иҗатында сөйгән ярга, мәхәббәткә дан җырлау яшәп килә. “Мәхәббәт-газап” юнәлеше тарафдарлары Җәмил ибн Магамар, Ләйлә –әл Әхъялийә, Кайс ибн Мөләүвахлар иҗатында чиста, саф, әфлатун мәхәббәте данланса, “мәхәббәт-ләззәт” канатын тәшкил иткән Гомәр ибн әбу Рабига, әл-Әрҗа, Әл-Әхвәс, әл-Вәлид ибн Язидләр исә төрле күңел ачуларны, мәхәббәт маҗараларын, ул китергән ләззәт һәм рәхәтлекләрне натуралистик планда тасвирлыйлар, хәтта кайберләре эротик элементлар белән дә сугарылган. Әлеге юнәлештә аеруча популярлашкан Гомәр ибн әбу Рабига хөрмәтенә бу төр әсәрләрне “гомәридләр лирикасы” дип тә атаганнар. Шушы чордан мәхәббәт шигырьләре мөстәкыйль яшәешкә дәгъва кыла һәм ***газәл*** дип йөртелә башлый. Бу жанрны фарсы әдәбиятында гамәлгә куючы булып Рудакый санала. Фарсы газәле үзенең тәмам камилләшүе һәм популярлык казануы белән Сәгъдигә һәм “Шираз сандугачы” – Хафизга бурычлы.

**Түбәндәге сорауларга җавап бирегез:**

1. Гарәп әдәбияты кайда туа?
2. Кем ул бәдәви? Ул нинди шартларда яшәгән?
3. Борынгы гарәпләрнең шигърият чыганакларын атагыз.
4. Җаһмлият чоры әдәбиятына сыйфатлама бирегез.
5. Борынгы гарәп шигъриятендәге лирик герой үзенчәлеген аңлатыгыз.
6. Җаһилият чоры шигъриятендә нинди жанр төрләре өстенлек итә?
7. "Мөгалләка"лар һәм аларның авторлары хакынданиләр исегездә калды?

## Тема №3. Халифәлекләр чорында гарәп мөселман әдәбияты

**Аннотация.** Әлеге лекция халифәлекләр чоры гарәп әдәбияты хакында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Яңарыш чоры гарәп әдәбиятындагы

төп юнәлешләр, асыл сыйфатлары, күренекле әдипләрнең иҗат мирасы мәсьәләләре карала.

**Ачкыч сүзләр**: тугрылыклы халифә, өммәвиләр, габбасыйлар, бәдәвиләр лирикасы, шәһәр лирикасы, сәяси көрәш поэзиясе, зөһдият, тардият, хәмрият, шугубия хәрәкәте.

**Методик күрсәтмәләр:**

- Лекция өлешендә теманың төп мәсьәләләре карала, иң әһәмиятле моментларга басым ясала.
- Теманы тагын да яхшырак ачу максатыннан төп һәм өстәмә әдәбият, текстлар, интернет ресурслар тәкъдим ителә.
- Теманы үзләштерүне тикшерү максатыннан якынча сораулар урнаштырыла.
- Сорауларга телдән дә, язмача да җавап әзерләргә мөмкин.

**Түбәндәге интернет ресурслар тәкъдим ителә:**

http://arabliterature.ru/

http://ru.wikipedia.org/ (Википедия.Свободная энциклопедия)

http://www.vostlit.info (Восточная литература.Средневековые исторические источники Востока и Запада)

http://al--mutanabbi.narod.ru Анализ творчества Аль-Мутанабби

Шидфар Б.Я. Образная система арабской классической литературы (VI–XII вв. // http://www.orientalstudies.ru/eng/images/pdf/b_shidfar_2011.pdf

Словесное искусство древних арабов (VI — середина VII в.) // http://www.textologia.ru

Верования арабов доисламского периода // http://www.azerislam.com/?lngs=rus&cats=40&ids=427

Гибб Х.А.Р.Арабская литература // http://bookitut.ru/Arabskaya-literatura.html

Гумеров И.Г. История арабской литературы //http://tulpar.kpfu.ru/course/view.php?id=107

**Әдәбият:**


1. Куделин А.Б. Арабская литература: поэтика, стилистика, типология, взаимосвязи. – М., 2005.
2. Фильштинский И.М. История арабской литературы. V- начало X века. – М.: Либроком, 2010.
3. Абу-ль-Аля аль-Маарри. Избранное. Пер. сараб.. – М.: Изд-во «Художественная литература», 1990.
4. Шидфар Б.Я. Абу-ль-Аля аль-Маарри. – М.: Наука, 1985.
5. Шидфар Б.Я. Абу Нувас. 2-е изд. – М.: Изд. дом Марджани, 2011.
6. Шидфар Б.Я. Образная система арабской классической литературы (VI-XII вв.). 2-е изд. – М.: Изд. дом Марджани, 2011.
7. Широян С. Г. Великий арабский поэт и мыслитель Абу-ль-Аля аль-Маарри. – М., 1957.


**Текстлар:**


Арабская поэзия средних веков. – М.: Худож. лит., 1975.

Из классической арабской поэзии. Пер, с араб. С.В. Шервинского; Вступ. ст., примеч., подстрочный пер. И.М. Фильштинского. – М: Худож. лит., 1979


**Глоссарий**

**Бәдәвиләр лирикасы** –икенче төрле гозрэитләр лирикасы – өммәвиләр чорында саф мәхәббәткә баш июче, “мәхәббәт- сагыш, кайгы һәм ул котылгысыз” дигән карашны алга сөрүче, илаһи мәхәббәт тарафдарлары. Бәдәви лирикасының күренекле вәкилләре: Җәмил ибн Магамар, Ләйлә әл-Әхъялийә, әл-Мәҗнүн әл-Әмири, Кайс ибн Зарих һ.б.

**Габбасыйлар** – өммәвиләрдән соң хакимияткә килеп, биш гасырдан артык (750—1258 еллар ) халифәлек иткән гарәп халифәләре династиясе. Беренче халифә - Габдулла ибн Мөхәммәд әс-Сәффах, соңгысы – әл-Мөстасим 1258 елда монголлар тарафыннан үтерелә.

**Гали** (Гали ибн Абу Талиб) – сөнниләрнең дүрт "тугрылыклы халифә"ләренең берсе (656-661 елларда идарә иткән). Мөхәммәд пәйгамбәрнең кияве, шигыйлар Галине Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң мөселманнар белән идарә итү өчен күктән иңдерелгән дип саныйлар, изгеләштерәләр.

**Гозрә** – Вамыкның мәгъшукасы, матурлык һәм мәхәббәт символы. "Гозрәидләр лирикасы" аның исеме белән бәйле.

**Зөһдият**– фәлсәфи характердагы аскетлыкны алга сөрүче юнәлеш

**Өммәвиләр** - дүрт тургылыклы халифәдән соң 661 елда властька килгән династия, беренче халифәләре Могавия (661-680) - Сүрия наместнигы. Башкаланы Дәмәшкъка күчерәләр, барлыгы – 14 халифә идарә итә, соңгысы – Мәрван II (744-750), 750 елда Әбу Мөслим восстаниясе нәтиҗәсендә габбасыйлар тарафыннан тәхеттән бәреп төшереләләр.

**Сәяси көрәш поэзиясе** – өммәвиләр чорындагы сарай мәдхиячеләре шигърияте. Бу сарай җырчылары өммәвиләрне данга күмеп, аларның дошманнарын тәнкыйтьләп, алардан туктаусыз көлеп, әсәрләрен күпләп тәкъдим итеп торалар. Бу юнәлеш, максатыннан чыгып, "сәяси көрәш поэзиясе" дип тамгалана. Һәм ул юнәлешне Әл-Әхтәл, Фараздак һәм Җәрир исемле шагыйрьләр "өчлеге" тәэмин итә.

**Тардият** – аучылыкны гәүдәләндерүче шигърият.

**Хәмрият** – шәраб поэзиясе

**Шәһәр лирикасы** – өммәвиләр чорындагы утрак тормышлы гарәпләр лирикасы. Ирекле эчтәлекле, төрле мәҗлесләрне, эротик күңел ачуларны натуралистик планда тасвирлаган әдәбият. “Гомәридләр лирикасы” дип тә йөртәләр. Вәкилләре: Гомәр ибн әбу Рабига, Әл-Әхвәс, әл-Вәлид ибн Язид һ.б.

**Шугубиячеләр** (шугубиты) **–** нигездәиранлылардан(фарсылар) торган, сәяси һәм мәдәни тигезлек өчен көрәшүчеләр, ислам дине кабул иткән халыкларның тигез хокуклы булуларын таләп итәләр, хәтта фарсыларның һәм гарәп булмаган башка халыкларның өстенлеген дәгъвалыйлар һәм бу юнәлешкә шугубия хәрәкәте дигән исем бирелә. Әдәбиятта бу юнәлешне алга сөрүчеләр булып Бәшшәр ибн Бурд һәм Әбу Нәүвас санала. Алга таба башка фарсы әдипләре тарафыннан үстерелә.

**Элеккеге традицияләрне торгызу өчен көрәшүче әдәбият-** гарәпләрнең элеккеге авторитар рольләрен кайтаруны таләп иткән консерватив, реакцион, үткәндәге традицияләргә кайтуга йөз токан юнәлеш, яңалык өчен көрәшүчеләрнең төп дошманнары. Күренекле вәкилләре: Әбу Тәммам, әл-Бухтури, әл-Җәһиз.һ.б.

**Яңалык өчен көрәшүчеләр әдәбияты - г**аббасыйлар чорындагы әдәбиятта “яңа өслүб”тә язучы әдипләр дулкыны. Алар үзләрен яңалык өчен көрәшүчеләрдип атыйлар.Бәшшар ибн Бурд, Әбу Нәүвас, Әбу әл-Әтәхийә һ.б**.** шушы дулкынны тәшкил итүчеләрнең иң танылганнары.

**Өйрәнү өчен тәкъдим ителгән сораулар:**

1. Ислам таралган чорда гарәп әдәбияты
2. Өммәвиләр чоры (661-750) әдәбияты. Шигърияттә "бәдәви" , "шәһәр", "сәяси көрәш" лирикалары һәм аларның атаклы вәкилләре
3. Габбасыйлар чоры әдәбияты. Гарәп әдәбиятының яңарыш чоры (VIII г.уртасы - IX г.б.)

## 1. Ислам таралган чорда гарәп әдәбияты

Ислам таралган чорда поэзиянең төп максаты – ислам динен пропагандалау,Аллаһны олылау, Мөхәммәд пәйгамбәр тәгълиматын хөрмәт итәргә һәм исламны кабул итмәүчеләргә каршы көрәшергә чакыру. Поэзиядә төп жанрлар – касыйдә, мәдхия, риса, һөҗү.

Аллаһны олылап, зурлап, гөнаһларны кичерүен сорап, Мөхәммәд пәйгамбәрнең батырлыгына дан җырлаган мәдхияләр беренче планга чыга. Исламның төп дошманы саналган көрәйшитләрдән көлеп язылган сатирик шигырьләр күбәя, шул ук вакытта исламны тәнкыйть итеп, борынгы бабалары диненә кайтырга чакыручы юнәлеш тарафдарларының әсәрләре дә үзләре бер канат тәшкил итә. Бу җәһәттән Кааб ибн Зөһәйр һәм Хассан ибн Сабит иҗатлары игътибарга лаек.

**Кааб ибн Зөһәйр** ислам таралган чорда инде танылган, шөһрәтле шагыйрь була. Абыйсы Буджейр ислам кабул итә, моңа Каабның бик нык ачуы килә. “Син – хыянәтче, бабаларыбыз диненә кире кайт”, - ди. Абыйсы ниятеннән, үзе сайлаган юлдан кире борылырга уйламый да, ул, киресенчә, Каабны исламга тарту юлларын эзли башлый. Каабның исә ачуы көчле була, ул исламны, Мөхәммәд пәйгамбәрне, аның тарафдарларын тәнкыйтьләп шигырьләр яза башлый. Шулай итеп шагыйрь Мөхәммәд пәйгамбәргә каршы көрәшкә күтәрелә. Пәйгамбәр белән бәрелешләр вакытында ул каты яралана, ярдәм сорап кабиләдәшләренә кайтып егыла. Үзен яклаучылар таба алмагач, мәҗбүри рәвештә, ислам кабул итә. Пәйгамбәрдән ярлыкау алу максаты белән “Суад мине ташлап китте” касыйдәсен язып, Мәдинәгә юл ала. Мөхәммәд пәйгамбәргә касыйдә бик ошый, ул аны гафу итә һәм хәтта бүләк итеп, өстендәге плащын да салып бирә. Хөрмәт йөзеннән әсәрнең исеме “Плащ” дип үзгәртелә. 58 бәеттән торган бу касыйдәнең 1-12 строфасы – нәсиб, 13-33 – васыф, биредә үзенең дөясен, аңа утырып сөйгәненә ашкынган мизгелләрен тасвирлый, ә 33-58 бәетләре – Мөхәммәд пәйгамбәргә мөрәҗәгать, аны һәм тарафдарларын мактаган, ярлыкау сораган өлеше. Зур

түбәнчелек белән гафу соравы һәр юлыннан сизелеп тора, пәйгамбәрне арысланга тиңли, аның көчен, хаклылыгын күрсәткәндә кылыч образына мөрәҗәгать итә. “Ул – туры юлны күрсәтүче, әгәр шушы юлдан тайпылсаң, ул сине аямаячак, тураклаячак” дигән юллар китерелә. Моннан соң да шигырьләре һәм эш-гамәлләре аша пәйгамбәр эшчәнлегенә зур ярдәм күрсәтеп тора.

Ә **Хассан ибн Сабитка** килгәндә, ул - Дәмәшкътагы гассанидлар сарае шагыйре. Каабтан аермалы буларак, ул исламны, үз тиресен саклап калыр өчен түгел, ә аның хак юл икәнлегенә чын күңелдән ышанып, үз теләге белән кабул итә. Бу вакытта инде аңа 60 яшь була. Ләкин ул пәйгамбәргә бары тик әсәрләре белән генә ярдәм итә, халык арасында ниндидер эшләр алып барырга инде көче булмый. Мөхәммәд пәйгамбәр аны бик хөрмәт итә, шагыйрьнең үзен данга күмә, хәтта ярты байлыгын биргән дигән фаразлар да яши.

Хассан ибн Сабитның поэзиясе шактый киңкырлы, ул 3 юнәлештән гыйбарәт:

1. Традицион мактау җырлары. - Фәхрияжанрында күп яза, җаһилият чоры традицияләрен дәвам итеп, үз кабиләсенә дан җырлый.Гассанидлар династиясен данга күмеп, хөкүмәт җитәкчеләрен мактап язган **мәдхия**ләре аның үзен дә зур ихтирамга, байлыкка төрә.
2. Ислам поэзиясе. – Аллаһны олылап, Мөхәммәд пәйгамбәрне, аның тарафдарларын зурлап, көрәйшитләрне сүгеп язган шигырьләре.
3. Күңел ачулар шигърияте**.** – Ул биредә бәйрәми тормыш, җырлы-биюле, хисле уеннар, мәхәббәт маҗаралары, хәмер, аның тәме, ул биргән алыштыргысыз ләззәт турында яза. Димәк, шәраб поэзиясе исламга кадәрге чорда ук гарәп дөньясында барлыкка килгән һәм хәтта ислам таралган чорда да арткы планга чигенмәгән дигән фикергә килергә мөмкин.

## 2. Өммәвиләр чоры (661-750) әдәбияты. Шигърияттә "бәдәви", "шәһәр", "сәяси көрәш" лирикалары һәм аларның атаклы вәкилләре

Мөхәммәд пәйгамбәр үлгәннән соң, властька дүрт тугрылыклы халифә килә: Әбу Бәкр, Госман, Гомәр һәм Гали. Госман вафат булганнан соң, идарә мәсьәләсендә алар арасында бәхәс чыга. Чөнки Госманның үлемендә Галине гаеплиләр. Властька ике кеше тәкъдим ителә: Әл-Зөбәйр, Сүрия наместнигы – Могавия. Гали һәм шушы ике кандидат арасында канлы көрәш башланып, бу орышларда Гали һәлак була. Аның тарафдарлары улы Хәсәнне куярга телиләр, ләкин ул, Могавиядән куркып, үзе тәхеттән баш тарта һәм ил белән өммәвиләр нәселеннән булган Могавия идарә итә башлый. Дүрт тугрылыклы халифә һм аннары өммәвиләр заманында ил үскәннән үсә бара. Гарәбстан үзенә Месопотамия, Сүрия, Палестина, Иран, Мисыр, Төньяк Африка, Пиреней ярымутравы, Урта Азия, Һиндстанның Төньяк Көнбатыш өлешен, Әрмәнстан, Азәрбәйҗан, Грузиянең бер өлешен буйсындырып, бик көчле дәүләт төзи һәм ул – халифәт – халифәлек дип атала башлый. Башкаласы – Дәмәшкъ шәһәре була.

Өммәвиләр башкаланы Дәмәшкъка күчергәч, хиджазлылар арасында ризасызлык туа һәм алар өммәвиләрнең дошманына әйләнә. Өммәвиләр, үз чиратында, хиджазлылардан баш тарта, аларны хөкүмәт тирәсенә җибәрмиләр. Аларны сәясәттән аеру максатыннан, төрле байлыклар белән кызыксындыра башлыйлар, бәдәвиләрне төрле һөҗүмнәр ясаудан тукталар, шулай итеп, илдә тынычлык оештыралар.

Неҗдә һәм Хиджаз далаларына куылган, үз өйләрен ташлап киткән, зур идеаллары булган, шуларга нык ышанып яшәгән, саф мәхәббәткә баш июче ризасыз кешеләр төркеме җыела һәм бу шигъриятнең яңа бер дулкын булып үсеп китүенә китерә.

Бу чорда шигърияттә 3 төрле юнәлеш яшәп килә: “бәдәви”, “шәһәр” һәм “сәяси көрәш” лирикалары.

Бәдәви лирикасының күренекле вәкилләре: Җәмил ибн Магамар, Ләйлә әл-Әхъялийә, әл-Мәҗнүн әл-Әмири, Кайс ибн Зарих һ.б.

**Җәмил ибн Магамар -** хатын-кыз матурлыгын тасвирлаган нәсибләре аны дөньяга таныта. Алар – сөйгәне Бусейнага багышланган. Аның мәхәббәте – әфлатун мәхәббәте, ул сөйгәне белән бер күрешер өчен әллә нинди авырлыкларга да түзә, түбәнлекләрдән дә тартынмый. Эчкерсез беркатлы сөю хәтта үлгәч тә аннан китмәячәк. Шигырьләре эмоциональ һәм музыкаль яңгырашлы.

**Ләйлә әл – Әхъялийә**әл-әхъял кабиләсеннән, бик гүзәл һәм матур сөйләшүче, җор телле шаян кыз була. Аның мәхәббәте - Тәүбә ибн әл-Хумайр, егет тә кызны бик ярата, Ләйлә аңа бик күп шигырьләрен багышлый, өйләнешергә хыялланалар. Ләкин Ләйләнең әтисе шул шигырьләрендә мәхәббәтен ачыктан-ачык белдергәне өчен бик нык хурлана һәм кызын башка кешегә кияүгә бирә. Ире бик көнчел кеше була, өенә берәүнең дә килүен теләми, шулай да Тәүбә килеп йөрүен туктатмый. Көннәрнең берендә аны үтерергә уйлыйлар, Ләйләнең яланбаш күренүеннән эшне аңлап алып, үлемнән котылып кала.

Тәүбә бик күп сугышларда, орышларда катнаша, берсендә вафат та була. Ләйлә бик авыр кичерә, мәрсияләр яза. Риваятьләргә караганда, имеш Ләйлә ире белән Тәүбә кабере яныннан узып барганда, аның ризасызлыгына карамыйча, сөйгәненә сәлам биреп уза. Тәүбә дәшми. Ләйлә бик күңелсезләнә, шулчак җир астыннан тавыш ишетелә, хатын йөрәген тотып егыла һәм җан бирә, аны мәхәббәте белән янәшә җирлиләр.

Ләйлә- мәдхия, мәрсия, сатира остасы. Иң яхшы әсәрләре Тәүбәгә багышланган. Ул аның көченә, куәтенә дан җырлый. Хисләре тирән,

эчкерсез, чын күңелдән язылган. Тәүбә үлгәннән соң гомере буе аны сагынып яза. Ул әл-Хәнсәдән кала гарәп әдәбиятында иң көчле шагыйрә санала.

**Шәһәр лирикасы** - яисә утрак тормышлы гарәпләр лирикасы. Ирекле эчтәлекле, төрле мәҗлесләрне, эротик күңел ачуларны натуралистик планда тасвирлаган әдәбият. Вәкилләре: Гомәр ибн әбу Рабига, Әл-Әхвәс, әл-Вәлид ибн Язид һ.б.

**Гомәр ибн Әбу Рабига** - көрәеш кабиләсенең бик танылган данлыклы гаиләсендә 644 елда Мәдинәдә дөньяга килә. Әтисе 4 тугры халифә заманында Ямәнда хакимлек итә. Исламга кадәр дә, яңа заманда да бик авторитетлы була. Гомәр һичнинди кыенлыклар күрмичә, бай, купшы, бәйрәми тормышта үсә, бик күп илләр буйлап сәяхәт итә, танылган кешеләр белән аралаша, сәясәткә кагылмыйча гына, алар турында шигырьләр яза. Хаҗ вакытын бик ярата торган була, иң матур киемнәрен киеп, андагы гүзәл хатын-кызлар белән очраша, аларны үз шигырьләрендә сурәтли. Танылысы, данга төренәсе килгән хатын-кызлар аны үзләре эзләп таба башлыйлар. Бик күп танылган кешеләр үз хатыннары өчен куркуга төшә. Бөтен гомере гүзәл затлар арасында үтә. Кульсумга өйләнә.

Гомеренең ахырында Гомәр яхшы ниятле кешегә әйләнә, мондый тормыштан баш тарта, үзенең эшләгән гамәлләре, үткән тормышы өчен бик еш кызарса да, үзенең эзләре буйлап әйләнәсе килгән вакытлары күп була.

Үлеме хакында 3 төрле версия яши:

1) Йеменда авырып үлгән;

2) диңгездә корабта янып үлә;

3) Сөргенгә сөрәләр-шунда үлә.

Ул бик матур кыяфәтле, хисчән, җор телле, әйтерсең, сөю-сөелү, мәхәббәт өчен генә яратылган. Җилбәзәк, үткен, шаян, һәрвакыт шат

күңелле. Аның белән бер генә сөйләшү, аралашу, мәҗлесләргә эләгү хатын-кызларның аерылгысыз хыялы була. Тормыш, яшәеш мәгънәсен бары матурлыкта һәм күңел ачуларда гына күргәнлектән, хаҗ кылучы ханымнарга бик күп бәхетсезлекләр дә китергән.

Төп жанры – газәл. Күзенә матур күренгән бер генә хатын-кызга да гашыйк булмыйча һәм шигырь язмый калмаган. Эчке һәм тышкы матурлыкларын мактаган. Эчке матурлыгын үз-үзен тотышында, характерында, сөйләшүендә, мөгаләмәсендә (бигрәк тә үзе белән мәхәббәт маҗаралары вакытында) таба. Тышкы гүзәллекне тасвирлау исә традиционлыктан читләшми.

Аның сөяркәләре, нигездә, танылган гаиләләрдән була. Аларны кояшка һәм ак газельләргә тиңли. Шигырьләрендә тирән фикер, киң фантазия очрамый, шулай ук тирән хис, рухи байлык та күзәтелми. Шигырьләре аһәңле, музыкаль яңгырашка ия, газәлләрендә диалог һәм хикәяләү формаларын еш куллана.

Шагыйрь традицион размерлардан баш тартып, хәфиф, рәмәл кебек җиңел һәм кыска үлчәмнәр белән эш итә.

**Әл-Әхвәс -** Габдулла ибн Мөхәммәд. Мәдинә шәһәреннән, яхшы тормышлы гаиләдә туып үскән. Үзенең шигырьләрендә күп кенә кешеләрдән көлә һәм шунлыктан тормышында бик күп кыенлыклар да күрә. Ул уен-көлке, күңел ачарга, рәхәт яшәргә ярата.

Төп жанры- газәл. Үзәктә - гашыйкларның мәхәббәт кичерешләре, газаплары, ләззәтләре. Аның мәгъшукалары арасында бик күп коллар да була. Шулай да аның аларга хисләре саф һәм чиста, эчкерсез сөюе белән башкалардан аерылып тора. Кол һәм җарияләрне мактау – өммәвиләр чорының үзенчәлеге.

**Әл-Вәлид ибн Язид.**708 нче елда Дәмәшкътә туа. Шулай ук яхшы тормышлы гаиләдән. Күңел ачарга, ауга йөрергә, хәмер эчәргә ярата, бөтен буш вакытын мәҗлесләрдә, хатын-кыз матурлыгына табынучылар арасында үткәрә. Ул кол кызларның җырлаганын тыңларга ярата, гомумән аның йорты җырчыларга, шагыйрьләргә һәм матур кызларга һәрвакыт ачык була. 733 елда халифә дәрәҗәсен ала, 743 елда вафат була.

Аның сакланып калган шигырьләре бик аз. Берничә газәле, мәрсиясе, мәдхиясе, берничә тасвиры, берничә һөҗү жанрындагы әсәре билгеле.

Төп темасы – кешенең эчке дөньясы. Ул аны күңел ачу вакытында да, кайгы-хәсрәттә дә сурәтли. Аның шигырьләре җиңел, хисчән, чын күңелдән язылган. Аны “оятсыз шагыйрь”ләрнең юлбашчысы дип тә атыйлар. Ул өммәвиләр һәм габбасыйлар поэзиясен бәйләп торучы шагыйрь.

**Сәяси көрәш поэзиясе.** Халифәлек оешкан чорда гарәп шигъриятендә зур урынны сарай мәдхиячеләре алып тора. Әлеге сарай җырчыларының иҗаты, максатыннан чыгып, “сәяси көрәш поэзиясе” дип тамгалана. Һәм ул юнәлешне Әл-Әхтәл, Фараздак һәм Җәрир исемле шагыйрьләр “өчлеге” тәэмин итә.

Бу сарай җырчылары өммәвиләрне данга күмеп, аларның дошманнарын тәнкыйтьләп, алардан туктаусыз көлеп, әсәрләрен күпләп тәкъдим итеп торалар. Шулай да аларның төп максатлары – башкада – үз кабилә мәнфәгатьләрен яклау, өммәвиләргә кабиләләрен ничек тә үз канатлары астына алдырту. Үзләренең төче, купшы әсәрләре белән алар халифәләргә тугрылыкларын исбатларга, шул ук вакытта дошман кабиләләрен булдыра алган кадәр каралтырга омтылганнар. Шунлыктан бу өч әдип иҗатында нәкаид жанры зур урын алып тора. Ул инде исламгача чорда ук таралыш алган булса да, өммәвиләр дәверендә аеруча популярлаша. Сатирик рухлы бу касыйдәләр, нигездә, дошман кабиләләргә адреслана, ә каршы як, әсәрнең бөтен үлчәмнәрен саклаган хәлдә, җавап кайтарырга тиеш була.

**Әл-Әхтәл** (640-710)- таглиб кабиләсеннән, христиан дине вәкиле. Хирада туа, үги ана җәберләүләре күреп үсә, иҗатын үги әнисеннән, кабиләдәшләреннән көлгән шигырьләрдән башлап җибәрә. Могавия һәм Язид идарә иткән чорда өммәвиләр сараенда, Дәмәшкътә яши. Бик почетлы, хөрмәтле кеше була. Язид властька килгәч, хөрмәт тагын да көчәя, ул халифәнең уң кулына, дустына әйләнә, мәдхиягә күмә, вафатыннан соң мәрсияләр яза.

Габделмәлик ибн Мерван идарә иткән чорда бик күп сугышлар була, Әл-Әхтәл ул яуларда өммәвиләр ягыннан сугыша, трибун дәрәҗәсенә күтәрелә, шуның өчен аңа халифә “өммәвиләр шагыйре” дигән титул бирә. Хәлифәне, аның улларын, туганнарын мактаган мәдхияләр аңа күп байлык китерә. Аларның дошманнарын сатира угына тота.

Әл-Әхтәл фәхрия, мәдхия, сатира, газәл, хәмрия жанрларында иҗат итә. Хәмер – аның тормышында зур урын алып тора, әгәр аерым касыйдәләр дә язса, аны “шәраб җырчысы” дип тә атарга мөмкин булыр иде.

**Әл-Фараздак** (641-732) – Басра гарәпләре арасында танылган, шөһрәтле гаиләдән. Байлыкта, рәхәттә үсә, бәдәви традицияләрендә тәрбияләнә. Бәйрәми тормыш алып бара, берничә тапкыр өйләнә, ләкин аерыла. Үзенең бер әсәрендә үзенә 10 бала бүләк иткән ән-Навар исемле хатынын телгә ала. Бу хатынын үзенең дошманы Җәриргә ярдәм сорап барганы өчен аера.

Затлы, шөһрәтле нәселдән булуына карамастан, Гыйрак хакимияте каршында бер дә хөрмәте булмый. Сәбәбе – усал теле һәм үзгәрүчән характеры. Өммәвиләр, хакимият кешеләре аннан гомумән куркып торганнар. Могавия идарә иткәндә Басра хакиме Зыяд белән бәхәс чыга. Зыяд аны куркыта, Фараздак Басрадан китеп, Мәккә, Мәдинә, Йемен, Бахрейн, Палестина, Дәмәшкъта була. Үзе булган һәр урында мәдхия һәм һөҗү язып, кемнедер сөендереп, кемнедер көенергә мәҗбүр итә. Зыяд үлгәннән соң, аны

гына түгел, бөтен якыннарын, хәтта аны җирләүдә катнашкан кешеләрне дә мыскыллап, сатирик шигырьләр яудыра. Өммәвиләргә дә түбәнчелек белән гафу үтенергә дип берничә тапкыр килә, ләкин шунда ук сатирик әсәрләр иҗат итеп, янәдән көләргә тотына.

Җәрир исемле каләмдәше белән 50 елдан артык дошманлашып яши. Җәрир үзенең шигырендә абыйсы Муджашия нәселеннән бер ханым турында ямьсез фикер әйтә һәм Фараздак аңа каршы чыгарга мәҗбүр була. Бу вакыйгалар халык арасында да бәхәс уята: фараздакчыларга һәм җәрирчеләргә бүленәләр. Гарәп әдәби дөньясының шагыйрьләр арасындагы мондый дошманлыкны моңарчы күргәне булмый. Фараздак 732 елда Басрада вафат була.

Фараздак фәхрия, мәдхия, мәрсия, һөҗү, васыф, газәл жанрларында иҗат итә. Ул һәрвакыт үз кабиләсе җырчысы булып кала, аннан читләшми, сәясәт белән дә кабиләсе мәнфәгатьләрен кайгырту өчен генә кызыксынган була. Могавия белән дә абыйсы Муджашияның мирасын казна файдасына бирергә теләмәгәнлектән генә очраша.

Язылган кадәр мәдхияләрендә өммәви халифәләрне мактый, аларны күккә чөя. Алар Аллаһның дусты, шуңа күрә һәрвакыт җиңү дә алар ягында, ди.

**Җәрир (653-733)-** Йемамда туа. Әтисе танылган кеше түгел, ялкау һәм саран зат була. Җәрир ярлы бәдәви гаиләсендә кырыс шартларда тәрбияләнә. Әтисенең сарык һәм кәҗәләрен көтә. Кечкенәдән җор телле, шигъри җанлы булып үсә, таланты бик яшьли ачыла. Малай вакытында ук үз кабиләсендәге дошманнарына һәм кабиләсенең дошманнарына үчегеп яши һәм киләчәктә шуның белән дан ала.

Фараздак белән бәхәс чыккач, ул Йемамны ташлап, Басрага китә. Бәхет эзләп, Хиджаз, Гыйрак, Йемен, Дәмәшкъ җирләрен таптый, үзен яклаучылар, теләктәшләр эзли, әмирләр сараена урнашу өчен төрле планнар кора. Башта

Могавиягә, аннары Хаджжаджга эләгә, соңгысы аны бик яхшы кабул итә, ә Җәрир идарәчене данга күмә. Хаджжадж ярдәме белән Габделмәлик ибн Мерван сараена кабул ителә, әл-Әхтәл белән бергә иҗат итәләр. Ләкин ул вафат булгач, Җәрир янәдән яклаучысыз кала, әр-Расафка китеп, андагы хуҗаларга хезмәт итә. Фараздак үлеп 40 көн үткәч, Җәрир дә вафат була.

Җәрир - үз кабиләсенең патриоты, өммәвиләрне, аларның туганнарын, дусларын мактый. Мәрсияләре арасында сарай кешеләренә багышланганнары да, үз туганнарына, якыннарына юлланганнары да бар. Дошманы Фараздак үлгәч, аның хакында җылы, матур сүзләр әйтеп язылган мәрсиясе дә билгеле.

Җәрирнең бөтен сатирасының угы Фараздакка юнәлгән. Ул аның “тимерче малае” булуыннан да көлә, чөнки ул һөнәр гарәпләр өчен оят булган. Шулай ук дошманы кабиләсендәге хатын-кызлар өстенә шактый гына пычрак сибә. Аның шәхси тормышына кысылып, бәйрәми, оятсыз тормыш алып барганы, халыкны үз артыннан начарлыкка сөйрәгәне өчен маймылга тиңли. Шулай ук Фараздакны динсезлектә, торыксызлыкта гаепли: “шимбә көнне – яһүди ул, ял көне – христианин” ди.

Җәрирнең әл-Әхтәлгә багышланган һөҗүләре дә бар. Аның да кабиләсен сүгә, диннәреннән көлә, тәреләрен, попларын, чиркәүләрен мыскыл итә. Дуңгыз ите ашауларын, хәмер эчүләрен, бәйрәми тормыш яратуларын тәнкыйтьләп, соңыннан аларны “ишәкләр” дип атый.

Башкаларны хурлаганда, үзен мактап, дошманнарын тагын да кимсетә. Үзенең шәхси сыйфатлары, мөмкинлекләре, шагыйрьлек таланты белән дә, ислам дине вәкиле булуы белән дә мактана.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, өммәвиләр чоры әдәби хәрәкәте төрле рухлы, төрле юнәлешле, күптармаклы җанлы әдәби процесс буларак күзалдына баса.

## 3. Габбасыйлар чоры әдәбияты. Гарәп әдәбиятының яңарыш чоры (VIII г.уртасы - IX г.б.)

Габбасыйлар властька килү белән, фарсылар алгы флангка чыга. Дәүләт белән идарә итүчеләр, гаскәр башлыклары, вәзирләр, хәтта хаттаблар да фарсылар була. Гарәпләр шушы территориядә яшәүче халыкка гына әйләнеп калалар. Башкала Дәмәшкътан Багдадка күчә. Дәүләт белән идарә итү дә, сугышлар алып бару методикасы да, иҗтимагый тормыш та фарсы традицияләренә нигезләнеп тормышка ашырыла. Хәтта ашау-эчү хәзерләү, мәҗлесләр, бәйрәмнәр - барысы да фарсыларча оештырыла, гарәпләрнең традицияләре төрле яклап кысрыклап чыгарыла.

Багдад – зур сәүдә портына, мәдәният һәм сәнгать учагына, кыскасы Шәрык дөньясының йөрәгенә әйләнә. Халифә сараена фән эшлеклеләре, җырчылар, шагыйрьләр җыела, сарай мәдәният һәм шоу үзәгенә әверелә. Шулай ук Басра һәм Куфа шәһәрләре дә габбасыйлар чорының мәдәният үзәкләреннән санала.

Багдад базарында Кытай ефәге, фарфоры, Африкадан китерелгән фил сөякләре, алтын, бизәнү әйберләре, Һиндстан металлары күпләп сатыла. Сарайда күңел ачу мәҗлесләре күп оештырылганлыктан, кайбер халифәләр хәмер эчү белән дә мавыга башлыйлар. Кәнизәкләр тоту гадәткә кертелә, коллар белән сату итү алга китә, шул рәвешле сарайда хаос барлыкка килә.

Милләтләре төрле булган халык арасында мөселманнарның төрле секталары, христиан, яһүди, зәрдәшти, манихей дине вәкилләре гомер кичерә. Мәдәният зур үсеш кичерә, халифәләр төрле фәннәрне үстерү өчен чыгымнарны кызганмыйлар. Берсен-берсе уздырып китапханәләр төзетәләр, яңа буында фәнгә тартылу көчәя, чит халыкларның мәдәнияте һәм цивилизациясе белән кызыксыну бик нык арта. Багдадтагы шундый белем учакларының иң танылганы Һарун әр-Рәшид төзеткән - “Бәйт –әл-хикмә”не (хикмәт, акыл йорты) мисалга китерергә мөмкин.

Бу вакытта әдәбиятка 3 мәдәният зур йогынты ясый:

1) нигезендә Коръән яткан чиста гарәп культурасы;
2) грек мәдәнияте;
3) шәрык мәдәнияте (фарсы, һинд, сәмит халыклары культурасы).

Греклар үзләренең фәлсәфи тәгълиматларын, медицина һәм астрономия өлкәсендәге белемнәрен тараталар. Бу барлык мәдәниятләр илдә мәктәпләр һәм тәрҗемәи әдәбият аша тарала. Борынгы фәннәр габбасыйлар дәүләтенә тәрҗемә һәм күчереп язу аркылы керәләр. Алар греклардан фәлсәфәгә, һиндлылардан аскетлыкка өйрәнсәләр, фарсыларга күбрәк көнкүрештә, көндәлек тормышта яраклашалар. Төрле культураларның таралуы исламның төрле дини секталары барлыкка килүгә китерә.

Халифәлектә сәяси һәм мәдәни тигезлек өчен көрәш җәелә һәм аңа шугубия хәрәкәте дигән исем бирелә. Шугубиячеләр ислам дине кабул иткән халыкларның тигез хокуклы булуларын таләп итәләр. Шулай ук искелек һәм яңалык тарафдарлары арасында көрәш башлана. Әдәбиятта бу юнәлешне алга сөрүчеләр булып Бәшшәр ибн Бурд һәм Әбу Нәүвас санала. Алар иҗатында беренче тапкыр хакимияткә көчле оппозицион караш яңгырый.

Әдәбият бу чорда җәмгыятьнең көзгесенә әйләнә. Сәяси көрәш поэзиясе юкка чыга, шигърияттә яңа юнәлешләр барлыкка килә. Беренче планга фәлсәфи лирика, суфыйчылык поэзиясе, эпоха фикерен җиткерүче үгет-нәсыйхәткә корылган дидактик шигърият чыга. Яңа жанрлардан**зөһдият**– фәлсәфи характердагы аскетлыкны алга сөрүче, **хәмрият** – шәраб поэзиясе**, тардият** – аучылыкны гәүдәләндерүче шигърият зур таралыш ала. Шулай да мәдхия, мәрсия, газәл һәм һөҗү иң популяр жанрлар булып кала бирә. Традицион темалар белән беррәттән, тормышчан, реаль җирлекле әсәрләр дә языла башлый, берничә яңа шигъри үлчәм барлыкка килә. Мәсәлән, мустатиль, мумтауд – озынайтылган, киңәйтелгән мәгънәсендә.

Габбасыйлар чоры әдәбиятын “гарәп әдәбиятының алтын чоры” дип атыйлар. Яңарыш чорының төп үзенчәлеге- катып калган традицион стильдән баш тартып, гарәп әдәбиятын җанлы заманча эчтәлек белән баету. Элек сарай әһелләренә генә хезмәт иткән әдәбият зыялылар катламы, бераз соңрак халык арасында да популярлаша бара. Купшы мәдхиячеләр, традицион касыйдә авторлары бары сарай аристократиясе өчен генә элеккеге авторитетын югалтмый, алар да моңа танылу, шөһрәт алу максатында гына мөрәҗәгать итәргә тырышканнар.

**Яңалык өчен көрәшүчеләр әдәбияты.** Габбасыйлар чорындагы әдәбиятта иң зур яңалык- ул “яңа өслүб”тә язучы әдипләр дулкыны барлыкка килү. Алар үзләрен яңалык өчен көрәшүчеләрдип атыйлар.Бәшшар ибн Бурд, Әбу Нәүвас, Әбу әл-Әтәхийә һ.б. шушы дулкынны тәшкил итүчеләрнең иң танылганнары.

**Бәшшәр ибн Бурд (714-784) –** Басрада һөнәрче фарсы гаиләсендә туа, бәдәвиләр арасында үсә. Шунлыктан гарәп телен яхшы белә, кечкенәдән үк иҗатка тартыла, 10 яшендә инде шигырьләр яза башлый. Багдадта әдәбият һәм башка дөньяви фәннәрне өйрәнә. Зур гына галимнәр, фән эшлеклеләре белән бәйләнештә тора. Матди хәлен яхшырткач үзенә сарай салдыра, бәйрәми тормыш алып бара, күңел ачулар, сөяркәләр, аларга мәхәббәт җырлау Бәшшарның әсәрләрендә дә гәүдәләнеш таба.

Бәшшар тумыштан сукыр, ямьсез гәүдәле, төскә-биткә дә шактый төксе, дөресрәге физик яктан шактый кимсенерлек зат була. Шунлыктан, ул әйләнә-тирәсендәге бер генә кешене дә яратмый, чәнечкеле, ямьсез сүзләр, усал теле белән һәрвакыт кемнедер җәберләп, кимсетеп, кемнәндер көлеп тору аңа тәм бирә. Ул кешеләрне шул дәрәҗәдә яратмый ки, хәтта үзенең сукырлыгына да сөенә. Аның өчен бер генә олы, изге әйбер дә юк. Ул хәтта дингә, Аллаһка да ышанмый, атеист була.

Иң күп язган жанры – һөҗү. Ул – аның яшәү чыганагы. Файда алырына бик ышанган вакытта гына мәдхияләр дә язгалаган, ләкин сатирасы белән күпкә күбрәк мал туплаган, чөнки аның теленә эләгүдән курыккан бик

күпләр аңа акча биреп, телен томалаган. Үзен һәм якыннарын, вәзирләрен гел яманлап язуыннан туеп, Әлмәхди хәлифә 784 елда аны 70 камчыга тоттыртып, җәзалап үтертә. Басра халкы, аның үлем хәбәрен ишеткәч, чын күңелдән бәйрәм итә, хәтта аны күмәргә дә бары фарсылар гына килә.

Бәшшарның әсәрләре “Җырлар китабы”на кертелгән. Һөҗү һәм фәхрия жанрларын бергә кушып та яза, гарәпләрне һәрдаим сүгә, алардан төрлечә көлә, мыскыллый, үзен аларга каршы куя, фарсы булуы белән мактана. Урыны белән бик тупас, ямьсез, пычрак сүзләр белән дә яза.

Газәлләреннән аның мәхәббәткә дә бик җиңел каравы, дөресрәге мәхәббәт хисләрен аңламавы, аны бары тик хисси, минутлык рәхәткә, мизгеллек ләззәткә кайтарып калдыруы аңлашыла. Шулай да аның әсәрләренең сәнгати ягы югары, алар музыкаль яңгырашка ия, аһәңлелек алга чыга, бик күп әсәрләре җыр итеп җырланыла.

**Әбу Нәүвас (762-813) –** ярлы гына фарсы гаиләсендә авылда туа. Малай кечкенә вакытта ук Басрага күченәләр, Коръән укырга өйрәнсен дип, махсус укытучыга йөртәләр. Әтисе яшьли вафат булганлыктан, укуын дәвам итә алмый, хуш исле үләннәр белән эш итүче бер сәүдәгәргә эшкә яллана. Базарда сату белән көннәрен үткәрсә дә, зур тырышлык куеп, тел белгечләреннән белем ала, мәдрәсәләрдә укымыйча гына гыйлем серләренә төшенә. Бер генә фактны да дәфтәргә теркәп куймый, шулай да хәтере бәрабәренә бөтен әйберне белешмәлек кебек истә калдыра торган була.

Басра - күңел ачулар, маҗаралар, бәйрәми тормыш шәһәре, Әбу Нәүвас та шундый яшәешне яратучы, хисчән шагыйрь булып формалаша. Әл-Хубай исемле шагыйрь белән дуслашып, аның дәртле, ләззәтле шигырьләрен укып әсәрләнә, үзенә илһам, юнәлеш ала. Хубай да аны якын күрә, үзен һәм үзе кебек тормыш алып баручы бертөркем дусларын озатып йөрүче итеп, яшь егетне Куфага алып китә.

Әбу Нәүвас табигате белән, әйтерсең, бары мавыгулар, мәхәббәт һәм поэзия өчен яратылган. Ул зифа буйлы, мәһабәт гәүдәле, күп телләр, күп

белемнәр белән коралланган, бик зирәк әңгәмәдәш, кыскасы –һәркемнең күз явын алырлык егет, өстәвенә талантлы шагыйрь дә. Шул ук вакытта ул бераз таркау һәм җиңел холыклы булуы белән дә аерылып тора. Иң беренче чиратта ул – үз хисләренең, йөрәк һәм күңел таләпләренең колы.

Әбу Нәүвасның 12 мең бәетне берләштергән шигырьләр җыентыгы Бәйрутта һәм Мисырда дөнья күрә. Әсәрләренең иң күбесе – күңел ачуларга һәм шәрабка багышланган. Сатирасы, нигездә, 3 төрле яссылыкта ачыла: 1) иске карашлы гарәпләрне искелектә, наданлыкта гаепләү, алардан көлү; 2) сәяси җирлектәге әсәрләрдә фарсыларга мәдхия укып, гарәпләрне аларга каршы кую, хурлау, мыскыллау; 3) шәраб турындагы шигырьләренең башлам өлеше булып тора.

Әсәрләрендә һәрдаим үзенең яңа тормыш яклы булуына басым ясый, яңа тормышның рәхәтлекләрен, уңайлыкларын тасвир итә. Кемнәрнедер шушы тормышны белмәүдә, шушы рәхәтлекләрне татымауда гаепләсә, икенчеләренең исә белеп тә искечә, бедуинча яшәүне алга сөрүләреннән көлә.

Әбу Нәүвас тардият – аучылык шигырен аерым жанр итеп гарәп әдәбиятына кертеп җибәрә, бу да аның яңалыгы булып тора. Гомеренең көзендә, бәйрәми тормыш алып бара алмаслык хәлгә килгәч, Аллаһка якыная, гөнаһларын таный, ярлыкау сорый, шул рәвешле зөһдият жанрына да мөрәҗәгать итә. Аның бу әсәрләре исламгача чор зөһдиятеннән шактый аерыла. Алар моң һәм сагыш белән, курку һәм үзен гаепле санау белән сугарылган.

Иң төп һәм яраткан жанры – хәмрият. Шәраб аның өчен – яшәү мәгънәсенә, идолына әйләнгән. Ул аның өчен хәтта диннән, Аллаһтан да баш тарта. Аракы, шәраб эчкән һәркемне яхшы, хөрмәтле кеше саный, яңа заман кешесе дип атый. Аңа шәраб шулкадәр якын һәм кадерле ки, аны исенә

төшергән һәрнәрсәне ярата. Аны һәр авыруга, һәр кайгыга дәва дип исәпли. Ул булмаса, тормыш ямьсез, мәгънәсез тоела.

**Әбу әл-Әтәхийә (748-825) –** балачагын, яшьлеген Куфада үткәрә. Күңел ачулар, маҗаралы бәйрәми тормышны үз итә, шундый ук кешеләр белән дуслашып, гомеренең бер өлешен мәҗлесләр күрке булып уздыра. Үзендә шагыйрьлек талантын сизеп алып, шигърияткә тартыла, исеме таныла. Талантын сарайга хезмәткә багышларга ниятләп, Багдадка килә. Әсәрләре белән Мәхди халифәнең күңелен җәлеп итә, аның дустына, табындашына һәм җырчысына әверелә. Хәлифәне мактап, күп мал, байлык туплый. Төп жанры – зөһдият.

**Элеккеге традицияләрне торгызу өчен көрәшүче әдәбият.** Төрле этник компонентлардан торган, бердәмлеккә ия булмаган халифәлек җайлап таркалуга йөз тота. Моңа шугубиячеләр дә зур этәргеч ясый. Шул вәзгыятьтә гарәпләрнең элеккеге авторитар рольләрен кайтаруны таләп иткән консерватив элементлар да баш күтәрә башлый. Шундый ук реакция үзен әдәби хәрәкәттә дә сиздерә. Үткәндәге традицияләргә кайтуга йөз тоткан әдәбиятчылар яңалык өчен көрәшүчеләрнең төп дошманнарына әйләнә. Язучы һәм шагыйрьләр беренчеләрдән булып эшлекле адымнарга баралар, борынгы гарәп поэзиясенең антологиясен төзиләр, гарәп поэтикасы, гарәп стилистикасы закончалыкларын ныклап өйрәнүгә алыналар.

Борынгы гарәп поэзиясе үрнәкләрен җыеп, антологияләр төзүчеләрдән иң танылганнары – Әбу Тәммам һәм Әл-Бухтури ( Әбу Тәммамның укучысы) исемле шагыйрьләр. Алар икесе дә исламгача һәм ислам таралган чордагы гарәп шигърияте үрнәкләрен туплап, “Батырлык китабы”дип исемләнгән антологияләр тәкъдим итәләр. Гарәпләрнең батырлыклары хакындагы әсәрләр беренче бүлеккә тупланганлыктан җыентыкка шундый исем бирелгән. Әбу Тәммамның үз шигырьләре, нигездә, традицион характерда. Ул риторика белән кызыксына, архаизмнарга еш мөрәҗәгать итә, гадәти булмаган образлар, томанлы ассоциацияләр белән мавыга, шунлыктан аның

әсәрләре киңкатлау укучы өчен аңлаешсыз да була. Иң яхшы әсәрләре пейзаж лирикасына карый.

Үткәндәге традицияләрне кире кайтару юнәлешенең тагын бер күренекле әдибе – **әл-Җәһиз** (775- 868). Басрада туа, кечкенәдән үк әдәби иҗатка тартыла, Басра мәчете каршында эшләп килүче әдәбиятчылар түгәрәгенә йөри, төрле галимнәр белән аралаша, болар аның дөньяга карашы формалашуга зур этәргеч ясый. Соңрак Багдадка килеп урнаша, биредә төрле фәннәрдән белемнәрен тирәнәйтә, математика, лингвистика, дин гыйлеме, медицина, фәлсәфә белән кызыксына. Багдадта әдәби иҗатын да башлап җибәрә.Тиз арада танылып та өлгерә. Аның шагыйрьлек маһирлыгы әл-Мәэмүн халифәгә дә барып ирешә, үзенә хезмәткә чакыра. Ләкин Җәһиз сарай шагыйре булып озак тормый, бу эшне калдырып китә. Олыгайган көнендә аны паралич суга, риваятьләргә караганда, башына киштәдән китап төшеп, якты дөнья белән саубуллаша.

Җәһиз- энциклопедик галим, ул 200 якын төрле фәнни өлкәләргә (фәлсәфә, дин гыйлеме, сәясәт, икътисад, социология, тарих, геграфия, зоология, этнография һ.б) караган хезмәтләр авторы. Күпсанлы әдәби әсәрләре арасында “Сараннар турында китап” дип исемләнгәне аеруча популярлык казана. Саран кешеләр турындагы төрле мәзәкләрне, хикәятләрне үзенә туплаган бу җыентык гарәпләр белән ярышкан фарсыларга багышлана. Фарсыларның кыргыйлыклары, киракссезгә акча туздырулары, тәртипсез бәйрәми тормышлары, әхлаклы, юмарт, кунакчыл бәдәвиләргә каршы куела. Бу сатирик әсәр IX йөзнең беренче яртысындагы халифәлек тормышына бәя булып яңгырый.

Җәһизәсәрләре - гарәп әдәбияты тарихында заманча темага язылган беренче проза үрнәкләре. Аның иҗаты гарәп прозасының аннан соңгы үсешенә зур йогынты ясый.

Х йөздә гарәп халифәлегенең таркалу процессы төгәлләнә. Ләкин бу вәзгыять әдәбият үсешенә уңай тәэсир ясый, Багдадтан тыш тагын мәдәни һәм әдәби үзәкләр калкып чыга. Бу яктан – саманидлар дәүләтенең шундый мәркәзләре саналган – Бохара һәм Сәмәрканд аерылып тора. Аларда һәм гарәп, һәм фарсы телендәге әдәбият чәчәк ата. Бу чорда гарәп телле әдәбиятның үсешен төрле халык вәкилләре тәэмин итә. Гарәпләрнең үзләреннән бу чорда Әл-Мөтәнәбби, Әбу Галә әл-Мәгарри кебек данлыклы шагыйрьләр үсеп чыга. Мәкам жанры, проза үсеш кичерә.

**Түбәндәге сорауларга җавап бирегез:**

1. Дүрт тугрылыклы халифә, өммәвиләр, габбасыйлар чоры әдәбиятының һәркайсына кыскача сыйфатлама бирегез.
2. Ислам таралган чордагы гарәп әдәбиятының максатын һәм адресатын ачыклагыз.
3. Бәдәви лирикасы шәһәр лирикасыннан ни белән аерыла?
4. Шәһәр лирикасының күренекле вәкилләрен атагыз?
5. Сәяси көрәш поэзиясен башкача ничек атарга мөмкин?
6. Габбасыйлар чоры әдәбиятының төп үзенчәлеге нәрсәдә?
7. Әбу Нәүвас, Бәшшәр ибн Бурдлар иҗаты хакында ниләр исегездә калды?
8. Шугубиячеләр хәрәкәтенә шәрехләү сорала.

## Тема №4. Яңарыш чоры фарсы әдәбияты. Классик период.

**Аннотация.** Әлеге тема яңарыш чоры фарсы әдәбияты хакында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Яңарыш чоры фарсы әдәбиятындагы төп поэтик формалар, бу чор әдәбиятының асыл сыйфатлары, күренекле әдипләрнең иҗат мирасы мәсьәләләре карала.

**Ачкыч сүзләр**: фарсы әдәбияты, касыйдә, газәл, робагый, Рудакый, Фирдәүси, Хәйям, Әбугалисина, “Шаһнамә”, шугубия хәрәкәте.

**Методик күрсәтмәләр:**

- Лекция өлешендә теманың төп мәсьәләләре карала, иң әһәмиятле моментларга басым ясала.
- Теманы тагын да яхшырак ачу максатыннан төп һәм өстәмә әдәбият, текстлар, интернет ресурслар тәкъдим ителә.
- Теманы үзләштерүне тикшерү максатыннан якынча сораулар урнаштырыла.
- Сорауларга телдән дә, язмача да җавап әзерләргә мөмкин.

**Түбәндәге интернет ресурслар тәкъдим ителә:**

1. http://ru.wikipedia.org
2. http://www.publ.lib.ru
3. http://www.coollib.net
4. http://www.sattor.com
5. http://www.newskif.su
6. http://www.royallib.ru
7. http://www.vostlit.info
8. http://www.pero-simurga.ru

## Әдәбият


1. Андреева И.И. Древние и средневековые литературы народов СССР. - Ч.1.
2. Брагинский И.С. 12 миниатюр. От Рудаки до Джами. 2-ое изд., дополн. - М.: Худ.лит., 1976. - 302 с.
3. Восточная поэзия. - М.: Терра - Книжный клуб, 2002. - Т.1. - 511 с.; Т.2. - 511 с.
4. Ганиева Р.К.Литература Востока (классический период). Расширенная программа лекционного курса / Р.К.Ганиева. – Казань, 2004.
5. Рейснер М.Л. Литература Ближнего и Среднего Востока: учебно-методическая разработка / М.Л.Рейснер. - Казань, 2003.

6. Таджикско-персидская поэзия X-XV вв. - Казань, 1990. - 184 с.
7. Золотая поэзия Востока.- Симферополь: Реноме, Харьков: Свитовид, 2001.-368 с.

**Текстлар:**

1. Гомәр Хәйям. Робагыйлар /Н.Арсланов тәрҗ.. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1986. - 143 б.
2. Илһамнар чишмәсе. Дөнья шигърияттеннән. Әхмәт Исхак тәрҗемәләре.- Казан.:Тат.кит.нәшр., 1985. - 344 б.
3. Литература народов СССР. Составитель Л.И.Климович. Часть первая (азерб, таджик., туркмен.лит.). - М.: Просвещение, 1971. - 520 с.
4. Фирдәүси Әбелкасыйм. Шаһнамә / Мәсгуд Гайнетдин тәрҗемәсе.- Казан: Тат.кит.нәшр., 2003. – 231 б.

**Глоссарий.**

**Азадә –** фарсы әдибеӘбелкасыйм Фирдәүсинең “Шаһнамә” эпопеясындагы иран шаһы, ау остасы Бәһрәм Гүрнең сөеклесе. Бәһрәм Гүр- Азадә сюжеты Шәрык дөньясында бик популяр була. Әдәби әсәрләрдә генә түгел, рәсем һәм сынлы сәнгатьтә дә еш очрый, савыт-сабаларга, келәмнәргә аларның рәсемнәрен бик яратып төшергәннәр.

**Ахриман** – “Шаһнамә” эпопеясыннан – начарлык Алласы.

**Ахурамазда -** “Шаһнамә” эпопеясыннан –яхшылык Алласы.

**Афак –** Низами Ганҗәвинең хатыны, аның күп әсәрләренең прототибы.

**Әбугалисина** - *Әбу Гали Хөсәен ибн Габдулла ибн Хәсән ибн Сина – Авиценна* – (930-1037)-Шәрык һәм Гаребнең атаклы энциклопедисты, ренессанс хәрәкәтен фән өлкәсенә кертеп җибәргән галим. Табигать фәннәре белгече, философ, табиб, математик, шагыйрь.

**Әфлатун** – грек фәлсәфәчесе Платонның гарәпчә әйтелеше. Шәрык һәм төрки халыклар арасында шул әйтелеш таралыш алган.

**Бәһрәм** – сасанидлар династиясенең легендар шаһы, ау остасы, коланнар (онагра – партояклы булмаган ат төре) аулау белән мавыкканлыктан Бәһрәм Гүр дигән тәхәллүс бирелә (Гүр – коланның фарсыча әйтелеше). Шәрык Дон-Жуаны булып танылган бу шәхес сөеклесе Азадә белән “Шаһнамә” поэмасыеда бирелә.

**Газәл-** гарәп шигъриятендә дөньяга килгән, фарсы, төрки әдипләре тарафыннан яратып кулланылган, 12 бәеттән артмаган поэтик форма, төп юнәлеше – лирик нигезле мәхәббәт җырлары, еллар узган саен иҗтимагый-фәлсәфи эчтәлекле газәлләр ешрак очрый

**Заххак** – Фирдәүсинең “Шаһнамә” поэмасыннан, иран шаһы Җәмшитне тәхеттән төшергән мифик идарәче, Иблиснең хезмәтчесе, Заххакның җилкәсеннән үсеп чыккан тынгысыз еланнар яшь егетләрнең мие белән туклана. Мең еллап идарә иткәннән соң бу елан патшаны бастыралар.

**Зәрдәштилек** - зароостризм – Авеста- ягъни утка табынучылар дине, фарсылар исламга кадәр шул динне тотканнар.

**Искәндәр** – Александр Македонский.

**Каюмарс** –иран тарихындагы беренче легендар идарәче, кешеләргә цивилизация бүләк иткән шәхес, Фирдәүсинең “Шаһнамә” поэмасыннан.

**Рөстәм** – иран халкының җиңелмәс батыры, каһарманы, Фирдәүсинең “Шаһнамә” поэмасының баш геройларыннан берсе.

**Рәхш** – Рөстәмнең пәһлевандай аты.

**Робагый** – дүртьюллык шигъри әсәр, фарсы әдәбиятында туа, осталары- Рудакый, Г.Хәйям. Нааба – шәкелендә рифмалашучы әлеге лирик форма еш кына фәлсәфи уйлануларга корылган була.

**Рудакый-** Әбу Абдулла Җәгъфәр ибн Мөхәммәд ибн Хәким ибн Габдрахман ибн Адәм Рудакый Сәмәрканди (860-941)- фарсы яңарыш әдәбиятының нигез ташларын салучы, фарсы шигъриятенең солтаны, күренекле шагыйрь, җырчы һәм музыкант. Рудакый иҗатының төп кыйбласы - шәхеснең азатлыкка омтылышын яклау, мәхәббәт культына дан җырлау, кешене олылау.

**Туранлылар**- төрки кабиләләр.

**Фәридун** – Җәмшит нәселеннән булган, тиңдәшсез байлыкка ия легендар иран шаһы. Фирдәүсинең “Шаһнамә” поэмасыннан.

**Фирдәүси -**Хәким Әбелкасыйм Мансур Хәсән Фирдәүси Туси- фарсы яңарыш әдәбиятының күренекле вәкиле, исламгача булган Иран тарихын яктырткан дөньякүләм яңгырашка ия “Шаһнамә” эпопеясының авторы. **Хәвәран** –көнчыгыш Иран.

**Хәйям** - Ибраһим Гомәр Хәйям (1048–1123) – галим, философ, фарсы яңарышының күренекле шагыйре, робагыйлар остасы.

**Хәлия**– үз хәлеңне язу, язмышка зарлану, касыйдәнең жанр формасы.

**Хөрәсән** – төньяк-көнчыгыш Иран.

**Шикия** – сөйгән ярны мактау, касыйдәнең жанр формасы.

**Шугубиячеләр** (шугубиты) **–** нигездәиранлылардан(фарсылар) торган, сәяси һәм мәдәни тигезлек өчен көрәшүчеләр, ислам дине кабул иткән халыкларның тигез хокуклы булуларын таләп итәләр, хәтта фарсыларның һәм гарәп булмаган башка халыкларның өстенлеген дәгъвалыйлар һәм бу юнәлешкә шугубия хәрәкәте дигән исем бирелә.

**Яздигерд** (420 елда вафат) –Сасанидлар династиясеннән булган иран шаһы.

**Лекция №1. Фарсы әдәбиятындагы ренессанс тарихы**

Өйрәнү өчен тәкъдим ителгән сораулар:

1. Фарсы яңарыш әдәбияты вәкилләре.
2. Рудакый поэзиясе.
3. Әбугалисина иҗаты.

**Лекция №4. Фарсы әдәбиятындагы ренессанс тарихы**

1. Фарсы яңарыш әдәбияты вәкилләре.
2. Рудакый поэзиясе.
3. Әбугалисина иҗаты.

## 1. Фарсы яңарыш әдәбияты вәкилләре

Фарсы әдәбияты - иң борынгы һәм иң бай әдәбиятларның берсе. Исламга кадәрге чорда зәрдәштилек – утка табынучылар динен тоткан бу кавем элек-электән җор телле, көйле, моңлы, аһәңле халык булып формалашкан. Исламга кадәр үк бай тарихлы әдәбиятлары булса да, төрле басып алулар, исламлаштыру процесслары аларның күбесен юкка чыгарган. Фарсыларда мөселман фәлсәфәсе бары 10-11 йөзләрдә генә киң таралыш ала, шуңа күрә әдәбиятта чагылышы да шул чордан гына күзәтелә. Аңарчы язылган әсәрләрдә зәрдәштилек – Авеста дине басымы шактый сизелә.

Габбасыйлар чорында (750-9 гасыр) фарсы теле бөтен Үзәк Азия территориясендә дәүләт теле һәм әдәби тел дәрәҗәсенә күтәрелә. Шушы вакытта яңартылган фарсы теле барлыкка килә. Аның шул рәвешле үзгәреше Рудакый, Фирдәүси, Унсури, Дакыйки кебек әдипләр иҗаты белән бәйле. Чөнки алар телне һәм элеккеге традицияләрен янәдән торгызу өчен үзләренең иҗатларында исламга кадәрге милли кыйблаларына мөрәҗәгать итәләр.

Бу чор әдипләре гарәп йогынтысыннан тәмам арыган, үз милли рухларын, милли традицияләрен саклап калу өчен көрәшкә күтәрелүчеләр буыны. Алар гарәп телендә иҗат иткән Бәшшәр ибн Бурд, Әбу Нәүвас традицияләрен дәвам итүчеләр, алар иҗатындагы дөньявилык, тормыш ямен җырлау шуннан килә.

Фарсы әдәбиятының матурлыгы, аһәңлеге дә халыкның яшәеше, гореф-гадәтләренә, халкының нечкә рухлы, нечкә күңелле, нәзакәтле булуына да бәйләнгән. Бер-берсе белән сөйләшкәндә дә шигъри телдә аралашу, рифмалы сөйләмгә мөрәҗәгать итү – акыллылык, зыялылык билгесе саналган. Мисалга, Әбугалисинаның бик күп сандагы медицинага караган хезмәтләре поэтик формада язылган.

Яңа фарсы телле шигъриятнең башлангыч чоры тулысынча диярлек сарай әһелләре идеологиясенә һәм аларның мәнфәгатьләрен кайгыртуга

корылган була. Шагыйрьләр бик зур дәрәҗәгә ия булып, аларның уң куллары саналган, хакимият эшләренә дә турыдан-туры катнашканнар. Мактау формаларыннан касыйдә иң популяр җанрлардан санала, шулай ук робагыйлар да бик яратып тыңланган.

Иран әдәбияты белгечләре классик фарсы шигъриятен 4 төркемгә бүлеп карыйлар: ***хөрәсән, азәрбәйҗан, гыйрак*** һәм***исфаһан*** төркемнәре.

**а)** Хөрәсән стилен тудыручылар: Әсҗади, Фаррухи, Рудакый, Дакыйки, Фирдәүси һ.б.

б) Азәрбәйҗан юнәлеше вәкилләре: Катран Тәбризи, Низами Гәнҗәви, Хакани Ширвани, Фалаки Ширвани һ.б.

в) Гыйрак стиле әдипләре: Сәнаи, Гаттар, Руми, Сәгъди, Хафиз һ.б.

г) Исфаһан юнәлешенә караучы шагыйрьләрдән иң танылганы – Әмир Хөрәү Дәһләви.

**2. Рудакый поэзиясе.**

Рудакый - *Әбу Абдулла Җәгъфәр ибн Мөхәммәд ибн Хәким ибн Габдрахман ибн Адәм Рудаки Сәмәрканди*(860-941)- фарсы яңарыш әдәбиятының нигез ташларын салучы, фарсы шигъриятенең солтаны, күренекле шагыйрь, җырчы һәм музыкант.

Булачак шагыйрь хәзерге Таҗикстан территориясендәге Зарафшан тавында урнашкан Пәнҗ Рудак (фарсы телендә - биш инеш д.аңалата) авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Кечкенәдән үк аны халык музыкасы, халык көйләре тәрбияли, ә туган җиренең искиткеч гүзәл табигате аны иҗатка илһамландыра. Яшьлегендә үзенең матур тавышы, шигъри таланты, төрле музыка инструментларында уйнавы белән популярлык казана. Наср II Әхмәд Сәмәнид (913-943) тарафыннан сарайга чакырыла, 40 ел буена Бохарада сарай шагыйре булып торган. Урта Азия һәм Хөрәсәндәге әдәби үзәкләр белән җитәкчелек иткән, яшь иҗатчылар тәрбияләгән, бу аның дәрәҗәсен бик нык күтәргән. Яшьлегендә шөһрәтле шагыйрь, олыгайгач,

сарай әһелләре белән конфликтка керә. Аны, күзләрен утлы кисәү белән актарып чыгарып, сарайдан куалар. Яшьлегендә бай яшәп, сөяркәләр тоткан шагыйрь хәер сорашырга кала. Моннан соң инде озак яшәми, туган җиренә кайтып, шунда вафат була.

Безнең чорга килеп җиткән чыганаклар аның шул чор поэтикасының барлык жанрларында да иҗат иткәнлеге хакында сөйли. Ул робагыйлар, касыйдәләр, мәдхияләр, газәл һәм  мәснәвиләр, кыйтгалар, дидактик поэмалар, сатирик шигырьләр һәм мәрсияләр дә язган. Шулай ук тәрҗемә белән дә шөгыльләнгән. Шундый тәрҗемәләрнең берсе – “Кәлилә вә Димнә”, икенчесе – “Синдбад маҗаралары”.

Рудакый иҗатында ислам диненә бәйле мотивлар урын алмый. Бу чор әдипләре гарәп йогынтысыннан тәмам арыган, үз милли рухларын, милли традицияләрен саклап калу өчен көрәшкә күтәрелүчеләр буыны. Алар гарәп телендә иҗат иткән Бәшшәр ибн Бурд, Әбу Нәүвас традицияләрен дәвам итүчеләр, алар иҗатындагы дөньявилык, тормыш ямен җырлау шуннан килә.

Рудакый иҗатының төп кыйбласы - шәхеснең азатлыкка омтылышын яклау, мәхәббәт культына дан җырлау, кешене  олылау.

Рудакый табигать матурлыгын, гүзәл кызлар матурлыгын мактый, шулай ук шәраб мотивлар күзәтелә.  Аның “Шәраб анасы”  дигән поэмасы бар. Әлеге  әсәрдә виноград өлгергәннән алып шәраб булып ясалу мизгеленә кадәр  күзәтү ясый. Аныңча яхшы кешене әхлаклы итә, яманны  аздыра. Рудакый киләчәктә мәйданга чыгачак, шәрабне мактаячак хәйямчелек хәрәкәтенең башында торучылардан. Бу юнәлешнең нигез ташын габбасыйлар чоры гарәп телле фарсы әдипләре салганлыгы мәгълүм.

Рудакый – мәхәббәт җырчысы. Аның канатлы сүзләре афоризм дәрәҗәсенә җиткерелгән. Аның мәхәббәт робагыйларында  сәнгатилек бик тә югары. Еш кына үзенең робагыйларын сорау-җавап рәвешендә яза. Аның мәхәббәт турында  икеюллыклары, ягъни бәет – афоризмнары да бар.

Ул  мәхәббәтне романтикларча яктырта. Мәхәббәт ул - мәңгелек матурлык, ди. Үзен шул матурлыкның  пәйгамбәре дип игълан итә.  Шуңа

күрә аның лирик герое михрабтан баш тартып, үзен Бохара гүзәлләрен ратуга, алар алдында сәҗдә кылуга багышлый.

Рудакый өчен матурлыктан башка илаһи зат юк. Һәм шагыйрь шушы матурлыкның пәйгамбәре. Аныңча, матурлыкны акыл белән генә үлчәп бетереп булмый, аны җан белән ярата белергә кирәк. Мәхәббәт турындагы шигырьләрендә ул хәдисләрдәге һәм Коръәндәге фикерләрне кабатлый. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әйткән сүзе: “Аллаһ үзе гүзәл, ул матурлыкны ярата. Шуңа күрә кешеләр дә матур булырга тиеш”. Бу фикерләр Рудакыйда да, Хәйямдә дә, Хафизда да, Фөзулида да дәвам итә.

Кайбер шигырләрендә ул грек фәлсәфәчеләре белән, аларның акылны мактаулары белән бәхәсләшеп ала. “Грекларның акыл фәлсәфәсе саегып килә, без кеше җанын олылыйк” дип чакыра. Шулай итеп, аның иҗатында матурлык эстетикасы өстенлек алып тора.

Рудакый иҗат ахырында иҗтимагый-социаль мотивларга да өлеш чыгара. Сукырайган, бөлгенлеккә төшкән шагыйрь тормыш гаделсезлекләрен тәнкыйть итә. Шулай ук иҗатына фәлсәфи мотивлар да үтеп керә. Аныңча дөнья, галәм гел үзгәрештә, яңа әйберләр искесе белән алышына. Кайчандыр матур бакча урынында чүл җәелеп ята, сахралар урынына шәһәр үсеп чыга һ.б.

Рудаки – классик гарәп касыйдәсен үзгәртеп, касыйдәнең башка бик күп төрләрен аерып тәкъдим итә һәм аларның һәрберсе мактау жанры булып тора, һәрберсе аерым атамага ия була. Моңарчы билгеле булган бәһария, фәһрия, мәдхия, мәрсия, хәмрия, һөҗвиядән тыш, ул тагын ***хәлия*** – үз хәлеңне язу, язмышка зарлану, ***шикия*** – сөйгән ярны мактау кебек төрләрен дә аерып чыгара.

Рудакый шигърияте киләчәк буын фарсы- таҗик шагыйрьләренә, гомумән үзеннән соңгы бөтен Шәрык поэзиясенә зур йогынты ясый. Ул – фарсы яңарыш әдәбиятына гына түгел, классик шигърияткә нигез салучы. Фирдәүси, Хәйям, Сәгъди, Хафиз кебек фарсы классиклары, тагын бик күп буын Шәрык әдипләре аны үзләренең Остазы дип таныйлар.

**3. Әбугалисина иҗаты.**

Әбугалисина - *Әбу Гали Хөсәен ибн Габдулла ибн Хасан ибн Сина – Авиценна* – (930-1037)-Шәрык һәм Гаребнең атаклы энциклопедисты. Ренессанс хәрәкәтен фән өлкәсенә кертеп җибәргән галим. Табигать фәннәре белгече, философ, табиб, математик, шагыйрь. Чыгышы белән иран таҗикларыннан. Белемне Бохарада ала. Балачактан ук гыйлемгә омтылышы белән үк укытучыларны шаккатырган. Үзенең автобиографиясендә “мин 18 яшемә җиткәндә бөтен гыйлемнәрне үзләштереп бетердем” дип яза. 16 яшендә зур табиб буларак таныла, Бохара әмире Мансурны дәвалый, бу аңа олы дан китерә һәм киләчәк яшәешенә зур йогынты ясый.

Ул әмир дә, вәзир дә булып торган, патша яуларында да катнашкан. Төрек солтаны Мәхмүт Газнәви эзәрлекләвеннән качып, Урта Азия, Әфганстан территорияләрендә яшәгән.

Ибн Сина үзенең бар гомерен, бөтен көчен хезмәткә багышлаган, аз йоклаган, күп эшләгән. Галәм серләрен, кеше тәне серләрен өйрәнгән. 450гә якын хезмәт язган, безнең көннәргә шуны 240 исемдәгесе килеп җиткән.

Әбугалисина – атаклы философ. Ул - Платон, Аристотель һәм башка грек философларының хезмәтләрен Шәрык җирлегенә җайлаштырып иҗади эшкәртүче һәм комментарийлар язучы. Аны кеше акылына мәдхия укыганы өчен Шәрыкнең икенче Аристотеле дип йөрткәннәр. 182 фәлсәфи хезмәт язган. Әмма аларның күбесе безнең көннәргә килеп җитмәгән. 20 томлык энциклопедик трактаты югалган, шулай ук күптомлы “Гаделлек” дигән китабы, “Шәрык фәлсәфәсе” хезмәтләре юкка чыккан.

18 томлык “Китабе әш-шифаэ” хезмәте сакланып калган. Платон, Аристотель кебек ул да галәмнең барлыкка килүен неоплотонизм фәлсәфәсенә таянып аңлата. Әбугалисина элеге философларның терминологиясен эшли. Фәндә кем ул Авиценна – неоплотоникмы? Әллә перипатетикмы? дигән бәхәсләр бара. Аристотель фәлсәфәсе тарафдарларын перипатетиклар дип атыйлар. Әбугалисина – икесенең дә тарафдары.

Аныңча, галәмне беренче сәбәп – Аллаһ иҗат иткән, аннары эмонация рәвешендә галәмнең акылын, галәмнең акылыннан аның җанын, иң соңыннан материяне барлыкка китергән.

Аристотель кебек, галәмнең зур акылы бик күп кечкенә акылларга бүленә, дип исәпли. Галәмнең җаны белән дә шул ук күренеш. Аның фикеренчә, андагы һәр нәрсә сәбәпле бәйләнештә. Кеше үзенең акылы, хисләре белән дөньяны таный ала. Бу фикерләре белән шулай ук Аристотельне хәтерләтә. Шул ук вакытта фәлсәфәсенең күп яклары белән Әфлатунга (Платонга) барып тоташа. Аныңча, акыл белән җан берлеге рухны тәшкил итә. Безнең акылыбыз, нәфесебез – тормыш символы. Җанның канаты – акыл.

Әбугалисина фикеренчә, кеше – иҗтимагый хайван, бу – Аристотельдән килә. Кешеләрнең җанлы яшәве өчен аралашу, хезмәттәшлек, гадел хөкем һәм башка законнар булырга тиеш. Дәүләт белән гадел хөкемдар идарә итәргә тиеш. Кешеләр исә, иҗтимагый файдалы эш белән шөгыльләнергә тиешләр.

Җәмгыятьтәге кешеләрне 3 төркемгә бүлә:

1) администраторлар
2) җитештерүчеләр
3) сугышчылар.

Бу карашны исә Платоннан (Әфлатун) алган. Әфлатун исә, җир кешеләрен фикер ияләренә, сугышчыларга һәм һөнәрчеләргә бүлгән.

Ибн Сина кеше бәхете – мәхәббәттә дип саный.

Аның иң атаклы китабы – “Әлкануне фиттыйбби” (“медицина кануннары”). Бу китап 18 гасырга кадәр Европа университетларында дәреслек вазифасын башкарган. Бу хезмәттә ул грек, рим, һинд, Урта Азия врачларының табиблык эшчәнлекләренең нәтиҗәләрен гомумиләштергән. Анда табиблык алымнары, медицина фәненең нигезләре, кеше төзелеше, сәламәтлек нигезләре, авыру төрләре тасвирлана. Ул бигрәк тә дөрес

туклануга игътибар итә, картлыкның, яшьлекнең медицина күзлегеннән күп кенә серләрен ача.

Медицинага багышланган 9 томлык поэмасы бар. Врач буларак, фәнни эзләнүләрен, дин әһелләреннән кача-кача, зиратларда алып барган. Кеше анатомиясен өйрәнү аңа бик күп авылыклар да тудырган. Кадимчеләр аны туктаусыз эзәрлекләгән, дәһри дигәннәр.

Иң танылган шигъри әсәре – җан турындагы касыйдә. Анда кеше җаны галәм җанының бер кисәге, бер нуры итеп санала. Касыйдә һәм робагыйларында фәнни эшчәнлегендәге терминнар белән эш итә. Иҗатында фәлсәфи һәм фәнни терминнарның күп кулланылуы белән аерылып тора. Материянең мәңгелеге, Аллаһ белән табигатьнең бергәлеге турында пантеистик фикерләр үткәрә.

Белемсез дин әһелләрен һәрвакыт тәнкыйть итә, аларны ишәк белән чагыштыра, бу традиция тукайгача дәвам итә. Аныңча, кеше үзен мөмкин кадәр белем белән баетырга тиеш, кеше гомер буе камиллеккә ирешергә тырышырга тиеш. Ибн Сина “минем дөньяда 2 дустым бар ди: берсе – кара савыты, икенчесе – виноград суы”.

Әбугалисина әдәбият теориясе буенча да хезмәтләр калдыра. Аристотель «Поэтика»сына комментарийлар язган, гарәп шагыйре ибн әр-Руминың шигырьләрен шәрехләгән. Үзенең фәлсәфи повесте да бар. Ул әсәрендә Әбугалисина нур фәлсәфәсе, неоплотонизм тарафдары буларак чыгыш ясый.

Әбугалисина - дөнья фәненә зур йогынты ясаган шәхес. Ул фәндә дә, мәдәният өлкәсендә дә мәңгелек образларның берсе.

Ул көнбатыш Иранда, Хамадан шәһәрендә күмелә. Кабере өстенә мавзолей корылган.

Татар әдәбиятында Әбугалисина образы белән К.Насыйри кыйссасында, Н.Исәнбәтнең 5 пәрдәлек драмасында танышырга мөмкин.

**Түбәндәге сорауларга җавап бирегез:**

1. Фарсы яңарыш әдәбияты кайчан башлана?
2. Фарсы классик әдәбиятының нинди юнәлешләрен беләсез?
3. Фарсылар исламга кадәр нинди дин тотканнар?
4. Авеста- зәрдәштилек диненең классик фарсы әдәбиятында чагылышы хакында ниләр әйтә аласыз?
5. Рудакый фарсы әдәбиятына нинди яңалык алып килә?
6. Фарсы касыйдәсенең нинди жанр төрләре исегездә калды?
7. Кем ул Әбугалисина? Аның әдәбиятка нинди катнашы бар?

**Лекция №2. Фарсы әдәбиятындагы ренессанс тарихы**

Өйрәнү өчен тәкъдим ителгән сораулар:

1. Әбелкасыйм Фирдәүси иҗаты.
2. Г.Хәйям шигърияте.

## 1. Әбелкасыйм Фирдәүси иҗаты

Фирдәүси -*Хәким ӘбелкасыймМансур Хәсән Фирдәуси Туси*- фарсы яңарыш әдәбиятының күренекле вәкиле. Туган-үлгән еллары турында ике төрле фараз яши: (932-941-1022-1030).

Фирдәүси ярлы гына аристократ гаиләсендә туа, заманы өчен яхшы белем ала. Ул Сарай шагыйре булмаса да, үзенең иң зур дөньякүләм танылган “Шаhнамә” поэмасын социаль заказ буенча яза. Ул 40 меңнән 120 меңгә кадәр бәетне үз эченә ала, 15 том тәшкил итә. Хәзерге көндә әсәрнең фарсыча 9 том, русча – 6 том басылып чыккан варианты бар. Татар телендә М.Гайнетдин тәрҗемәсендә танышырга мөмкин.

“Шаhнамә” – дөньякүләм яңгырашка ия шигъри эпопея. Төп проблемасы: туган илгә, җиргә, аның халкына мәхәббәт, үз телеңне, тарихыңны, гореф-гадәтләреңне ярату.

“Шаһнамә”не тарихи ихтыяҗ итудыра. 7 гасыр уртасында иранлылар гарәпләр тарафыннан басылып алыналар, үз телләрен, әдәбиятларын, мәдәниятләрен югалту дәрәҗәсенә килеп җитәләр. Фирдәүси “Шаһнамә”не язганда Иран халкы янәдән бәйсезлеген югалту алдында тора. X-XII гасырларда иранлылар яшәгән җиргә төркиләр: газнәвиләр, караһанилар, сәлҗүкләр үтеп керә. Әсәр гарәпләр һәм төркиләр басымы астында калган иранлыларның үз дәүләтчелекләрен саклап калу омтылышы ихтыяҗы нәтиҗәсендә язылган.

Иранда элеккеге мирасны, традицияләрне (возрождение) кайтару хәрәкәте башлана. Бу хәрәкәт шугубийә хәрәкәте дип атала. Әлеге хәрәкәт нәтиҗәсендә күп ходайнамә, шаһнамәләр барлыкка килә. Әлеге “Шаһнамә”не Дакыйки исемле яшь сарай шагыйре яза башлый. Ләкин ул үзенең колы тарафыннан үтерелә. Аның эшен олы яшьтәге Фирдәүси дәвам итә. Ул бу эпопеяны 20 елдан артык язган, дип исәплиләр. Ул әсәрне Иран патшалары – саманидлар династиясе хакимлек иткәндә яза башлап, төрекләр (газнәвиләр) идарә иткәндә тәмамлый. Димәк ният ителгәндә “Шаһнамә” саманидларга багышланган булса, ахырда Мәхмүд Газнәви – төрек солтанына юллап тәмамларга мәҗбүр була.

Әлеге поэманы укыганчы Мәхмүт Газнәви бик күп алтын, күп акча вәгъдә иткән булса да, укыгач, көмеш тиеннәр генә җибәрә. Нәтиҗәдә ике арада зур конфликт туа, М.Газнәви аны филләр астында таптатып үтерергә боера. Фирдәүси шактый вакытлар качып йөрергә мәҗбүр була.

Вафатыннан соң, Фирдәүсине дәһри (динсез) дип, мөселман зиратына күмдермиләр, үз бакчасына күмәләр. Әмма соңыннан ул урынга мавзолей куела.

“Шаһнамә” - гуманистик әсәр. Эпопея гади җир кешеләрен олылый, гадел патшаларга мәдхия укый, явыз патшаларны тамырларын корыту белән куркыта. Шагыйрь үзенең дине итеп кешелеклелекне атый.

Фирдәүси кан коюлы сугышларга каршы чыга. Эпопея нигезендә яхшылык белән явызлык көрәше ята. Бу этик төшенчәләр иранлылар белән

туранлылар (төрки) образларында символлаштырыла. Әсәрдә иранлылар изге, ә төркиләр – явыз көч итеп, иранлылар – ак атта, туранлылар – кара атта сурәтләнә.

“Шаһнамә”нең фәлсәфи-эстетик нигезе зәрдәштилек һәм Ислам дине фәлсәфәсенә барып тоташа. Мәгълүм булганча, Авеста дине үз халкын күтәреп, башкаларга түбәнсетеп карый. Һәм бу халәт “Шаһнамә”дә дә шактый сизелә. Фирдәүси шуны яшерегергә күпме генә тырышса да, төркиләргә булган тискәре мөнәсәбәтне М.Газнәви тиз тоеп ала. Рус һәм Иран тарихчылары тарафыннан Мәхмүт солтан - тиран патша итеп сурәтләнә, ә төрки тарихта эшчәнлеге уңай бәяләнә. Ул мәдәният, сәнгать кешеләренә яхшы мөнәсәбәттә була.

Әлеге әсәрдә гади кеше олылана һәм җирдәге тыныч тормыш яклана. Фирдәүсинең “Шаһнамә”се Аллага, патшага мәдхия уку белән башлана. Солтан М.Газнәвине мактаганнан соң, акылны мактаган бүлек китерә. “Шаһнамә” керештән, бетемнән һәм күләмнәре төрлечә булган өч бүлектән тора.

1. Мифологик бүлек.
2. Баһадирлар бүлеге.
3. Тарихи патшалар бүлеге.

Мифологик бүлектә борынгы иранның космогоник карашлары бирелә, дөнья яратылышы, легендар 4 патшаның - Каюмарс, Хушан, Тахмурас һәм Җәмшиднең изге гамәлләре сурәтләнә. Бу патшалар борынгы кешеләргә цивилизация алып киләләр. Кешеләрне тау куышларыннан куып чыгарып, җир эшкәртергә, сарык-мал асрарга, хайван тиресе ябыну урынына кием кияргә, ризыкны пешереп ашарга, көймә ясарга, суда йөзәргә өйрәтәләр. Шулай ук табиблык һөнәрен башлап җибәреп, халыкны төрле чирләрдән дәвалыйлар.

Мөселман дөньясында беренче атабыз Адәм галәйһиссәлләм саналса, мифологик бүлектә кешеләр нәселен башлап җибәрүче Каюмарс исәпләнә. Фирдәүси Адәмне телгә дә алмый.

Зәрдәштилек диннәренә мөнәсбәттә әсәргә яхшылык-яманлык Аллалары килеп керә. Ахурамазда – яхшылык Алласы, начарлык алласы – Ахриман.

Әсәрдә легендар патша Җәмшид иранлылар белән идарә иткән 700 ел Иранның алтын гасыры итеп санала. Гомеренең ахырында Җәмшид масаеп китә, “мин- дөнья хакиме” дип йөри башлый. Шуның өчен аңа Ходай Тәгалә җәза җибәрә, иран кабиләләре тормышына бер-бер артлы бәла-каза килә башлый. Җәмшид гарәпләрдән булган Заххак заманында туралып үтерелә.

Заххак- шайтан тарафыннан аздырылган, аның йогынтысына бирелгән кеше. Ул тәхеткә дә, шайтан котыртуы буенча, әтисен үтереп килә. Беренче мәртәбә иблис аңа кеше кыяфәтендә далада очрый һәм “Нигә кирәк илгә ике патша?” диеп, әтисен үтертергә күндерә.

Икенче тапкыр иблис патша сараена пешекче сыйфатында килә һәм Заххакның ашханәсе белән идарә итәргә алына. Элек вегетариан ашлары белән тукланган иранлыларга кош, хайван итләреннән әзерләнгән ризыклар ашата башлый. Тәмле ризыклар ашатканы өчен Заххак пешекче-иблискә җилкәләреннән үбәргә рөхсәт бирә. Ул үпкән җирдән ике елан үсеп чыга. Алар Заххакны бик борчый, бимазалый башлыйлар. Аптыраган, тилмергән патша янына Иблис өченче тапкыр табиб кыяфәтендә килә. Еланнарны тынычландыруның бердәнбер юлы төсендә яшь егетләрнең баш миеннән ризык пешереп ашатуны тәкъдим итә. Бу еланнарны тынычландыру хакына илдә бик күп яшь егетләр юк ителә. Иблиснең максаты – кешеләр нәселен юк итү.

Кавә исемле бер тимерченең 18нче улына чират җиткәч, бу хурлыкка түзә алмыйча, алъяпкычын байрак итеп, Елан патшага каршы көрәшкә күтәрелә. Халык восстаниясе Заххакы тәхеттән төшерә, аның үзен кыя-ташка кадаклап куялар. Аннары янәдән тәхеткә Җәмшиднең нәсел варислары килә.

“Баһадирлар бүлеге” - “Шаһнамә”нең төп өлешен алып тора. Анда, нигездә, Рөстәм һәм Сиявуш хакындагы дастаннар, хикәятләр китерелә. Рөстәм – 600 ел буена иран патшаларының гаскәре белән идарә итә. Ул – гадел, туры сүзле, азатлык яратучы хәрби башлык итеп гәүдәләнә.

Өченче бүлектә 28 реаль патша хакында сөйләнелә.

Фирдәүси поэмасы - героик эчтәлекле ренессанс әсәре. Шагыйрь, беренчеләрдән булып, Рөстәм кебек гадәттән тыш көчле каһарман образын иҗат итә. Әсәр күп яклары белән героик эпоска охшый. Ул үзеннән соңгы фарсы әдәбиятына, гомумән Шәрык әдәбиятына зур йогынты ясый. Аның нигезендә бик күп әсәрләр языла.

**2. Гомәр Хәйям иҗаты.**

Гомәр Хәйям - *Ибраһим Гомәр Хәйям* (1048–1123) – галим, философ, фарсы яңарышының күренекле шагыйре. Ул 1048 елның 18 маенда Нишапур шәһәрендә туа, шул шәһәрдә белем ала һәм үз чорының күп кенә эре уку йортларында, шул исәптән, Бәлх һәм Сәмәркандта да белем ала. Хәйям – тәхәллүсе - чатырлар тегүче дигәнне аңлата.

Гомәр искиткеч зирәк бала булып үсә, 8 яшендә чакта ук Коръәнне яттан белә, 12 яшендә Нишапур мәдрәсәсендә укый башлый. Соңрак, бик яхшы укыганлыктан, аның үзен укытучы итеп билгелиләр.

Аның фәнни хезмәтләре буенча фикер йөрткәндә, “О доказательствах задач алгебры и алмукабалы” дигән трактат язган. Аңа кадәр ике математик трактат язылган була. 1074 елда эре астрономия обсерваториясен җитәкли. “Евклид китабының авыр постулатларына комментарийлар” дигән китабын эшләп бетерә, үзенең хезмәткәрләре белән бергәләп календарь төзи.

XI нче гасырның 90 нчы елларында Мәккәгә хаҗ кыла. Җирле идарә башлыгы Хөрәсәндә врач булып эшли. Шул елларда фарсы телендә “Яшәешнең гомумилеге хакында” трактат яза.

Гомеренең соңгы 10-15 елын ялгызлыкта Нишапурда үткәрә. Кешеләр белән аз аралаша. Күрәсең, аның гомеренең соңгы еллары бик авыр

узгандыр. Ул мондый юллар язып калдыра: “Мәңгелеккә илтә торган ишекләрне тапсаң иде”, - ди ул. Нишапурда яшәгән соңгы елларында ул бары тик китап белән дус була. Гомеренең соңгы көннәрендә Хәйям Әбүгалисинаның “Савыктыру китабы”н укый. “Бердәмлек һәм гомумилек турында” дигән фәлсәфи бүлеккә кадәр укый да, торып дога кыла һәм җан бирә.

Хәйям - гыйсьянчы-бунтарь шагыйрь. Җирдән, тормыштан канәгатьсезлек белдерә, ә моның чыганагы – гаделсезлек. Шуңа күрә Аллаһы Тәгаләгә дә тел-теш тидерә, робагыйларына атеистик тенденцияләр үтеп керә.

Төп идеяләре – икейөзлелекне һәм монафикълыкны фаш итү, шәхес иркенә чакыру.

Иҗатында дин әһелләрен тәнкыйтьләү беренче урында тора. Аллаһның барлыгын, берлеген таный, шул ук вакытта Корьәндәге мотивлар белән дә бәхәсләшә. Шул рәвешле хакыйкать эзли.

Гомәр Хәйямиҗатында хәмер мотивы зур урын алып тора. Аның робагыйларына бәйле әдәбиятта хәйямчелек хәрәкәте барлыкка килә. Ул шәрабне мактап, дөньяга куанып яшәргә мөмкин, дип белдерә. Шулай ук дөнья авырлыкларын, үлемнән курыкмыйча, хис-тойгы белән уртак тел табып яшәргә мөмкин, дип саный. Ул эчкечелекне мактаганга, бертуктаусыз эзәрлекләнә.

Мәгълүм булганча, шәраб эчү, шулай экстаз халәтенә керү, Аллаһ белән кушылу суфыйчылык әдәбиятына хас сыйфатлар. Күп кенә галимнәр аның иҗатындагы шәраб мотивын да суфыйчылык юнәлешендә иҗат итүе белән аңлаталар. Бу, әлбәттә, каршылыклы фикер.

Гомәр Хәйям кешене зурлый, аны табигатьнең таҗы дип саный. Кеше бөеклеге алдында баш ия. Ул дөньяны үзгәртеп корырга тели һәм моның өчен барысын да эшләргә тырыша, табигать законнарын ача, йолдызларга карый, дөнья серләренә төшенергә тели һәм кешеләргә рухи коллыктан чыгарга ярдәм итә.

Дин - кеше өчен начарлык, барлык диннәр дә кешенең рухын кысалар, акылын алалар, дип исәпли. Аннан азат булганда гына кеше бәхетле һәм ирекле яши ала дигән караш тора.

Гомәр Хәйям фикерләвенчә, яшәеш меңләгән, миллионлаган мизгелләрдән тора. Тормыш ул - мизгелләр океаны. Робагыйларына фәлсәфилек хас, ләкин пессимистик тон күзәтелми, киресенчә, гыйсъянчылык рухы сизелеп тора.

Аның шигырьләре фикергә бай. Робагыйларының беренче 3 юлы еш кына укучыны киеренкелектә тота, төп фикер соңгы 4 юлда гына ачыла.

Иҗаты бик нык каршылыклы, чөнки робагыйларында төрле полюста яткан күренеш-мотивлар бергә очраша. Ул гыйсьянчы, материалист, идеалист, философ, скептик та, бала кебек саф күңелле шәхес тә. Платон һәм Аристотель кебек үк галәмне беренче барлыкка китерүче итеп Аллаһны исәпли, дөньяда мәңгелек хәрәкәт баруын робагыйларында исбат итә.

Дөньядагы хәрәкәтне 2 төрле сурәт, образлар ярдәмендә белдереп була, ди. Берсе – чәчәкләр, икенчесе – чүлмәк ясаучы чүлмәкчеләр.

Хәйям иҗаты Урта Азия һәм Иран халкы мәдәнияте, бөтен кешелек тарихында искиткеч күренешләрнең берсе. Аның хезмәтләре фәнне үстерүгә зур өлеш кертсәләр, искиткеч дүртюллыклары укучыларны бүгенгә кадәр үзләренең тирән мәгънәлелеге, сәнгати чараларның гадилеге, сыгылмалы ритмы белән шаккатыра. Барыннан да бигрәк, Хәйям үз шигырьләрендә кешене югары бәяләве белән зур һәм кабатланмас шагыйрь.

**Түбәндәге сорауларга җавап бирегез:**

1. Фирдәүсинең "Шаһнамә" эпопеясы нәрсә турында?
2. "Шаһнамәнең" сюжет-композиция үзенчәлекләрен атагыз.
3. Рөстәм образына сыйфатлама бирегез.
4. Робагый жанрының үзенчәлеге нәрсәдә?
5. Г.Хәйям иҗаты хакынданиләр исегездә калды?
6. Г.Хәйям иҗатындагы гыйсъянчылык мотивларын аңлатыгыз.

7. Г.Хәйям традицияләренең татар әдәбиятында чагылышын шәрехләгез.

## Тема №5. Суфыйчылык әдәбияты

**Аннотация.** Әлеге лекция суфыйчылык әдәбияты хакында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Суфыйчылык идеологиясенең асылы, төп юнәлешләре, Яңарыш чоры фарсы суфый шагыйрьләрнең иҗат мирасы асыл мәсьәләләре карала.

**Ачкыч сүзләр**: суфыйчылык әдәбияты, мөршид**,** мөрид,шәригать, тарикать, мәгърифәт, хакыйкать, хәнака, нәкъшбәндия, Җ.Руми, Нәсими, Сәгъди, Хафиз, Г.Җәми.

**Методик күрсәтмәләр:**

- Лекция өлешендә теманың төп мәсьәләләре карала, иң әһәмиятле моментларга басым ясала.
- Теманы тагын да яхшырак ачу максатыннан төп һәм өстәмә әдәбият, текстлар, интернет ресурслар тәкъдим ителә.
- Теманы үзләштерүне тикшерү максатыннан якынча сораулар урнаштырыла.
- Сорауларга телдән дә, язмача да җавап әзерләргә мөмкин.

**Түбәндәге интернет ресурслар тәкъдим ителә:**

9. http://ru.wikipedia.org
10. http://www.publ.lib.ru
11. http://www.sufimovement.ru/library.htm
12. http://uchebnik-online.com/131/1121.html
13. Путь суфия - Путь сердца // http://www.sufi.su
14. Руми Мавляна Джалалетдин. Избранные рассказы из "Маснави" http://www.kitaphane.crimea.ua/ru/rumi-mavlyana-dzhalaletdin-izbrannye-rasskazy-iz-masnavi.html

15.Джалаледдин Руми http://whoy.ru/blog/43478010439/Dzhalaleddin-Rumi
16.Насими http://www.opklare.ru/m/nasimi_-_analiz_tvorchestva
17.Стихи азербайджанских поэтов http://forum.rcmir.com/topic1919743_30
18. Стихи Насими http://www.stihi.ru/2008/03/01/171
19.Творчество Саади http://www.people.su/96490
20."Гулистан" - "Сад роз”"Саади (на персидском с дословным переводом на русский язык) http://www.russianplanet.ru/filolog/vostok/saadi/
21. Творчество Хафиза http://mmorpgbb.ru/foegwoeg/
22. Хафиз Ширази http://fakty-o.ru/Хафиз_Ширази
23.Хафиз Ширази http://yablor.ru/blogs/
24. Абдурахман Джами http://www.fway.org/sufism-44/61-2009-03-15-07-23-41/373-2009-03-20-09-40-54.html
25.Абдурахман Джами http://www.comunicom.ru/home/93-2011-07-30-12-02-12.html
26.Суфизм. Ступени возвышения http://www.youtube.com/watch?v=dkqA9nUrcTo

## Әдәбият

8. Андреева И.И. Древние и средневековые литературы народов СССР. - Ч.1.
9. Восточная поэзия. - М.: Терра - Книжный клуб, 2002. - Т.1. - 511 с.; Т.2. - 511 с.
10. Ганиева Р.К.Литература Востока (классический период). Расширенная программа лекционного курса / Р.К.Ганиева. – Казань, 2004.
11. Бертельс Е.Э. Избранные труды. Суфизм и суфийская литература. - М.: Издательство"Наука", 1965. - 522 с.
12. Кныш А.Д. Мусульманский мистицизм: краткая история. Пер. с англ. М.Г. Романов. – СПб.: Издательство «ДИЛЯ», 2004.

13. Рейснер М.Л. Литература Ближнего и Среднего Востока: учебно-методическая разработка / М.Л.Рейснер. - Казань, 2003.
14. Таджикско-персидская поэзия X-XV вв. - Казань, 1990. - 184 с.

**Глоссарий.**

**Мәгърифәт** - суфыйчылыкның өченче баскычы, Аллаһны акыл белән түгел, ә йөрәк белән танып-белүне, интуиция ярдәмендә тоюны аңлата. Бу халәтне, башкаларга аңлашылмаган бу серле гыйлемне Хак Тәгалә сөекле кешеләренә үзе җибәрә.

**Мәйханә**- шәраб, исерткеч эчемлекләр сатыла торган урын.

**Мәүлана** - "әфәнде ". Зур дәрәҗәләргә ирешкән галим- голяма, шагыйрьләр, казыйлар, руханилар, суфыйчылык җитәкчеләренең исемнәре алдыннан әйтелә торган шәрәфле исем.

**Мөршид** – рухи остаз, суфыйларның җитәкчеләре.

**Мөрид** – суфыйчылыкның тәрикать юлына баскан, остазының сүзеннән чыкмаска, аның юлын дәвам итәргә сүз биргән мөршиднең укучысы.

**Нәкъшбәндия –** суфыйчылыкның Бохара шәехе Баһаветдин Нәкъшбәнди нигезләгән юнәлеше, төрки-татарлар шушы юнәлешкә карый, алар зөһедлек һәм тәкъвалыкны, дәрвишлекне, хәнакада яшәүне мәҗбүрият итеп куймыйлар. "Нәкъшбәндия" юнәлеше кешене гел изгелек кылуга тартуы белән аерылып тора, Мөхәммәд пәйгамбәр юлын дәвам итүчеләр санала. Алар гадел, кешелекле булырга, ярлыларга, фәкыйрьләргә ярдәм итәргә чакыралар, кешеләрне үз хезмәтләре белән көн күрергә чакыралар

**Суфыйчылык әдәбияты**- Аллаһка мәхәббәт тәрбияләү, аңа якынаерга, ахыр чиктә аның белән бергә кушылырга омтылуны максат иткән, үзәгендә - илаһияткә омтылган камил кеше образы торган әдәбият.

**Тарикать –** суфыйчылыкның икенче баскычы, шәех, ишан- ягъни рухи остаз җитәкчелегендә Аллаһ юлына басуны аңлата, бу баскычтагы суфый мөрид дип исемләнә.

**Хакыйкать** - суфыйчылыкның соңгы баскычы, Аллаһка якынаю, аның белән бергә кушылу. Һәр суфыйның төп һәм ахыр максаты шул.

**Хәнака** (ханках) – суфый дәрвишләрнең гомуми торагы. Кайбер юнәлештәге суфыйларга анда яшәү мәҗбүри куелган.

**Шәригать** - суфыйчылыкның беренче адымы, аның нигезендә - гыйлем, гамәл һәм ышану ята. Бу баскычтагы суфый илаһият кануннарын, ислам һәм шәригать нормаларын өйрәнә.

**Өйрәнү өчен тәкъдим ителгән сораулар:**

1. Суфыйчылык идеологиясе, тарихы.
2. Суфыйчылык әдәбиятындагы юнәлешләр.
3. Суфыйчылык әдәбиятының фәлсәфи нигезләре.
4. Суфыйчылыкның мәкамнәре - баскычлары.
5. Суфыйчылык әдәбиятының үзенчәлекләре, образлар системасы.
6. Яңарыш чоры суфый фарсы әдипләре.

## 1. Суфыйчылык идеологиясе, тарихы

Суфыйчылык фәлсәфәсе күп заманнар элек, б.э.к. 3 гасырда Һиндстанда барлыкка килгән. Аның мөселман дөньясында таралышы ислам дине белән бәйләп карала. Коръәндә дә суфыйчылык төсмерләре бар.

Галимнәр фикеренчә, суфыйчылык мөселманнарда 8-9 гасырларда киң тарала, бигрәк тә Гыйрак белән Сүриядә актив күзәтелә, ә кульминациясе – 11-12 йөзләргә туры килә.

Суфыйчылык идеологиясе яшәп килүче тәртипләргә каршы барлыкка килә. Халык Ислам дине яшәешне җиңеләйтер дип өметләнгән була, ләкин җәмгыятьтәге сыйнфый бүленеш үзен тагын да ныграк сиздерә башлый. Ислам дине вәкилләре, руханилар суфыйчылыктан куркып, аны ислам белән килештерергә уйлыйлар. Моның башында имам Газали тора. Ул суфыйчылыкны рәсми юлдан җибәрә. Шуңа күрә гарәпләрдәге суфыйчылык

ислам диненә нык яраклашкан, ә фарсыларда, киресенчә, суфыйчылык оешмалары, нигездә, исламга каршы торалар.

**“Суфый”**сүзенең килеп чыгышы хакында төрле версияләр яши.

1) Гарәпләрдәге йон сүзеннән килеп чыккан, чөнки суфыйлар тупас, дөя йонынннан тегелгән кием киеп йөргәннәр. Вафат булып, гүргә керер алдыннан гына алар бу киемнәреннән аерылганнар.

2) Европа галимнәре фикеренчә, грекларның – “София – мудрость» сүзеннән килеп чыккан.

3) Суфыйлар, нигездә, фәкыйрь булганлыктан, йоклар урыннары булмаган, шуңа күрә Кәгъбә тирәсендәге “әс-сөффә” дип аталган урындыкта утырып төн үткәргәннәр, бу исем – урындыкта йоклаучы Аллаһ кешеләре дигәнне аңлата.

**2. Суфыйчылык әдәбиятындагы юнәлешләр.**

Суфыйчылыкның төрләре бик күп. Төрки-татарлар аның “нәкъшбәндия” юнәлешенә карыйлар. Төркиядә “мәүләвиләр”, Кавказда “кадыйриләр” юнәлеше өстенлек ала. “Нәкъшбәндия” юнәлеше кешене гел изгелек кылуга тартуы белән аерылып торган.

Суфыйлар элгәреге (ранние) һәм соңгы (поздние) суфыйларга бүленәләр. Элгәрегеләр җыр-биюгә мөрәҗәгать иткәннәр, алар кеше җанына күбрәк мөмкинлекләр биргәннәр. Алар эзәрлекләнгәннәр. Соңгы суфыйлар исә – реакционерлар.

Суфыйчылыкның мистик, оппозицион һәм пантеистик төрләре бар.

Мистик суфыйлар – бары Аллаһны гына беләләр. Уй-фикерләрендә, кылган гамәлләрендә, һәр адымда Аллаһны юлдаш итеп алалар. Бу суфыйлар начар ашыйлар, начар йоклыйлар, начар киенәләр. Һәр адым Аллаһ белән кушылуга илтә, дип ышаналар.

Оппозицион суфыйлар – яшәп килгән гаделсезлекләрне күрә алмыйлар, халык хәрәкәтләрендә катнашалар, колониаль изучеләргә каршы корал белән чыгучылар.

Пантеистик суфыйлар Аллаһ- Галәм- Кеше – бербөтенлекне тәшкил итә, дип саныйлар. Алар хәтта Кеше ул –Аллаһ дигән фикер дә үткәрәләр. Аларча, Аллаһ бөтен галәмгә нур рәвешендә таралган.

**3. Суфыйчылык әдәбиятының фәлсәфи нигезләре.**

Ислам дине буенча  кеше Аллаһка буйсынырга, аннан куркырга, сәҗдә кылырга һәм яратырга тиеш. Ә суфыйчылык Аллаһны бары яратырга гына өнди. Аның үзәгендә – Аллаһка мәхәббәт тора. Ренессанс әдәбиятында исә, Аллаһ та, Кеше дә олылана.

Суфыйлар хакимияткә буйсынуны яратмаганнар, шуңа күрә алардан ераграк булырга тырышканнар.

Суфыйлар Аллаһ ризалыгын алу өчен нәфесне тыялар, күңелне дөньядан биздерәләр. Заһитлар теләк, омтылышларны  тыялар, риязәт кылалар, тәннәрен зәгыйфьләндерәләр, үзләрен ач тоталар, йокламыйлар, өсләренә дөя йонынннан кием кияләр, кыш көне дә ялан аяк йөриләр. Суфыйлар карашынча, тәнне никадәр зәгыйфьләндерсәң, шулкадәр күңел нечкәрә, рух сизгерләнә. Нәфесне тыйган кеше матдият (материалист) галәменнән (идеалист) мәгънәвият галәменә күчә.

Зөһетлек – ярлыларда туган, соңрак өстен сыйныфларда да таралган. Ислам дине,  андагы “кәлям – фәлсәфәсе “ – мөтәкәллимнәр – дөньяны танып белүдә акылга игътибар бирәләр. Шуңа күрә күк пәрдәсен ачсак, иң элек акыл күренә. Ә суфыйлар фәлсәфәсе буенча дөнья кубрәк хисләр – нәфес (җан) – калеб – интуиция ярдәмендә танып була. Шуна күрә суфыйлар дөньяны инану белән тануны  алга сөрәләр.

Суфыйчылыкның барлык төрләренең дә нигезендә неоплатонизм фәлсәфәсе ята. Моннан тыш суфыйчылык башка диннәргә дә хас, христианнар, буддистлар арасында да, хәтта мәҗүсиләр арасында суфыйчылыкның төрле төрләре очрый.

## 4. Суфыйчылыкның мәкамнәре - баскычлары.

Суфый гомере буена тормышта камил кешегә әйләнеп, Аллаһ белән якынаерга тырыша. Бу вакытта билгеле бер этап – баскычлар – мәкамнәр үтә. Нигездә алар 4:

1) Шәригать (аны өйрәнү )
2) Тәрикать (юл)
3) Мәгърифәт (Аллаһны йөрәк белән танып-белү)
4) Хакыйкать (Хак тәгаләгә якынаю)

Суфыйчылык галимнәре мәкамнәрнең күбрәк булуына да игътибар итәләр (8-10-12 гә җиткерелә): 1)шәригать ( акыл белән тану ); 2)тәүбә итү; 3) алны-артны карау-вараэ (осмотр); 4)зөһетлек (тәкъвәлек ); 5) фәкыйрьлек; 6)сабырлык; 7)тәвәкәллек (Аллаһка тәвәкәлләү) 8)Аллаһка буйсынып, аның белән бергә кушылу.

## 5. Суфыйчылык әдәбиятының үзенчәлекләре, образлар системасы

1) Алар гашыйк. Суфыйлар һәрчак Аллаһка гыйшыкны мактыйлар.

2) Кеше тәненең матурлыгы. Бу – Аллаһның матур сыйфатлары күздә тота.

3) Шәраб. Шәраб эчү Аллаһ белән кушылуны – экстазны аңлата. Суфыйчылык әдәбиятында еш кына суфыйлар кабакта утыралар. Шәраб эчәләр, касәләрен ваталар, исереп идәнгә егылалар. Бу күренеш - җир исереклеген аңлатмый, бу – Аллаһ белән кушылу.

Суфыйлар яратып кулланган образ-детальләр: шәм, йөрәк, сәмруг кош, гүзәл кыз, гөл һ.б.

Суфыйчылык тәгълиматы татар әдәби-эстетик фикерендә дә үзенчәлекле урын алып тора. Төрле гасырларда яшәгән татар суфыйчылык әдәбияты вәкилләре: Әхмәт Ясәви, С.Бакырганый, М.Болгари, Х.Кятиб, Өмми Камал, Колшәриф, Мәүла Колый, Һ.Салихов, Ш.Зәки, Ә.Каргалый.

Шәрык әдәбиятларында суфыйчылыкның күренекле вәкилләре:

Сәнан, Гаттар, Җ.Руми, Нәсими, Фөзули, Сәгъди, Хафиз, Г.Җәми, А.Нәвои һ.б.

## 6 Яңарыш чоры суфый фарсы әдипләре.

**Җәлалетдин Руми**(1207- 1273) – тулы исеме - *Мөхәммәд ибн Мөхәммәд ибн Хөсәйн Хөсәйни Хатиби Бәкри Бәлхи*– суфый шагыйрь, философ. Иҗатының таҗы – “Көллияте Шәмси Тәбризи” исемле зур күләмле шигырь җыентыгы. Андагы газәлләрнең эчтәлеге – кешене илаһилаштыру, галәмдәге һәр нәрсәнең гомум Җан – Аллаһ белән бергә кушылуы.

Руминың икенче зур хезмәте – 15 ел дәвамында язылган 6 томлык фәлсәфи дидактик эчтәлекле “Мәснәви” поэмасы. Ул – суфыйчылык тәгълиматы энциклопедиясе һәм Көнчыгыш халыклары фольклоры чыганагы.

Руми татар әдәбиятында Мөхәммәдъяр, Өмми Камал, Кол Шәриф, Һибәтулла Салихов, Каргалый, Шәмсетдин Зәки кебек суфый шагыйрьләр иҗатына йогынты ясаган. Шагыйрь, галим Г.Утыз Имәни Руминың “Мәснәви”ен күчереп язган, комментарийлар биргән. Руминың татар әдәбиятына тәэсире хакында З.Вәлиди, Г.Таһирҗанов, Ш.Абилов, Ә.Шәрипов, Х.Миңнегулов хезмәтләреннән укырга мөмкин.

Руми – пантеистик суфыйчылык вәкиле. Әфганстанда туа, Кече Азиянең Рум шәһәрендә яшәгән. Әтисе – күренекле дин белгече. Монголлардан качып, Төркиягә килеп урнашалар. Җәләлетдин мәдрәсәдә

укыткан, укучылары аны олылап, “мәүләви, мәүләнәбез” дип йөрткәннәр. Шуннан мәүләвиләр тарикате барлыкка килгән.

Җәләлетдин Шәмсетдин Тәбризи исемле рухи остазы йогынтысында суфыйчылык юлына баса. Әлеге остазы белән берлектә мәдрәсәдә суфыйчылык тәгълиматын укыталар. Көннәрдән бер көнне Ш.Тәбризи югала, төрле версияләр яши, кайберәүләр качып киткән дигән фикерне алга сөрсә, икенчеләре аны Ж.Руми һәм аның укучылары үтерткән дип саный.

Тәбризи югалгач, Руми шигырьләр яза башлый, ул аларны Шәмс тәхәллүсе белән бастыра. Ул - бик күп санлы газәлләр авторы .

Суфыйларга хас булганча, җир образларын кулланып, Аллага мәхәббәт турында яза. Шулай ук укытучысы Ш.Тәбризигә дә ярату хисләрен белдерә.

***В счастливый миг мы сидели с тобой – ты и я ....***

Мәхәббәт шигырьләрендә Аллага ярату хисләрен җир мәхәббәте образлары ярдәмендә белдерә. Аның лирик герое укытучысы белән дә, илаһият белән дә бергә кушыла. Руми газәлләрендә дөньяны йөрәк белән тануга игътибар ителә, кеше калебе – Аллаһ йорты, диелә. Пантеистик суфыйчыларның күбесе Аллаһ мәрхәмәтле, изге кеше йөрәгендә дип раслыйлар. Руми әсәрләрендә икейөзлелектән, явызлыктан азат кеше турында сөйләнелә.

Руми газәлләре символистик образларга корылган, музыкаль аһәңгә ия. Аларда анафора, эчке рифма, рәдифләр мул кулланыла.

Руми газәлләрен тыңлаучылар экстаз халәтенә керә торган булганнар. Аның әсәрләрен “суфыйчылык Коръәне” дип тә атаганнар.

6 томлык “Мәснәви” Румига дөньякүләм шөһрәт алып килә. Мәснәви – икеюллыклар. Бу әсәр – суфыйчылык энциклопедиясе. Ул гыйбрәтле хикәяләрдән, мәсәлләрдән тора. Анда галәм акылы, галәм җаны һәм аларның

Аллаһ белән мөнәсәбәте хакында сүз бара. Җан-тән, ихтыяр мәсьәләләре турында сөйләнелә, диалектика проблемалары күтәрелә.

Руми фикеренчә, галәм капма-каршылыклар бердәмлегеннән гыйбарәт. Бу фикерне Гегель дә кабул итә. Кайбер хикәяләрендә каләм иясе байлык, фәкыйрьлек мәсьәләләрен күтәреп, иҗтимагый гаделлек проблемаларын да хәл итү юлларын тәкъдим итә.

Руми кешеләрдәге тискәре сыйфатларны кире кага, камил кеше идеалын яклый, сугышларга каршы чыга. Тәннәребез, диннәребез төрле булса да, уртак тел табып яшәргә чакыра. Йөрәк белән уртак тел табу – иң зур кыйммәт.

Анын иҗатында очраган суфыйчылык символлары:

Сәмруг кош – Аллаһ

Гөл - Аллаһ

йөрәк – Аллаһ

гүзәл кыз – Аллаһ

шәм – Аллаһ

Шәм янында очучы күбәләк – Аллаһ янындагы суфый. Күбәләк шәмдә янып юкка чыга, ягъни Аллаһ белән кушыла.

Руми – гуманист шагыйрь, чөнки ул кешене олылый. Анын суфыйчылык дәресләрен мөселманнар да, яһүдиләр дә, христианнар да тыңлаган. Суфыйлар дөньяны йөрәк белән таныйлар. Аларда Аллаһ мәхәббәт белән танылa. Христиан мәдәниятенең дә төп кыйммәте – мәхәббәт.

**Сәед Имамеддин Нәсими** (1369-1417)– азәрбәйҗан шагыйре, төрки, гарәп, фарсы телләрендә иҗат иткән. Газәл һәм робагыйлар остасы. Суфыйчылыкның “хәрефчелек” дип аталган фәлсәфи-пантеистик юнәлешен

алга ала. Аллаһ белән кеше арасына тигезлек билгесе куя. Кешене олылаганы, тәңреләштергәне өчен “дәһри” диеп игълан ителә, тиресе тунап үтерелә. “Нәсими” – тәхәллүс, иртәнге чәчәк мәгънәсендә.

Нәсими образы фидакарьлек символы булып тора. Реакцион дин әһелләре 600 ел үткәч тә, (XX гасырда) аны эзәрлекләүне дәвам итәләр, бер урыннан икенче урынга күчереп куялар.

Татар әдәбият тарихында Нәсими исеме XX йөз башына кадәр телгә алына. Аның шигырьләре “Бакырган” китабына кертелгән. Ул С.Рәмиев, Н.Думави иҗатларына йогынты ясаган. Аның әсәрләрен Зәки Нури, Әхмәт Исхак татар теленә тәрҗемә иткәннәр.

Нәсими Азәрбәйҗанның Шәмәхә шәһәрендә туа. Үз заманы өчен шактый әйбәт белем алган, дин гыйлеме, астрономия, логика, математика фәннәрен яхшы белгән, гарәп, фарсы, төрки телләрдә иркен сөйләшкән, язган. Беренчеләрдә булып, үз телендә, азәрбәйҗан телендә шигъри җыентык яза.

Нәсими – суфыйчылыкның “хәрефчелек” юнәлешен нигезләүче (башлап җибәрүчесе – Наими исемле шагыйрь була). Үзенең укытучысының эшен дәвам итә. Наими Аксак Тимернең улы тарафыннан үтерелгәч, Нәсими илен ташлап, Төркиягә китә.

Нәсими суфыйчылык тәгълиматын фарсы әлифбасының 32 хәрефе ярдәмендә аңлатып бирә. Аныңча, дөньядагы җанлы һәм җансыз нәрсәләрне хәрефләр ярдәмендә язып була. Аллаһ, галәм, табигать, кеше һ.б. сүзләр хәрефләр ярдәмендә белдерелә ала.

Шул рәвешле, Аллаһ белән Кеше арасына да тигезлек билгесе куя. Ул Аллаһны кешеләштерә, ә кешене илаһилаштыра, тәңреләштерә. Аныңча, дөньядагы бөтен нәрсә – Аллаһ, һәр кеше – Аллаһ. Аллаһы Тәгалә безнең йөзебездә хәрефләр белән язылган.

Агач та, һәммә нәрсә – илаһият нурларыннан барлыкка килгән. Кешенең чәче – Коръән аяте.

***Бог – человечий сын и человек велик***

***Всё создал человек и многое постиг.***

***Всё в мире – человек, он – свет и мироздание***

***И солнце в небесах есть человечий лик.***

***Вхожу ли я в мечеть, иду ли мимо храма***

***Направо я иду, налево или прямо***

***Я думаю о том и убеждаюсь в том,***

***Что Бог – любой из нас, из сыновей Адама.***

Нәсими касыйдәләр, газәлләр дә язган. Газәлләрендә сөйгән ярны илаһилаштыра. Аның бу традициясен С.Рәмиев дәвам иттерә.

Аның әсәрләрендә табигать тә гүзәл кызга охшарга тырыша, гүзәл кыз образы – Нәсими өчен Аллаһы Тәгаләнең йөзе дә. Аныңча, мәхәббәт – галәмнең бар байлыгыннан да югарырак, оҗмаһ ләззәтләреннән дә өстенрәк. Мәхәббәт ул – кояшка тиң, ул да Кояш кебек дөньяга яктылык, җылылык өләшә, тормыш бүләк итә. Нәсими гашыйклары хисләргә бай булу белән аерылып торалар. Аның газәлләрен дөньяви эчтәлектә дә, суфыйчылык тәгълиматы рәвешендә дә кабул итәргә мөмкин.

Нәсими үзе дә, остазы кебек үк Аксак Тимер дәвамчыларының эзәрлекләвенә дучар була, чөнки алар хөр фикерле кешеләргә яшәргә, иҗат итәргә мөмкинлек бирмәгәннәр. Шулай да Нәсиминең шигырьләре,

карашлары Шәрык илләрендә киң таралыш ала. Нәсими әсәрләрен халыкка укучы бер  малайны хәтта үлем җәзасына хөкем иткәннәр, ул моны ишетеп, тизрәк баланы коткаруга керешә, “бу шигырьләрнең авторы – мин” диеп, җәзаны үзенә ала, триесе салдыралар, каны ага тора, ул сары төскә керә бара. Җәзалаучының  “син ник саргаясың?” дигән соравына “Мин - кояш!”дип җавап бирә. Соңгы сүзе: “Аллаһны яраткан кеше ыңгырашмыйча, кычкырмыйча үлә” “Әнә әл-хак” (“мин –Аллаһ”) дип кабатлый.

Нәсими – гыйсъянчы шагыйрь, аның шигырьләрен уку, аны искә алу озак еллар тыелган була. Нәсими – кешене олылавы, тәңреләштерүе белән төрки ренессансына нигез салучыларның берсе.

**Сәгъди Ширази -** Әбу Мөхәммәд Мөслихетдин ибн Габдулла Сәгъди Ширази фәлсәфи-дидактик, фәлсәфи-лирик юнәлешне үз иткән күренекле лирик.  Ул тумышы белән Шираз шәһәреннән, 100 елдан артык яшәп, иҗат иткән. Гомеренең беренче яртысын сәяхәтләрдә уздырган. Һиндстаннан Суриягә кадәр ара узган, гаҗәеп хәлләргә юлыккан. Дәрвиш сыйфатында авылдан-авылга, шәһәрдән-шәһәргә йөреп, вәгазь сөйләгән. Гади халык алдында да, патшалар, шәехләр катында да сөйләр сүзе күп булган. Гади халык алдында чыгыш ясарга, аларга тормыш гаделсезлекләре турында сөйләргә аеруча яраткан.

Гомеренең икенче яртысын иҗатка багышлаган. Олыгаеп, Ширазга әйләнеп кайткач, ике зур әсәрен яза – “Бостан” һәм “Гөлстан” поэмалары.

“Бостан” – иран ханы Әбу Бәкргә багышлана. Бу идарәче монгол яулары  заманында ил казнасындагы акчаларны монголларга биреп, Шираз шәһәрен һәлакәттән саклап калган була. Бу әсәр шул вакыйгаларны истә тотып язылган.

Әсәр 10 бүлектән тора:

- Гаделлек

- Изгелек, юмартлык
- Мәхәббәт
- Тыйнаклык
- Язмыштан риза булу
- Азга канәгать итү
- Бүгенге көндәге иминлек өчен Аллаһка рәхмәт уку
- Тәүбә итү
- Дога кылу һәм тәмамлау.

“Гөлстан”поэмасы исә 8 бүлекне үз эченә ала:

- Патшалар турында
- Дәрвишләр әхлагы
- Азга канәгать итү
- Дәшмәүнең өстенлеге
- Мәхәббәт һәм яшьлек
- Картлык һәм хәлсезлек
- Тәрбия
- Аралашу кагыйдәләре.

Баштагы 7 бүлек кыска хикәяләрдән гыйбарәт. Соңгысы исә, мәкальләрдән, канатлы сүзләрдән, хикмәтләрдән тора.

Әсәр рифмалы проза – сәдҗ белән язылган. “Мөсәҗҗәгъ нәсер” дип тә йөртәләр. (С.Рәмиевның “Таң вакыты” әсәре рухында.)

Әсәр халык иҗаты нигезендә язылган, шуңа күрә тиз арада бөтен Шәрыкка тарала, тора-бара Аурупа телләренә дә тәрҗемә ителә. 14 йөздә С.Сараи төрки-татар телендә “Гөлстан-бит-төрки” әсәрен тәкъдим итә.

С.Ширази ике әсәрендә дә гадел кеше, гадел патша турында яза. Аеруча патшаларга мөрәҗәгать итеп, аларны гаделлеккә, тыйнак булырга, азга канәгать итәргә, ислам дине тәртипләрен үтәп яшәргә чакыра. Дәүләтнең халык җилкәсендә яшәвен фаш итеп, изүләрне, халыкны талауны туктатырга өнди. Гуманист язучы буларак, сугыш, талауларга каршы чыга. Явыз шаһларны тәмуг белән куркыта. Патшалардан гаделлек таләп итүе белән реалист шагыйрьгә ошый.

**Шәмсетдин Мөхәммәтхафиз** (1325-1390) - фарсы әдәбиятының көчле лирикларының берсе. “Хафиз” исеме Коръәнне яттан белгән өчен бирелә,төрле дини уку йортларында укыта. Гарәп, фарсы телләрен камил белә. Ул Сарай шагыйре, Мозаффаритлар Сараенда хезмәттә тора. Ләкин, тора-бара үзенең иреккә омтылуы белән Сарай кешеләренә ярамый башлый һәм шуның өчен Сарайдан китә.

Газәлләр, робагыйлар, поэмалар иҗат итә. 500 дән артык газәле бар. Бу жанр Хафиз иҗатында кульминацион ноктасына җитә. Шәрык белгечләре Хафиз иҗатын суфичылык рухында дип таныйлар. Ләкин, тулысы белән аны суфый дип атау мөмкин түгел. Аның газәлләрендә конкрет кеше мәхәббәте фәлсәфи югарылыкта бирелә. Мәхәббәт китергән ләззәт бар төсмерләре белән бирелә. Аның газәлләре антиномиягә нигезләнгән. Мәхәббәт – ләззәт һәм мәхәббәт – газап мотивлары янәшә килергә мөмкин.

Үзенең әсәрләрендә Хафиз икейөзле дин әһелләреннән көлә, аларга каршы чыга. Күп кенә казыйлар, шәехләр, суфыйчыларның икейөзле булуларын фаш итә. Алардагы ахмаклык, мәкерлек сыйфатларыннан көлә.

Аның иҗатында шәхес бунтын күрергә мөмкин. Ләкин ул пассив рәвештә гәүдәләнә. Восстаниягә, күтәрелешкә чакырмый.

Хафиз хәмерне, тормыш матурлыгын, мәхәббәт һәм дуслыкны да зурлап җырлый. Күпмедер дәрәҗәдә Хәйям иҗатын хәтерләтә. Ләкин иҗаты бик каршылыклы.

**Габдрахман Нуретдин Җәми** (1414- 1492) – фарсы яңарыш әдәбиятының ишекләрен ябучы атаклы шагыйрь һәм суфыйчылык әдәбиятының теоретигы.Җәми заманының абруйлы шәхесе, галим дәрәҗәсенә ия булган, патшалар белән хат алышкан, сүзенә һәрчак колак салганнар.

Ул суфыйчылыкның “нәкъшбәндия” юнәлешенә җитәкчелек иткән. Бу юнәлешкә 12 гасырда Йосыф Хамадани дигән кеше нигез салган. Татарлар арасында бу юнәлеш әле дә яши, алар Мөхәммәд пәйгамбәрчә яшәргә өндиләр, гадел, кешелекле булырга, ярлыларга, фәкыйрьләргә ярдәм итәргә чакыралар, кешеләрне үз хезмәтләре белән көн күрергә чакыралар.

Җәминең суфыйчылык буенча остазы – Урта Азия суфыйларының башлыгы, атаклы Хуҗа Әхрар була. Ул аның кызына өйләнә. Бай булса да, суфыйларча, гади тормыш кичерә, байлыгын әдәбият һәм сәнгать кешеләренә сарыф итә.

Җәми үзбәк әдәбиятының классигы Галишер Нәвои белән дус була. Ул – аның укытучысы, Җәми Нәвоине суфыйчылык тәгълимате кагыйдәләре белән таныштыра.

Җәми иҗат эшенә шактый соң алына. 66 яшендә беренче әсәрен яза, барлыгы 100 әсәр иҗат итә, 78 яшенә кадәр кулыннан каләме төшми.

Җәми касыйдәләр, газәлләр язган, төрле җыентыклар иҗат иткән, илаһият белеме, суфыйчылык, шигырь төзелеше, риторика, музыка буенча хезмәтләр калдырган, 500дән артык суфыйның биографиясен төзегән. Улына үгет-нәсихәт рәвешендә, Сәгъдигә ияреп, “Бәһарстан” дигән китап язган, аны раузаларга (бакчаларга) бүлгән.

Җәминең газәлләре – Хафиз белән Сәгъдигә нәзыйрәләр. Ул – мәхәббәт җырчысы. Ул мәхәббәтне суфыйларча аңлата. Ләкин ул мәхәббәттә Сәгъди,

хафизларча гыйсъянчы түгел, аның мәхәббәт турындагы шигырьләрен илаһият фәлсәфәсе һәм дөньяви юнәлештә аңларга мөмкин.

***“Мәхәббәт ул – Аллаһ! Яшәү нигезе. М-т ул – галәмне, андагы җанлы һәм җансыз предметларны иҗат итүче! М-т ул – яшәешнең кендеге!”***

Җәми тасвирлаган мәхәббәт – ләззәтлемәхәббәт, гаделлеккә, тугрылыкка өндәүче мәхәббәт.

Суфый шагыйрь буларак, Җәми иҗатында суфыйчылыкка нисбәтле образлар мул бирелгән.

**Түбәндәге сорауларга җавап бирегез:**

1. Суфыйчылык баскычларын атагыз, һәрберсен шәрехләгез.
2. Суфыйчылык әдәбияты нинди традицион образлар белән эш итә?
3. "Хәрефчелек" хәрәкәтен ничек аңлыйсыз?
4. Җ.Руми иҗатына кыскача сыйфатлама бирегез.
5. Сәгъди Ширази иҗаты хакынданиләр истә калды?
6. Хафиз газәлләренең үзенчәлеге нәрсәдә?
7. “Сәлмән вә Әбсәл” поэмасының төп идеясен ачыклагыз.

## Тема №6. Урта гасыр мөселман Көнчыгышы әдәбиятлары контекстында төрки әдәбиятлар

**Аннотация.** Әлеге тема төрки яңарыш әдәбияты хакында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Яңарыш чоры татар, азәрбәйҗан, үзбәк әдәбиятларындагы күренекле әдипләр иҗаты, аларның дөньякүләм яңгырашка ия әсәрләре белән танышу, аларны чагыштырма планда өйрәнү мәсьәләләре алга куела.

**Ачкыч сүзләр**: Төрки яңарыш әдәбияты, Йосыф Баласагунлы, Кол Гали, Хакани, Низами, Фөзули, Нәвои, “Хәмсә”, Хөсрәү, Ширин, Фәрһад, Искәндәр, газәл, шикаятнамә.

**Методик күрсәтмәләр:**

- Лекция өлешендә теманың төп мәсьәләләре карала, иң әһәмиятле моментларга басым ясала.
- Теманы тагын да яхшырак ачу максатыннан төп һәм өстәмә әдәбият, текстлар, интернет ресурслар тәкъдим ителә.
- Теманы үзләштерүне тикшерү максатыннан якынча сораулар урнаштырыла.
- Сорауларга телдән дә, язмача да җавап әзерләргә мөмкин.

**Түбәндәге интернет ресурслар тәкъдим ителә:**

http://ru.wikipedia.org

http://www.coollib.net

http://www.royallib.ru

http://www.vostlit.info

http://www.az-love.com

http://www.vostlit.info

http://www.azeri-info.com

http://www.turan-info.

http://www.briefly.ru

http://www.obshelit.ru

**Әдәбият:**

15.Андреева И.И. Древние и средневековые литературы народов СССР. - Ч.1.

16.Восточная поэзия. - М.: Терра - Книжный клуб, 2002. - Т.1. - 511 с.; Т.2. - 511 с.
17.Ганиева Р.К.Литература Востока (классический период). Расширенная программа лекционного курса / Р.К.Ганиева. – Казань, 2004.
18.Рейснер М.Л. Литература Ближнего и Среднего Востока: учебно-методическая разработка / М.Л.Рейснер. - Казань, 2003.
19.Таджикско-персидская поэзия X-XV вв. - Казань, 1990. - 184 с.
20.Золотая поэзия Востока.- Симферополь: Реноме, Харьков: Свитовид, 2001.-368 с.

**Текстлар:**

5. Баласагунский Юсуф хас-Хаджиб. Наука быть счастливым. - М.: Худ.лит., 1971 - 157 с. -Перевод Наума Гребнева.
6. Баласагуни Юсуф. Благодатное знание. - Л.: Советский писатель, 1990. - 560 с. (Перевод С.Н.Иванова).
7. Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1989. - 221 б.
8. Навои Алишер. Лирика. - М. - СПб.: Диля, 2000. - 320 с.
9. Навои Алишер. Фархад и Ширин. - Ташкент: Изд-во лит.и искусства им. Гафура Гуляма, 1985. - 351 с. (Перевод Льва Пеньковского).
10. Навои Алишер. Лейли и Меджнун. - Ташкент: Худ.лит., 1957. - 176 с. (Перевод Семена Липкина).
11. Нәваи Низаметдин Галишер. Фәрһад һәм Ширин // Мирас. - 2002. - №10-12; 2003.- №1-12; 2004. № 1-4.
12. Низами Гянджеви. Собр соч. В пяти томах. Лирика. Сокровищница тайн. - М.: Худ.лит., 1985. - Том первый. - 302 с.
13.Низами Гянджеви. Хосров и Ширин. - М.: Худ.лит., 1985. - Том второй. - 478 с.
14.Низами Гянджеви. Лейли Меджнун. - М.: Худ.лит., 1986. - Том третий. - 366 с.

15. Низами Гянджеви. Семь красавиц. - М.: Худ.лит., 1986. Том четвертый. - 366 с.
16. Низами Гянджеви. Искандер-наме в двух книгах. - М.: Худ.лит., 1986. - Том пятый. - 782 с.
17. Физули. Лирика. - Баку: Язычы, 1985. - 77 с.

**Глоссарий.**

**Афак –** Низами Ганҗәвигә бүләк ителгән кол кыз, соңыннан Низаминың сөекле хатыны, аның күп әсәрләренең прототибы.

**Әнуширван - Нәүширван** – Хөсрәү I Ануширван (531-579) – “Гадел” кушаматы тагылган Сасанидлар династиясеннән булган иран шаһы, ул идарә иткән чорда салымнар кими, халык иркен яши. Риваятьләргә караганда, ул үзенең идеаль дәүләт турындагы фикерләрен тәхетенә чокып эшләткән була.

**Бәһрәмгүр** – Низами, Нәвои поэмаларының баш каһарманы, тарихта - сасанидлар династиясенең легендар шаһы, ау остасы , коланнар (онагра – партояклы булмаган ат төре) аулау белән мавыкканлыктан Бәһрәм Гүр дигән тәхәллүс бирелә (Гүр – коланның фарсыча әйтелеше). Шәрык Дон-Жуаны булып танылган бу шәхес сөеклесе (Азадә, Диларәм, Фетнә) белән бик күп әсәрләрнең сюжет тукымасына кертелгән.

**Газәл-** гарәп шигърияттендә дөньяга килгән, фарсы, төрки әдипләре тарафыннан яратып кулланылган, 12 бәеттән артмаган поэтик форма, төп юнәлеше – лирик нигезле мәхәббәт җырлары, еллар узган саен иҗтимагый-фәлсәфи эчтәлекле газәлләр ешрак очрый.

**Искәндәр-** Александр Македонский, Низами, Нәвои әсәрләренең баш каһарманы.

**Низами** – Әбу Мөхәммәд Ильяс ибн Йосыф ибн-Заки ибн-Муайад Низами Ганҗәви (1141-1209)-Шәрык, азәрбәйҗан әдәбиятының бөек шагыйре, фикер иясе, әсәрләрен фарсы телендә иҗат итә. Ул фарсы эпик поэзиясенә сөйләм

телен һәм реалистик өслүб алып килгән, әдәби әсәр тудыруның яңа стандартларын эшләп биргән сүз остасы, һәрберсе тиңдәшсез саналган биш поэманы берләштергән “Хәмсә” авторы.

**Нәвои-** Мир Низаметдин Гыясетдин Алишер Нәвои(1441-1501)- үзбәк яңарыш дәвере шагыйре, фикер иясе һәм дәүләт эшлеклесе. Ул - бик үткен телле, тәнкыйди рухлы иҗатчы. Нәваи иҗатының кульминацион ноктасы - аның “Бишлеге” – “Хәмсә”се.

**Хөсрәү** - Хөсрәү Пәрвиз (590-628) - сасанидлар династиясенә караган иран шаһы. Низами, Нәвои әсәрләрендәге Ширинга гашыйк булган баш каһарман.

**Ширин-** Низами, Нәвои әсәрләренең баш каһарманы, патшабикә.

**Фәрһад** - Низами, Нәвои әсәрләренең баш каһарманы, Ширинга гыйшык тотучы ташчы егет (Низамида), ә Нәвои әсәрендә ул – архитектор, кытай хаканы улы.

**Фөзули –** мәүланаМөхәммәт ибн Сөләйман Фөзули (1494-1558)- шагыйрь һәм фикер иясе, азәрбәйҗан яңарыш әдәбиятының соңгы вәкиле, газәл остасы. Азәрбәйҗан әдәбиятына шикаятнамә жанры алып килә.

**Хакани** - Әфзалетдин Хакани (1120-1199) – күренекле азәрбәйҗан әдибе, азәрбәйҗан ренессанс әдәбиятына нигез салучы.

**Хәмсә** – бишлек, биш поэманы берләштергән зур шигъри җыентык, беренче “Хәмсә” авторы – Низами, аның эшен дәвам итеп, җавап рәвешендә, һиндстанлы Әмир Хөсрәү Дәһләви (1253—1325), фарсы- таҗиклардан Габдрахман Җәми (1414—1492), үзбәкләрдән Алишер Нәвоиләр (1444—1501) үз “Хәмсә”ләрен тудыралар.

**Шикаятнамә –** зар- -мәгънәсендә, әдәбиятка жанр буларак Фөзули алып килә.

**Хөрәсән -** – төньяк-көнчыгыш  Иран.

**Лекция №1.   Төрки әдәбиятлардагы ренессанс тарихы**

Өйрәнү өчен тәкъдим ителгән сораулар:

1. Азәрбәйҗан яңарыш әдәбияты. Хакани иҗаты.
2. Низами Ганҗәви- азәрбәйҗан ренессансының бөек шагыйре.

Азәрбәйҗан әдипләре XI йөзгә кадәр әсәрләрен гарәп телендә иҗат иткәннәр. XI йөздә Гатран Тәбризи иҗатына бәйле рәвештә азәрбәйҗан шигърият мәктәбе фарсы телендә иҗат итүгә күчә һәм шуның белән үзенең үсешендә яңа дәвер башлап җибәрә. XII йөздә әдәби аренага инде төрки телле азәрбәйҗан шигърияте килә.  Ләкин әле алар үзләренең иҗат җимешләрен аһәңле, югары дәрәҗәле саналган фарсы телендә тәкъдим итүне дәвам итәләр. Бу чорда азәрбәйҗанлылар арасыннан ике зур каләм мастеры дөньяга таныла. Берсе – Афзалетдин Хакани, икенчесе – Низами Ганҗәви.

**1. Хакани иҗаты**

Әфзалетдин Хакани (1120-1199) – Хакани – тәхәллүсе. Хакан – сарай шагыйре булуын белдерә. Ул Әзәрбәйҗанның Ширван шәһәрендә дөньяга килә. Ул “шәмәхә шәһәр” дип йөртелә. Бабасы – тукучы, әтисе – балта остасы, әнисе – мөселманнарга әсир төшкән византияле хәрби кешенең кызы була.  Әти-әнисе ул кечкенә чакта ук аерылышалар, Әфзалетдин әтисенең абыйсы Мирза Кафи тәрбиясендә үсә.  Ул укымышлы, алдынгы карашлы кеше булганлыктан, энекәшенә дә  белем бирергә тырыша. Егет Шәрык әдәбияты, фәлсәфә,  мөселман һәм христиан дине нигезләре белән тирәнтен кызыксына. Аны әти-әнисе язмышы һәрвакыт борчый.

Укытучысы Әбу Улә аны хакимият сараена урнаштыра. Укытучысының  кызына өйләнә, әмма алар арасында аңлашылмаучылык килеп чыга. Әбу Улә шулай ук сарай шагыйре буларак, бик купшы телле һәм патшаларны, аларның хатыннарын, вәзирләрен, башка якыннарын туктаусыз күпертеп, мактап тора. Сәбәпле-сәбәпсез идарәчеләрне мактап, данлап тору

белән Әфзалетдиннең табигате килешми. Ул исә җәмгыятьтәге күренешләрне реаль җирлектә тасвирларга омтыла, касыйдәләрен социаль мотивлар, азатлыкка омтылу мотивлары  белән баета. Кияү белән каената арасында шул нигездә низаг туа.  Алар бер-берсенә һөҗү яза башлыйлар, ике арада җылы мөнәсәбәтләр бетә. Хакани хатыны хакына бу ызгыштан читләшә.

Хакани күп касыйдәләр иҗат итә. Ул аларның эчтәлеген, язылу рәвешен җиңеләйтә, халыклаштыра. Иң атаклы касыйдәсе  “Йөрәк дусты” дип атала.  Биредә шагыйрь феодаль изүне тәнкыйтьли, динчеләрнең дөньяви гыйлемгә каршы чыгуларын, дин белән сату итүләрен камчылый, һәрдаим өстен сыйныфларны чеметеп тора. Тора-бара сарай тормышыннан качу җаен эзли башлый. Һәм ул хаҗга бару сылтавы белән Сарайдан кача. Урта Азиядә, Шәрык илләрендә булып, төрле дәүләт эшлеклеләре, сәнгать кешеләре белән очраша. Кайда гына булмасын, аның талантына сокланалар, зурлыйлар, хөрмәтлиләр.  Ул туган иленә олыгаеп, күп илләрдә танылып, кайтып төшә.

Сәфәрдә күргәннәре нигезендә романтик эчтәлекле ике поэма яза:“Ике Гыйрак бүләге” һәм “Мәдаин шәһәренең хәрабәләре”.

Бу әсәрләрдә халыкларның үткәне, илләр язмышы турында уйланыла. Үзе булган илләрнең табигатен- тау, чүлләрне тасвирлый, хәрабәләр күз алдына килеп баса. Шулай ук дөнья, тормыш гаделсезлегенә ризасызлык белдерә, алтын, акча хакимиятенә каршы чыга. Аныңча, кеше алтын арттыннан түгел, ә  гыйлем артыннан йөрергә тиеш. Хакани карашында алтын – ул ике яклы пычак, ул хәсрәт,ут,  ул бер каракка тиң һәм икейөзле гүзәлне хәтерләтә. Ул- мәҗүсиләр табына торган пот. Хакани фикерләре Тукайгача эзлекле  дәвам итә.

Ширванга кабат кайткач, шагыйрь бик нык эзәрлекләнә. Аны төрмәгә ябалалар, ул хәбестә (төрмәдә) утырганда, әсәрләр иҗат итә һәм аны “Хәбсия циклы” дип тамгалый. Бу әсәрләрендә патша сараен тәнкыйтьли, аны “Акула белән тулган диңгез, тар төрмә” дип игълан итә. Тора-бара Хакани тәхәллүсеннән баш тарта.  “Мин халык шагыйре”, дип белдерә. Әнисе белән

аралаша башлый. Төрмәдән чыккач, византияле туганнары ярдәме белән Көньяк Азәрбәйҗанга күчеп китә.

Хакани газәлләр дә язган. Аларда ул мәхәббәтне бик тә олылый. Үзенең лирик героен шәех Сәнанга тиңли. Сәнан – дәрәҗәле дин әһеле була, гүзәл христиан кызына гашыйк булып, аңа өйләнә, диннән баш тарта, Коръәнне утка яга, христиан тормышы белән гомер итә. Хакани үз геройларын шушы рухта иҗат итә. Мәхәббәт дингә, милләткә бәйле түгел, дип исбатлый. Аныңча, кешенең йөрәк хисләренә ирек бирергә кирәк.

Хакани шигырьләре сурәтләргә, фәлсәфи фикерләргә бай, шуңа күрә аның әсәрләре озак еллар әдәбият галимнәрен кызыксындырып килгәннәр. Күп шәрехнамәләр язылган. Ул азәрбәйҗан әдәбиятындагы ренессанс хәрәкәтен башлап җибәрүче булып тора.

## 2. Низами Ганҗәви- азәрбәйҗан ренессансының бөек шагыйре

**Низами (1141-1209) -** *Әбу Мөхәммәд Ильяс ибн Йосыф ибн-Зәки ибн-Муайад Низами Ганҗәви*– Шәрык, азәрбәйҗан әдәбиятының бөек шагыйре, фикер иясе. Тумышы белән Азәрбәйҗанның Ганҗә шәһәреннән, милләте ягыннан азәрбәйҗан булса да, әсәрләрен, нигездә, фарсы телендә иҗат иткән. Низами Ганҗәви – аның тәхәллүсе. Ул фарсы эпик поэзиясенә сөйләм телен һәм реалистик өслүб алып килгән, әдәби әсәр тудыруның яңа стандартларын эшләп биргән сүз остасы.

Коръән сурәләренә таянып, үзен иген чәчүче, киләчәк буыннар өчен “шигърият орлыклары чәчүче” дип атый. “Все мы сеятели. Один для другого”. Соңрак чорларда чәчүче образы мөселман һәм христиан әдәбиятларында да еш очрый. Татар әдәбиятында ул Мәүла Колый иҗаты аша Г.Ибраһимовка кадәр дәвам итә.

Үзенә кадәрге традицион халык авыз иҗаты һәм язма тарихи истәлекләрдәге темаларны дәвам итеп, үзенең әсәрләре аша Низами мөселман Иранын исламгача Иран белән тоташтырып куя. Фарсы телле әдәбиятның әйдәп баручы шагыйре буларак танылган әдипнең героик-

романтик иҗаты үзеннән соң бик күп гасырлар фарсы-таҗик иҗатчыларына гына түгел, бөтен Шәрык әдәбиятына зур йогынты ясап килә.

Шагыйрьнең биографиясе, тормыш һәм иҗат баскычлары хакында мәгълүматлар юк дәрәҗәсендә, нигездә, биографлар фаразларына гына кайтып кала. Кайбер галимнәр фикеренчә, Низами чигү эшләре белән шөгыльләнүче урта хәлле һөнәрче баласы була. Икенче бер версиягә караганда – әтисе Йосыф ибн Зәки - урта хәлле чиновник, ә әнисе Рәисә - чыгышы белән иранлы– көрд кабиләсе башлыгы кызы. Ничек кенә булмасын, Низами бик яшьли ятим кала, аны әнисенең абыйсы Хуҗа Гомәр тәрбияләп үстерә.

Низами заманы өчен шактый яхшы белем алган. Ул вакытларда Ганҗә шәһәре сәлҗүкләр солтанаты составына кергән, шәһәр тулысы белән фарсы мәдәнияте басымы астында яшәгән, халыкның да төп өлешен иранлылар тәшкил иткән, шунлыктан бу тирәлек Якын һәм Урта Көнчыгыш мәдәниятләре бергә очраша торган урын саналган.

Булачак шагыйрь күп телләр белгән, фәлсәфә, тарих, медицина, математика, астрономия, алхимия, риторика белән кызыксынган, музыка, хәрби сәнгать, архитектура, рәсем сәнгате, дин гыйлеме, диннәр тарихы, иран мифологиясе өлкәсендә дә тирән белемгә ия булган. Болар барысы да аның шигъри әсәрләрендә чагылыш тапкан, ә каләмен ул бик яшьли чарлаган.

Низаминың барлык яшәеше туган шәһәре белән бәйләнгән. “Сарай шагыйре” булудан баш тартып, ирекле һәм бәйсез иҗат юлын сайлаган. Шулай да, традицияләргә тугры калып, кайбер әсәрләрен феодалларга, хөкүмәт җитәкчеләренә, идарәчеләргә дә багышлаган. Аларга турыдан-туры хезмәт итмәсә дә, хакимият, сарай хуҗалары аны хөрмәт иткән, әсәрләре өчен матди ярдәм дә күрсәткәләгәннәр.

1170 еллар тирәсендә Дербент шәһәре идарәчесе Низамига төрки кабиләләрдән булган бер кол кыз бүләк итә. Афак исемле бу чибәргә шагыйрь бөтен йөрәге белән гыйшык тота, бик нык ярата, коллыктан азат итеп, аңа өйләнә. Афак аңа Мөхәммәд исемле ир бала бүләк итә. Ләкин

бәхетле гаилә тормышы кыска гомерле булып чыга, Афак кинәт кенә вафат була. Низами үзенең бөтен барлыгын улына багышлый, аны үзе тәрбияләп, аякка бастыра. Тагын ике тапкыр гаилә корып карый, ләкин, кызганычка каршы, алдагы хатыннары да озын гомерле булмый. Ул гомере буе Афакны гына яратып, аны гына уйлап яши, бөтен әсәрләрендә диярлек аны гәүдәләндерүче образлар иҗат итә.

Низами- гаделлек җырчысы. Ул гомере буе гаделлек эзләгән, беренче поэмаларыннан башлап, соңгы әсәрләренә кадәр гаделлек мәсьәләләрен яктыртуга зур урын биргән.

Низамига дөньякүләм танылуны "Хәмсә"се алып килә. Аның "Бишлеге" түбәндәге әсәрләрне берләштерә:

1. "Серләр хәзинәсе".
2. "Хөсрәү вә Ширин".
3. Ләйлә вә Мәҗнүн".
4. "Җиде гүзәл".
5. "Искәндәрнамә".

Низами әлеге җыентыгын 30 еллап иҗат итә. Анда кешелек җәмгыяте, халыклар бәхете, иҗтимагый гаделлек турындагы фикерләрен бирә. Һәр әсәрендә диярлек хыялга мөрәҗәгать итә. Шунлыктан аны И.Брагинский "Бөек хыялый" дип атый. Моннан тыш аның тагын 20 мең бәетне берләштергән "Диван"ы булганлыгы билгеле. Безнең көннәргә аннан 116 газәл, 30 робагый, берничә касыйдә һәм кыйтга гына килеп ирешкән.

**Беренче поэмасы- "Серләр хәзинәсе"**- гаделлек турындагы фәлсәфи-дидактик трактат. Биредә шагыйрь әдәп – әхлакка өндәүче хикәяләр аша үзенең гуманистик концепциясен тәкъдим итә. Бу әсәрен автор үзе суфый шагыйрь Сәнанга нәзыйрә дип саный, ләкин ул аны ренессанс рухында эшкәртә, ягъни күпмедер күләмдә суфыйчылык йогынтысы да катнашкан, дөньяви эчтәлекле әсәр тудыра. Үзе бу хакта:" Я слова по чужим образцам не взял, что велел мне сердце, то и сказал", - дип яза.

Низаминың бу поэмасы  катлаулы сурәтләргә, образ һәм фикерләргә бай, талантлы язылган, шулай да авыр әсәр исәпләнелә. Әсәр үзәгенә рухи кыйммәтләр салынган. Анда тоташ сюжет юк, ул 20 хикәятне үз эченә алган. Һәрберсенең башында бер әһәмиятле фикер әйтелә һәм  художестволы бер күренеш белән иллюстрацияләнә. Мәсәлән, “Яшәеш нигезе – гаделлек” дигән карашны алга сөргән “Әнуширван патша һәм аның вәзире” хикәяте Шәрык әдәбиятларында гаделлек символы буларак кабул ителгән Әнуширван патша һәм аның изге гамәлләренә багышлана.

“Серләр хәзинәсе”ндә халыкны изүче тираннар, канэчкеч идарәчеләр кискен тәнкыйтьләнә, хакимияттә торучыларның икейөзлелеге, саранлыгы, ялкаулыгы, ачкүзлелеге, халык җилкәсендә яшәүләре, кәеф-сафага корылган гамьсез хәятләре фаш ителә. Низами алтын, акча артыннан куып яшәүне гаепли, аларны Аллаһ җәзасы белән куркыта.  Үз хезмәте белән көн итүче саф күңелле гади кешеләрне аларга каршы куя, аларның әдәп-әхлакка корылган көнитешен, күркәм гамәлләрен югары күтәрә.

Низаминың үгет-нәсихәтләре үткен, тирән эчтәлекле. Кешене ул рухи байлыгы, акылы, белеме өчен югары куя. Аныңча һәр кеше игелекле, саф кңелле булып туа. Кешедә һәрвакыт яхшылык кына эзләргә кирәк. Бу – ренессан шагыйренең идеаллары.

Автор сүз сәнгатенә югары бәя бирә. Ул аны – “илаһи балкыш”, “Аллаһның асыл сыйфаты дип атый”. Аныңча, бакча корый, ефәк чери, һәрнәрсә тузанга әверелә, ә җил аны очыртып тарата, юкка чыгара. Дөньяда бары бер нәрсәүлемсез – ул сүз сәнгате. “Сүз сәнгате турында”гы бүлекне Низаминың иҗат программасы дип кабул итәргә мөмкин.

Низами фикеренчә, сүз – яшәү серләрен ачучы ачкыч. Сүз ул- галәм даны, дөнья бизәге. Сүз – иң зур көч, иң куәтле корал, аннан да үткен, аннан да нәфис берни дә юктыр. Сүз ярдәмендә иң катлаулы, бәхәсле. Мәңге чишелмәстәй мәсьәләләрне дә хәл итеп була. Сүзне болай олылау аннан соңгы әдәбиятта киң таралыш алып, Тукай, Исхакыйларгача дәвам итә.

“Серләр хәзинәсе”нә бик нәзыйрәләр, комментарийлар языла, төрки шагыйрьләр дә бу юнәлештә үз өлешләрен кертәләр, мәсәлән, Харәзминең нәзыйрәсе барлыгы билгеле.

**Икенче поэмасы – “Хөсрәү вә Ширин**” дә хатын-кыз образын үзәккә чыгара, Шириндә сөеклесе Афакның чалымнарын сурәтли. Әлеге әсәр композицион яктан камил. Геройлардан иң яхшы эшләнгәне, бөтен каршылыклары белән, психологик яктан тирән бирелгән образ – Хөсрәү. Әлеге әсәрне “шигъри роман”, “роман-дастан” дип йөртәләр.

Поэмада, нигездә, геройның эчке кичерешләре, мәхәббәт хисләре сөйләнелә. Шуңа күрә ул – романтик әсәр.

Романда берничә төрле мәхәббәт күзәтелә. Алар Хөсрәү, Ширин, Фәрһад образларына бәйле. Фәрһаднең Ширингә мәхәббәте- идеаль эфлатун мәхәббәте. Сөйгәне өчен ул үзен корбан итә.

Хөсрәүгә – тирән хисле, шашкын, дәртле җир, ягъни тән мәхәббәте кирәк. Һәрчак Ширинне уйнашлыкка этәрмәкче була. Ширин – Хөсрәүне үлеп яратса да, акылы – аның тозагына эләгергә мөмкинчелек бирми. Киресенчә, ул – Хөсрәүне үзгәртү юлына баса, аны тугрылыклы, гадел идарәчегә әйләндерү максаты белән яши, үз идеалына таба хәрәкәт итә, моңа ирешә дә.

Низами фикеренчә, дөнья мәхәббәттән барлыкка килгән,мәхәббәттән төзелгән. “Мир воздвигнут на любви”!!!Мәхәббәт булганга гына, магнит тимерне үзенә тарта, мәхәббәтсез таң да атмый, болытлар да еламый. Дөньяда бары тик мәхәббәт кенә чын, калган барысы да – ялган уен. Мәхәббәтсез кеше – үле кеше. Гайрәтле арслан да мәхәббәтсез берни тормый. Кеше иң элек- мәхәббәт колы, корбаны. Кеше песине генә булса да яратырга тиеш. “Хоть в кошку влюбись!”

Низами мәхәббәтнең төрле төрләрен каршы куя. Ул мәхәббәттә иң элек әхлаклылыкны алга сөрә. Шагыйрь фикеренчә, никяхлы мәхәббәт – мөселман дөньясының яшәү нигезе. Шундый мәхәббәт кенә аклана. Шул ук вакытта

Низами күпхатынлылык тарафдары түгел, бу аның һәр әсәрендә диярлек тоемлана. “При множестве жён- мужчина будет одинок!”

“Хөсрәү вә Ширин” поэмасына да бик күп нәзыйрәләр язылган, төркиләрдән Котб иҗатында очратабыз. Котб поэмасында образ-сурәтләр төрки җирлеккә яраклаштырылган, ислам дине тәэсире нык сизелә. Ә Низами әсәрендә исә – утка табынучылар- зәрдәштилек дине шактый көчле чагылыш тапкан. Аның поэмасындагы Ширин- әрмән патшасы, ә Котбта – төркиләрдән. Низамида да, Котбта да хатын-кыз ирләрдән акыллырак, көчлерәк, белемлерәк, әхлаклырак итеп бирелә. Бу – яңарыш әдәбиятының мөһим сыйфатларыннан.

Низамига искиткеч шөһрәт китергән өченче поэмасы – **“Ләйлә вә Мәҗнүн”** – фаҗигале мәхәббәт тарихына багышланган. Ул Шекспирның “Ромео и Джульетта”сын хәтерләтә. Поэманың геройлары – Ләйлә һәм Кайс – реаль шәхесләр. 7 гасырда Гарәбстанда Ләйлә исемле бәдәви кызына гашыйк Кайс яшәгән. Алар арасындагы фаҗигале мәхәббәт тарихын Низами мәңгеләштергән. Әсәр ширваншаһ Ахситан I кушуы буенча, аның истәлегенә язылган.

**Поэманың кыскача эчтәлеге.** Гарәбстан ярымутравында яшәүче әмириләрнең бик игелекле, юмарт, гадел кабилә башлыклары була. Ни үкенеч, бу гаиләнең баласы булмый. Аллаһка озак ялварганнан соң, Кайс исемле уллары дөньяга туа. Барлык иптәшләре арасында бар яктан да килгән, шигырьләр язучы талантлы егет булып үсеп килә. Ләйлә белән кечкенәдән дус булып, бергә уйныйлар, бергә укыйлар, дуслык тора-бара мәхәббәткә әйләнә. Башка сабакташлары арифметикадан мәсьәләләр чишкәндә, алар мәхәббәт сүзлеге төзеп, үз дөньялары белән яши башлыйлар. Ләкин көчле мәхәббәт хисләрен башкалардан яшерә алмыйлар. Ләйләне күргә, Кайс үзе дә сизмәстән рухланып, шигырьләр сөйли, җыр көйли башлый икән. Башкалар аның күңел халәтен аңламыйлар, аны “ Мәҗнүн” ягъни “Юләр” дип йөртә башлыйлар. Кеше сүзеннән, гайбәттән куркып, туганнары Ләйләне Кайстан качыралар. Егет урамнар, базар эчләренә кереп, кайгысыннан, елый-

елый, җырлый-җырлый моңланып, Ләйлә хакында уйланып, бәргәләнеп йөрүен дәвам итә. Аны күргән һәркем артыннан да, йөзенә карап та “Әнә юләр, юләр килә” дип көлә торган булалар. Кайс мәхәббәттән авырып, чүлгә китә, үзе көннәрен шунда үткәрә, төннәрен качып, Ләйләләр өенә килеп, сөйгәне бикләнгән ишек тоткаларын үбеп китә торган була. Көннәрнең берсендә шулай хәтта Ләйләнең йөзен дә күрү бәхетенә ирешә, ләкин бу аны соңгы тапкыр күрүе була.

Юләрләнгән улын кызганып, әтисе Ләйләнең әтисенә күп бүләкләр төяп, кыз сорарга килә. Ләкин “кызыбызны күрә торып юләргә бирмибез” дип, аларны кире боралар. Ләйләне тулысынча югалтуын аңлаган Кайс, тауларга китеп югала. Әтисе, аны дәвалау максатыннан, үзе белән хаҗга алып бара, ләкин ул үзенә дәва түгел, ә Ләйләсенә бәхет сорый, һәм Аллаһка “Минем мәхәббәтемне күкләргә иңдер” дип ялвара. Шул рәвешле, егет мәңгелек мәхәббәт чиренә дучар була.

Ләйлә дә, үз чиратында бик борчыла, кайгыра, сагыштан йөзләре сула, Кайс килмәсме икән, күренмәсме дип, йорт түбәләренә менеп, тирә-якны күзәтә. Бакчаларда йөргәндә, Кайс язган җырларны ишетеп, йөрәге әрни, ә аның үзен көнчел, кара эчле кешеләр: “Әнә Кайс сиңа мәхәббәтеннән җүләрләнгән, ә син тынычлап, күңел ачып, бакчада йөрисең” дип, мыскыллый торган булалар. Әти-әнисе Ләйләне коткаруның бердәнбер чарасы дип аны кияүгә бирүне табалар һәм кияү буласы кеше озак көттерми – яшь, бай феодал Ибн Сәләм дигән кешегә вәгъдәләшәләр.

Бу хәбәрне Нәүфәл исемле көчле гаскәр башлыгы ишетеп бала, ул Кайсны бик хөрмәт итә, егетнеүзенә чакыртып ала. Аны тынычландыра, мәҗлесләр оештыра, ярдәм итәргә вәгъдә бирә. Иң көчле батыр егетләрен генә җыеп, Ләйләнең әтисенә яу белән бара. Өч тапкыр баралар, өчесендә дә җиңәләр, ләкин кызын юләргә кияүгә бирүдән коллыкны өстен күргән ата барыбер ризалашмый. Кайс, тәмам өметен өзеп, янәдән далага күченеп китә. Кош-кортлар, җәнлекләр белән дуслаша, алар, үзләренчә, Кайсны саклап, бергә тереклек итәләр.

Ибн Сәләм бик кыйммәтле, зиннәтле бүләкләр төяп, никяхлашырга килә, бик зур туйлар үткәреп, Ләйләне үзе теләмәгән кешегә кияүгә биреп җибәрәләр. Туйдан соң никяхлы хатыны белән ләззәтләнергә теләгән кияүне Ләйлә кабул итми, якынлашкач, аның яңагына суга. Хатынының матурлыгы белән әсирләнгән Ибн Сәләм моңа ризалаша, аның матурлыгына гына сокланып яшәргә әзер булуын белдерә. Романтик шагыйрь буларак, Низами геройлары янәдән матурлыкны югары күтәреп, аның алдында сәҗдә кылалар. Ләйлә ире белән тән матурлыгын уртаклашмаса да, Ибн Сәләм гомере буе аңа тугрылык саклый. Ләкин тора-бара җавапсыз мәхәббәтеннән авырый башлый.

Бу хәбәрне Кайска җиткерәләр, ул Ләйләнең үзенә тугрылык саклавын, мәхәббәттән аның да газаплануын белеп яши. Ләкин шул халәттә дә Ибн Сәләмнән көнләшә, чөнки ул аның йөзен күрү бәхетенә ия, ә мин моннан да күптән мәхрүм ителгән, ди.

Улының кайгысын күтәрә алмыйча, әтисе үлеп китә, бу хәбәрне ишеткәч, Кайс бераз аңына килгән кебек була, тетрәнеп китә, ләкин инде “Ләйлә” исеменнән башканы аңларлык халәттә булмаган егет, ата-ана кадерен тоярлык, югалту кайгысын кичерерлек булмый, кош-кортлары белән әвәрә килүен, йолдызларга табынуын дәвам итә.

Көннәрнең берендә Ләйләдән хат ала, Ләйлә үзенең тугрылык саклавын, бик газаплануын, үзенең аңа һаман “дус” булуын һәм “мин мең мәҗнүннән дә юләррәк” дигән сүзләр яза. Озакламый Мәҗнүннән җавап та килә. Үзеннән бигрәк Кайсны җәлләгән хатын сөйгәненә очрашу бүләк итәргә уйлый. Мең төрле хәйлә табып, очрашу урыны билгели. Ул әйткән пальма урманына Кайс ут тизлегендә, сусызлыкка тилмергән кеше бер тамчы су эчәргә ничек килсә, шул халәттә, шашып-тилереп килгән була. Ләйлә сөйгәненә 10 адым калгач, туктап кала, ирен яратмаса да, аңа хыянәт итә алмаячагын белдерә. Кайсның шигырь укуын, җырлавын үтенә. Егет чынга ашмаган хыяллары, сагышлары, киләчәге булмаган көчле сөюялкыннары турында озак җырлый. Җырлый-җырлый Ләйләсе яныннан

китеп бара, ул да, бу очрашуның йөрәк газапларын тагын да арттыруын гына аңлап, кире өенә кайта.

Озак та үтми, Ибн Сәләм, җавапсыз мәхәббәт чиреннән дәва таба алмыйча, якты дөньядан китә. Гореф-гадәтләр буенча, ул ике ел кайгырып, иренең үлемен көйләп яшәргә тиеш була. Моңарчы, бәхетсезлегеннән качып еларга мәҗбүр булган Ләйлә, беркемнән дә курыкмыйча, теләгәнчә борчылу, елау, сыктау бәхетенә ирешә. Шушы сагышыннан Ләйлә инде озакламый җан бирә. Аның каберен тырмый-тырмый, елый-елый, җырлый-җырлый Мәҗнүне дә якты дөньяны калдырып китә. Үзе кайгырткан кош-кортлар, җәнлекләр, аның мәетенә 1 ел буе кеше җибәрмиләр, бары шуннан соң гына Кайсны Ләйлә янына җирлиләр. Алар кабере өстенә чәчәкләр утырталар. Бу каберлек гашыйкларның сәҗдә урынына әверелә.

**“Җиде гүзәл” поэмасы –** Низаминың иң оста язылган, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан иң камил әсәрләреннән. Ул башта “Бәһрәмнамә” дип аталган, тора –бара шушы исемгә алыштырыла. Ул ильдегизидларның дошманы булган  атабекларының берсе – Мараги Ала ал-Дингә багышлап язылган.

Поэманың төп герое – Бәһрәмгүр. Ул реаль шәхес, сасанидлар династиясенең бер патшасы. Ул Шәрык әдәбиятында  Дон Жуан кебек данлыклы образ. Ауга йөрергә яраткан, күп кәнизәкләр тоткан, әмма һәрбер әсәрдә иң яраткан сөяркәсе белән бергә сурәтләнә. Фирдәүсинең “Шаһнамә”сендә аның Азадә белән мәхәббә маҗаралары тасвирланса, Низамида аның янәшәсендә яратканы – Фетнә. Исеменә кушылган –“гүр” кушымчасы- Шәрык әдәбиятында гадәттә ауга йөрүче булуын аңлата, ләкин Низами бу кушымча белән аның үлемсезлегенә ишарә ясый. Әсәр ахырында ауга чыккан Бәһрәм тау куышына кереп китә һәм әйләнеп чыкмый. Аның шулай хәбәрсез югалуы – үлемсезлек билгесе булып аңлатыла.

Әсәрдә ике тема янәшә килә: гадел патша, гадел идарә һәм мәхәббәт темасы. Бәһрәмнең тормышы Низами тарафыннан туган көненнән алып,

үлгәнчегә кадәр тасвирлана, ягъни әсәр биографизм принципларына корылган.

**Поэманың кыскача эчтәлеге.**

Ирандагы явыз Ездигирид патшаның тәхет варисы – улы булмый. Озак вакыт ялварганнан соң Аллаһ аңа ир бала бүләк итә- дөньяга Бәһрәм аваз сала. Бик көтелгән бала булса да, әтисе аны яратмый, ниндидер якынлык хис итми, бердәнбер теләге- тәхетен калдырырлык дәвамчысын күрү була. Дошманнары үтермәсен дип, аны Йеменга – Ногман патшага җибәрләр. Ногман патша аны үз баласы кебек ярата, кадерләп, үз улы белән бергә тәрбияли, укыта, җаны ни теләсә, шуны үти. Ләкин тумышы белән чагыштырмача салкынча климаттан булганга, Йеменның тынчу һавасы, кызу кояш Бәһрәмгә начар тәэсир итә. Егетне салкынча урында яшәтергә кирәклеген аңлап, рум архитекторы Симнарга тау куышлыгында сарай салдырта. Бу искиткеч гүзәл сарайга “Һаварнак” дип исем кушалар. Әлеге хезмәте өчен Ногман патша Симнарга бик күп байлык бирә. Сөенеченнән нишләргә белмәгән төзүче егет, беркатлыланып патшага болай ди: “ Мин синең бу дәрәҗәдә юмарт икәнлегеңне белмәдем. Белгән булсам моннан мең өлеш яхшыракны төзегән булыр идем. Әгәр теләсәң, иртәгә үк яңаны төзергә тотынам”. Бу сүзләрне ишеткәч, Ногман патша ни уйларга да белми, кинәт аның башына бик ямьсез уй килә: “Әгәр моны җибәрсәм, димәк ул иртәгә үк кемгәдер яхшырак сарай сала башлаячак”. Менә шушы көнчелек хисе патшаның юмартлыгыннан өстен чыга, ул егетне үзе төзегән сарай түбәсеннән ыргытырга куша. Шулай итеп, Симнар вафат була, ләкин вөҗдан газабы Ногманны бик нык эзәрлекли, көннәрнең берендә ул тавыш-тынсыз гына сарайдан китеп югала.

Бәһрәм үзенең сараенда матур гына тормыш алып бара. Көннәрнең берендә сараен карап йөргәндә, ул моңарчы үзенә таныш булмаган залга килеп чыга. Андагы стенага – җиде гүзәл кыз портреты ясалган була һәм алар арасында горур Бәһрәм рәсеме балкый.  Симнар, Бәһрәмнең киләчәген шул рәвешле 7 гүзәл хатын белән яшәешкә юрый һәм моңа ишарә рәвешендә

шушы залны формалаштырган була. Мондый киләчәк турында уйлау гына да егеткә күп дәрт өсти, хезмәтчеләренә бу залга беркемне дә кертмәскә чакыра, үз буш вакытларын гел шушында үткәрә, киләчәккә планнар корып яши башлый.

Шулай матур гына яшәп ятканда, әтисе вафат була, дошманнары Иран җирләрен, аның тәхетен яулап алалар. Бәһрәмгүр сугыш белән әтисенең тәхетен кире кайтара, идарәне үз кулына ала. Бәһрәм уен-көлке, күңел ачулар белән бик мавыга, кәнизәкләрен дә бик еш алыштыра. Атнаның бары 1 көнен генә эштә, калганын мәҗлесләрдә үткәрә торган була. Шуның өчен илгә җәфа килә- Аллаһ 4 ел буе Иран җирләрен ачлык белән куркыта. Ләкин шул ачлык еллары Бәһрәмнең гадел патша булуын дәлилләүгә дә хезмәт итә. Бәһрәм амбарлардагы бөтен ашлыкны ярлыларга, халыкка тарата. Анысы беткәч, казнадагы акчаларына байрак кешеләрдән сатып алып икмәк тараттыра. Үз илендә беткәч, чит җирләрдән алдырта, шул рәвешле Иран халкын үлемнән коткара.

Бу афәттән котылгач, Иран тагын бәйрәмчә яши башлый. Хәтта эшчеләргә дә төшкә кадәр генә эшләргә рөхсәт ителә, калган вакытларында ял итәргә боера. Шундый көннәрнең берсендә сөеклесе Фетнәне алып, Бәһрәм, гадәтенчә, ауга китә. Ауда, әлбәттә, аңа тиңнәр булмый. Ләкин горур Фетнә генә никтер аны мактамый, мактау ишетәсе килеп биргән соравына да “Син бу эшләрне тәҗрибәң күп булганга гына яхшы башкарасың. Бу һичкенә дә синең талантың түгел, бу синең көчеңне күрсәтми” дип әйтеп сала. Егетнең моңа бик нык ачуы килә. Ул аны бер полководецына бирә һәм үтерергә куша. Ләкин Фетнә аңа бик нык ялынгач, үз өендә асрау итеп калдыра. Бу гаскәринең сыеры бозаулый, ул шул бозауны карап үстерә. Көн саен 60 баскыч югарылыкка аны җилкәсенә салып алып менә, кире алып та төшә. Алты ел буе ул шушында хезмәттә була. 6 яшьлек зур үгезне һаман шулай җилкәсендә йөртүен дәвам итә.

Фетнә Бәһрәмне бик сагына һәм хәйлә корып, полководецтан аны кунакка чакырттыра. Патша баш тартмый, кунакка килә, җилкәсенә ирләр дә

күтәрә алмаслык үгез асып, баскычлардан җил-җил йөрүче яшь, гүзәл ханымга таң кала. Йөзен күргәч, үзенең Фетнәсен танып ала, аның исән булуына бик сөенә, гаскәриенә күп рәхмәтләр укый. Кызның шул зур малны җилкәсендә йөртә алуын- үзен чыныктырудан килгәнлеген әйтә, кызның үз адресына әйткән теге сүзләрен исенә төшерә, аннан гафу үтенеп, Фетнәне кире сараена алып кайта.

Ләкин тагын тыныч кына яшәп ятканда туранлылар, чиннар сугыш белән килә. Бәһрәм аларны тармар итә. Дошманнарын җиңгәч, янәдән теге 7 гүзәл турында уйлый башлый. Озак та үтми, 7 илнең 7 гүзәл патша кызын яучылап, өйләнә. Бер-бер артлы күп-күп бирнәләр, байлык төяп, 7 гүзәл аның сараена килеп тула. Бу кылар өчен Бәһрәм төрле төсләрдән сарайлар салдырта, алар үз рухи дөньяларына туры килгәнен сайлап, шул сарайларда яши башлыйлар. Бәһрәм көн дә берсе янында төн үткәрә, алар берсеннән берсе уздырып, ирне ләззәткә күмәләр, кызыклы экиятләр сөйлиләр.

Шимбә көнне баштан-аяк карадан киенгән Һиндстан гүзәле (Сатурн планетасы) аны көтә. Аның экияте дә үзе кебек шомлы тоела Бәһрәмгә. Якшәмбе көн - төрекмән кызы – символы – Кояш, төсе – сары. Дүшәмбе көн – Хорезм кызы – яшел төс- символы – Ай; Сишәмбе көн – словян кызы – кызыл төс- Марс планетасы; чәршәмбе көн- Мәгъриб кызы- зәңгәр төс- Меркурий планетасы; Пәнҗешәмбе – Византия гүзәле- Юпитер (мөштәри) планетасы, сандал төсе; Җомга көн- Иран гүзәле – ак төс – Венера (Зөһрә) планетасы. Болар арасыннан словян кызы аны матур экиятләре, рәхәт ләззәтләре белән таң калдыра торган була. Аның янында вакыт үткәнен дә сизми Бәһрәм. Кызыл төсне Низами шатлык төсе итеп гәүдәләндерә.

Атнаның соңгы төнен Бәһрәм Иран гүзәленә багышлый. Аның исеме дә –Дурус, ягъни саф дигән мәгънәдә. Иң самими, иң күңелле экиятләрне аннан ишетә патша.

Шул рәвешле поэмадагы хисләр дә карадан ак төскә – саф мәхәббәткә таба хәрәкәт итә. Бәһрәм түбән баскычлардан күтәрелгән кебек, җенси- түбән

мәхәббәттән әфлатун мәхәббәтенә күтәрелә. Соңрак хатыннарыннан бөтенләй баш тарта. Карадан акка таба хәрәкәт – илаһияткә таба бару.

Поэмада астрологик мәгълүматлар күп бирелә. Астрологиягә мөрәҗәгать итү- дөньявилыкка борылу – ренессанс билгесе. Ислам динендә йолдызларга карап, язмыш юрау- начар бәяләнә. Юрап китерелгән әлеге хатыннарыннан Бәһрәм ахырда баш тарта. Ислам дине бары тик никяхлы, әхлаклы мәхәббәтне генә таный. Низами да һәр поэмасындагы кебек моңа тагын бер кат басым ясый.

**“Искәндәрнамә” поэмасын** Низами гомеренең соңгы елларында яза. Ул, исеменнән үк аңлашылганча, Александр Македонскийга багышланган. Шәрык әдәбиятында традицион образ булып тора, аның турында күп кенә фольклор һәм әдәбиә сәрләр иҗат ителгән. Аларда Искәндәр – гадел патша, шәһәрләр төзүче уңай герой буларак сурәтләнә. Чынлыкта исә, ул бөек җиһангир, илләрне, халыкларны басып алучы, аларны үзенә буйсындырганда күп кан коючы, гаделлек,кешелеклелек сыйфатларыннан шактый ерак торган зат.

Низами поэмасы ике өлештән: “Дан” (“Шәрәфнамә”) һәм “Бәхет” (“Икалнамә”) китапларыннан тора.

Беренче китапта Македонскийның биографиясе тергезелә, Аристотель белән дуслыгы сурәтләнә, тиран патшаларга каршы 6 походы тасвирлана. Идел буена – Караңгылык патшалыгына кылынган җиденче походы аеруча үзенчәлекле бирелә. Искәндәр Идел буена тереклек суы эзләп килә, ләкин таба алмый, шунлыктан башка җир кешеләре кебек үк үлемгә дучар була.

Искәндәр Идел буена Хөзер пәйгамбәр белән килә. Хөзер тереклек суын табып, коенып өлгерә, ләкин Искәндәр килеп җитүгә су юкка чыга. Шул рәвешле ул 33 яшендә вафат була, бальзамга төреп, иленә алып кайталар, кулына бер уч туфрак салалар, ягъни барыбыз да, кем булуыбызга карамастан, туфракка әйләнәчәкбез, дигән фикер үткәрелә.

Икенче китапта Македонский дөнья хакимнәре- философлары белән аралаша: Платон, Аристотель, Сократ һ.б. Акыллылыгы, гаделлеге өчен аңа

пәйгамбәр дәрәҗәсе бирелә. Бу шулай ук ренессанс әдәбияты өчен хас сыйфат.

Күктән иңгән тавыш аңа дөньяның 4 ягына сәфәр чыгарга куша. Гаделлек идеалларының тормышка ашуын Искәндәр төньяк кабтләләрдә таба. Анда бай һәм ярлылар да, сугышлар да юк, кешеләр тыныч тормышта бик бәхетле гомер кичерәләр. Аларда караклар да, кешене буйсындырып торучы, үзләренә кол ясаучы идарәчеләр дә юк, һәркем ирекле хезмәттә. Кешеләр җәмгыять белән акылга, югары әхлак кагыйдәләренә буйсынып идарә итәләр. Шул рәвешле Низами 12 гасырда ук кешеләр ирекле, бәхетле яшәүче коммунистик җәмгыятьне сурәтли. Бу поэмасы белән дә Низами гадел патша, гадел җәмгыять идеяләрен яклый, гуманлылык, кешелеклелеккә дан җырлый.

Әлеге поэмада да хатын-кызны ирләр белән тигез куя, хәтта аларны акыллырак та итеп сурәтли. Бу әсәрдә андый көчле образ- Нушәбә. Ул- азәрбәйҗан патшасы, үзе гзәл, акыллы, җаны – фәрештәгә тиң. Бу дәүләттә һәр эшне хатын-кызлар башкара, ә ирләр кошлар сыйфатында төрле якларга таралышкан.

Нушабә - таҗ да, пәрәнҗә дә киеп йөрми, төннәрен догада үткәрсә, көндезләрен бәйрәми тормыш алып бара. Искәндәр Нушабә биләмәләренә килгәч тә, хатын үзен бик ипле, бик горур тота, аның алдына баш иеп килми, үз дәрәҗәсен белеп кенә эш итә, аңа бүләкләр җибәрә. Македонскийның моңа бик ачуы килә, илче киемнәре киеп, аның сараена китә. Ләкин үз-үзен тотышыннан Нушабә аны бик тиз танып ала, үзе белән янәшә тәхеткә утырта. Искәндәр үзенең кемлеген белгертмәскә тырыша, илче булып кылана. Мәҗлескә аның ефәккә чигелгән рәсемен алып чыгалар, кунак куркуга төшә, ялганы тотылганлыгын аңлый, ә моның өчен Шәрыкта җәза бик көчле була. Искәндәр, горур елмаеп үләргә, дигән карарга килә.

Нушабә аны бик нык сыйлый, өстәл сый-нигъмәттән сыгылып тора, хәтта кыйммәтле ташлар да китерттерә. Искәндәр бик аптырый һәм “Боларны бит ашап булмый, нигә китердегез?” дип сорарга мәҗбүр була. “Кыйммәтле,

зиннәтле ташларны ашап булмагач, нигә син туктаусыз сугышлар, яулар алып барасың? Нәрсә җитми сиңа?” дигән сорау белән җавап кайтара патша-хатын. Искәндәр хатынның зирәклегенә таң кала һәм “синең акылың ирләрнекеннән дә югарырак” дип, соклануын аңа да җиткерә. Нушабә: “Әйе, мин - ана арыслан, ә син- ата. Ә ана арыслан сугышта ата арысланга тиң”, ди. Шул рәвешле Низами хатын-кыз акылы алдында баш ия, аларны һәр яктан камил зат, ирләр белән тигез дәрәҗәгә лаеклы булуларын тагын бер кат раслый.

Искәндәр гаскәре белән юлын дәвам итеп, кыпчаклар яшәгән җирләргә килеп чыга. Кыпчак кызларының гүзәллегенә таң калалар, гаскәре сугышка барудан баш тарта. Македонский кыпчак кызларына пәрәнҗә кияргә әмер бирә, ләкин бер генә кыз да йөзен капларга ризалык бирми, чөнки бу гадәт аларда юк, яулык ябыну элек-электән кыпчак хатыннарына ят әйбер була. Низами тагын бер кат хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен калкытып куя.

Хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсенә ялгап, автор сәнгатькә мөнәсәбәт проблемасын да күтәрә. Сынлы сәнгать әсәрләре, музыканың кеше әхлагын төзәтүдәге әһәмиятен игътибар үзәгенә куя. “Сәнгать – әхлак төзәтә” дигән фикер Аристотельдән килә. Низами, ренессанс шагыйре буларак, сәнгатьне тыюларга каршы чыга. Бу Искәндәр сугышчыларының кыпчак гүзәлләре белән очрашу күренешендә дә чагыла.

Кыпчак кызларын буйсындыра алмагач, аксакаллар Искәндәргә чишмә буена хатын-кыз сыны ясарга киңәш бирәләр. Ул ап-ак мәрмәрдән, челтәр астында кара мәрмәрдән ясала. Кыпчак кызлары бу сынны бик ошаталар, аңа охшарга тырышып, гүзәллекне пәрдә астына яшерүгә дә ризалашалар. Низами бу күренеш аша сәнгатьнең тәэсир көчен, аның әмерләрдән, боерыклардан күпкә өстен, күпкә көчлерәк булуын дәлилләргә омтыла.

Моннан тыш шагыйрь музыкага карата булган тискәре карашларны юкка чыгару юнәлешендә дә эш алып бара. Мәгълүм булганча, Платон музыка кешеләрнең әхлагын боза дип исәпләгән. Аныңча, музыкантлар, шагыйрьләр – хис кешеләре, алар акылга сыймаслык эшләр эшләргә сәләтле,

моның белән әхлак кагыйдәләрен бозалар. Шуңа күрә Платон аларны үзенең “Идеаль дәүләт”енә дә кертми. Платон фәлсәфәсе аша мондый тискәре караш Коръәнгә дә үтеп керә. Шул рәвешле татарларда да 20 йөз башына кадәр музыкага тискәре караш саклана.

Ренессанс әдәбиятында шагыйрьләр Платонның музыканы тыюна каршы чыгалар, бәхәсләшәләр. Бу нисбәттән Низами да Платон белән каршылыкка керергә батырчылык итә – музыка кораллары ясата һәм көй чыгарта. Платон көйләрне тыңлаганда, кешеләр, ирексездән, биеп китәләлр, ач икәнлекләрен дә оныталар. Бүреләр сарыкны ашамый, арыслан боланга ташланмый. Күкләрдә туган музыка хайваннарны да, кешеләрне дә экстатик хәлгә китерә, ягъни хуштан яздыра, аларны акыллырак, мәрхәмәтлерәк итә, дөньяда бара торган хәлләрнең асылын аңларга ярдәм итә. Шул рәвешле Низами музыканы идеаллаштыра.

Низаминың “Хәмсә”се, биш әсәре Шәрык халыклары шигъриятенең озак гасырлар дәвамында үсеш юлын билгеләп киләләр. Һәр мәшһүр шагыйрь ул сайлаган сюжетларга я нәзыйрә, я җавап язырга омтылган. Галимнәр фикеренчә, бер Ләйлә вә Мәҗнүн мотивына гына да фарсы һәм төрки телләрдә йөзләгән поэма иҗат ителә. Низами эзеннән барып, Шәрыкнең иң данлыклы әдипләре – һиндстанлы Әмир Хөсрәү Дәһләви (1253—1325), фарсы- таҗиклардан Габдрахман Җәми (1414—1492), үзбәкләрдән Алишер Нәвоиләр (1444—1501) үз “Хәмсә”ләрен тудыралар

Низами иҗаты Шәрык әдәбиятының гына түгел, Бөтендөнья әдәбиятының зур казанышы, зур хәзинәсе. В.Гете аны “һәр халыкның, һәр заманның иң даһи 7 шагыйренең берсе” дип санаган. 1991 ел шагыйрьнең тууына 850 ел тулу уңае белән ЮНЕСКО тарафыннан Низами Ганҗәви елы дип игълан ителгән һәм дөньякүләм бик күп төрле мәдәни чаралар үткәрелгән. Бу вакыйга үзе генә дә Низаминың даһилыгын тагын бер кат раслый.

**Түбәндәге сорауларга җавап бирегез:**

1. Төрки яңарышы хакында ниләр исегездә калды?
2. Татар әдәбияты үз тарихында ничә яңарыш чоры кичерә?
3. Татар ренессанс әдәбияты вәкилләрен атагыз.
4. Азәрбәйҗан яңарышын кайсы әдип башлап җибәрә?
5. Хакани касыйдәләренең үзенчәлеге нәрсәдә?
6. Низами иҗатының асыл сыйфатларын билгеләгез.
7. Нәрсә ул “Хәмсә”? Кемнәр иҗатында очрый?

**Лекция №2. Төрки әдәбиятлардагы ренессанс тарихы**

Өйрәнү өчен тәкъдим ителгән сораулар:

1. Мөхәммәт Фөзули иҗаты.
2. Нәвои иҗаты-үзбәк яңарыш әдәбиятының югары ноктасы.

**1. Мөхәммәт Фөзули иҗаты**

***Мөхәммәт ибн Сөләйман Фөзули*** **(1494-1558)** - азәрбәйҗан халкының иң атаклы шагыйрьләренең һәм фикер ияләренең берсе, азәрбәйҗан яңарыш әдәбияты вәкиле. Үзенең шигъри һәм фәлсәфи әсәрләрен азәрбәйҗан, фарсы һәм гарәп телләрендә иҗат иткән бу әдипне барлык Якын һәм Урта Көнчыгыш илләрендә үз итәләр, яратып укыйлар.

Чыгышы белән азәрбәйҗан, Гыйракта туа, Багдад шәһәрендә яши, белем ала. Ул үзенә кадәр язган язучыларның иҗаты белән кызыксына, таныша. Төп жанры – газәл. Фөзули аны әдәбиятның иң югары жанры дип саный. Ул газәлне иҗтимагый-фәлсәфи эчтәлек белән баета, аның газәлләренең төп үзенчәлеге - сурәтләү байлыгында, аның газәлләрен башка авторныкы белән бутап булмый, алар аерылып тора.

Фөзули - суфый шагыйрь. Ул традицион образларны сурәтләү ягыннан үзеннән элгәреге иҗатчыларны шактый узып китә. Аның шигырьләрендә традицион суфыйчылык символларыннан тыш, нур – фәлсәфәсенә бәйле яктылык символлары да кулланыла: ай, кояш, йолдызлар, энҗе-мәрҗән,

алтын-көмеш һ.б. Шагыйрьнең суфыйчылык рухында язылган поэмалары да бар. Аларда суфыйчылык тәгълиматының төшенчәләре аңлатыла.

Фөзули газәлләрендә дә мәхәббәт темасы әйдәп бара. Аныңча, һәр кешенең эчке дөньясы – зур байлык. Аның лирик герое сөйгән ярын Мәҗнүннән дә катырак ярата. Аның газәлләрендә мәхәббәтнең ике төрле гәүдәләнеше күрсәтелә: моңсу газаплы һәм илаһи күтәренке. Бу шагыйрьнең дөньяны кабул итү үзенчәлеге белән бәйле. Фаразларга караганда, Багдадта укыганда ул үзенең гарәп теле укытучысының кызына гашыйк була. Ләкин бу гыйшык кавышуга китерми, алар бергә була алмыйлар. Кабул ителмәгән мәхәббәттән Фөзули сөю чире белән авырый башлый.

Фөзули, ренессанс шагыйре буларак, мәхәббәтне Аллаһ бүләге итеп кабул итә һәм мәхәббәт турында язарга яратуын да шуның белән аңлата. Ә мәхәббәткә аны җир гүзәлләре рухландыра. Ул мәхәббәтне илаһи чыганак итеп карый. Фөзули карашынча, җан һәм тән мәхәббәтебергә яшәргә тиеш.

Шул ук вакытта, суфый шагыйрь буларак, ул күбрәк илаһи мәхәббәт турында яза. Аллаһка якынаю өчен бары тик җан мәхәббәте аша гына хәрәкәт итеп була дип саный. Шунлыктан суфый шагыйрьләр калебне – Аллаһ йорты дип исәплиләр.

Шулай ук, романтик шагыйрь буларак, Фөзули матурлык алдында баш ия. Аның иҗатының таҗы – “Ләйлә вә Мәҗнүн” поэмасы. Аны “Дөнья шигъриятенең энҗесе” дип югары бәялиләр. Фөзули геройлары тышкы яктан да, эчке дөньялары ягыннан да тиңдәшсез гүзәлләр. Башка щдиплщрдщн аермалы буларак, шагыйрь Кайсның тышкы кыяфәтенә зур игътибар бирә, аны мәһабәт гәүдәле, чишмә кебек татлы телле итеп сурәтли. Аның үзенә карап та, һуштан егылырга мөмкин, дип саный. Ләйлә исә, тагын да нәфисрәк, нәзакәтлерәк, ихласрак итеп бирелә. Кайстан аерылу газабы кичергән кызның кайгысын күрсәтү өчен, Ләйләне ай, шәмдәлләр, күбәләкләр, искән җил белән әңгәмәләрен тасвирлый.

Ләйлә һәм Мәҗнүн мәхәббәте – әфлатун мәхәббәте, пантеистик рухта аңлатыла, ягъни җаннары бергә кушыла.

Үзенең әсәрләрендә патшаларны, дин әһелләрен гаделлеккә чакыра. Дөньяда чама белән яшәргә кирәклеген искәртә. “Йөрәк дусты” исемле касыйдәсе билгеле. Ул - Хакани әсәренә нәзыйрә. Бу касыйдәдә феодаль изүләрне тәнкыйть итә, крестьян мәнфәгатьләрен яклый.

Фөзули шагыйрь генә түгел, прозаик та. Әзербайҗан әдәбиятына ул яңа жанр алып килә, ул – “Шикаятьнамә”- ягъни - зар. Бу жанр үз заманының гаделсезлекләрен тәнкыйть итә. Зарлар язу барлык тцрки щдщбиятларга да хас. Тукайның “Мулланың зары” әсәре дә шушы традицияләрне дәвам итеп язылган.

Фөзули – әзербәйҗан ренессанс әдәбиятының соңгы вәкиле.

## 2. Нәвои иҗаты-үзбәк яңарыш әдәбиятының югары ноктасы

***Мир Низаметдин Гыясетдин Алишер Нәвои*** **(1441-1501) -** үзбәк яңарыш дәвере шагыйре, фикер иясе һәм дәүләт эшлеклесе. ***“Галишәр”*** тәхәллүсе аңа сарайда вәзир хезмәтен башкарганы өчен бирелә, ул *“бөек арыслан”* дигәнне аңлата.

Низаметдин Мир тимуридлар хөкүмәте чиновнигы Гыясетдин гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе генә түгел, агалары - шагыйрь Әбу Сәид, музыкант һәм каллиграф Мөхәммәд Гали дә үз чорының танылган кешеләре була. Мешхед, Герат һәм Сәмарканд мәдрәсәләрендә укый, Гератта дөньяви белем алу бәхетенә ирешә. Биредә музыка, сәнгать, тарих белән кызыксына, каллиграфия серләрен өйрәнә, иҗатка тартыла, әсәрләрен иске үзбәк-чыгытай телендә яза, үз теленең матурлыгына, байлыгына сокланып, аны дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү хыялы белән яна, гомере буе шуңа омтылып яши. Шунлыктан үзбәк телендә язылган әсәрләрен ***“Нәвои”*** – аһәңле тәхәллүсе белән, ә фарсы телендәгеләрен ***“Фани”*** имзасы белән тарата.

Герат мәдрәсәсендә бергә укыган иптәше Хөсәен Бәйкара Хөрәсән дәүләте белән идарә итә башлагач, Нәвоине үз сараена эшкә ала, әмир дәрәҗәсенә күтәрә. Хөсәен үзе дә - иҗат кешесе, әдәбият һәм сәнгатькә

хөрмәт белән караучы, шунлыктан каләмдәшләрен беркайчан да игътибарыннан читтә калдырмаган.

Нәвои Габдрахман Җәминең шәкерте булып, киләчәктә аның фикердәшенә, дустына әйләнә. Суфыйчылык тәгълиматын өйрәнеп, шул кыйблага тугрылык саклап, белемнәрен яшь буынга да тарату максатыннан, мәдрәсәләрдә дәресләр дә алып бара. Ул да укытучысы кебек үк халык мәнфәгатьләрен кайгыртып яши, бар байлыгын шәһәрне төзекләндерүгә, юллар, мәктәпләр, китапханәләр, шифаханәләр салдыруга, сәнгать һәм фән өлкәсендә хезмәт куючыларга тота. Ул сарайда хезмәттә булганда әдәби түгәрәкләргә җитәкчелек итәргә дә вакыт тапкан.

Нәвоинең шагыйрьлек таланты бик иртә ачыла, 15 яшендә инде фарсы һәм төрки телләрдә шигырьләр язучы оста каләм иясе буларак таныла. Ул - бик үткен телле, тәнкыйди рухлы иҗатчы. Үзенең әсәрләрендә ач күзле хөкүмәт вәкилләрен кискен тәнкыйть итә, аларның ришвәт алуларын, халык җилкәсендә яшәүләрен фаш итә, гади халык мәнфәгатьләрен беренчел куя. Шуңа күрә Сарайда да тора-бара аңа мөнәсәбәт үзгәрә, бөтенләй зур каршылыкларга кермәсәләр дә, аны Астрабад өлкәсенә идарәче итеп куялар, мәркәздән читтәрәк тотарга тырышалар. Ләкин Нәвои анда озак идарә итми, хөкүмәт эшләреннән баш тартып, кире Гератка кайта һәм үзен иҗатка, фән эшләренә багышлый.

Әдипнең иҗаты зур һәм күпкырлы: 30 лап күләмле әсәрләре- поэма, төрле диваннары, 3000нән артык газәлләре һәм башка тезмә әсәрләре билгеле. Нәвои мөселман Көнчыгышы халыкларының бай традицияләрен дәвам итеп, үз әдәби дөньясын тудыруга ирешә.

1498-1499 елларда “Фикер хәзинәсе” дип аталган шигъри җыентык тәкъдим итә, ул хронологик принципка корылган, гомеренең төрле чорларын эзлекле яктырткан “Балачак могҗизалары”, “Яшьлек зирәклеге”, “Гомер уртасының гаҗәеп җимешләре”, “Картлыкның файдалы киңәшләре” дип аталган 4 диваннан гыйбарәт. Аларда газәлләр, касыйдәләр, кыйтга, робагый һәм башка жанрлардагы әсәрләре тупланган.

Нәваи иҗатының кульминацион ноктасы - аның “Бишлеге” – “Хәмсә”се. Ул Низами һәм укытучысы Җәми юлын дәвам итә, аларга таянып яза. Нәвои “Бишлеге” түбәндәге әсәрләрне берләштерә:

1. “Изге кешеләрнең хәйранлыклары”
2. “Ләйлә вә Мәҗнүн” поэмасы
3. “Фәрхад вә Ширин” поэмасы
4. “Җиде планета” поэмасы
5. “Искәндәр стенасы”

**“Изге кешеләрнең хәйранлыклары” (1483)** – дидактик-фәлсәфи характердагы 64 бүлектән торучы поэма. Ул - Низаминың “Серләр хәзинәсе” нигезендә язылган, гаделлек идеалларына дан җырлаучы әсәр. Дин, әдәп, әхлак мәсьәләләрен күтәргән 20 хикәятне үз эченә ала. Нәвои үзенең әңгәмәләрендә феодалларны, халыкны изгән бәкләрне, икейөзле, сатлыкҗан шәех һәм казыйларны көчле тәнкыйть утына тота. Бу әсәре шагыйрьнең этик һәм эстетик карашларын, шул чор вәзгыятен һәм әдипнең аңа мөнәсәбәтен яхшы чагылдыра.

**“Ләйлә вә Мәҗнүн” (1484)** поэмасы традицион сюжетка корылса да, Нәвоидә аның сюжет төсмерләре шактый аерыла. Биредә Ләйлә гади бәдәви кызы түгел, ә мәдрәсә мөгаллименең бердәнбер яраткан баласы итеп бирелә. Бер-берсенә үлеп гашыйк ике җанны дөньявилыкта бергә булудан мәхрүм итәләр. Артык нечкә күңелле, хисчән, ярату көче тәэсирендә шагыйрьгә әйләнгән Кайсны Ләйләнең әтисе үз кызына тиң санамый. “Аңа җеннәр иялэшкән, ул бит җүләр, акылга зәгыйфь” диеп, егетне “Мәҗнүн” дип йөртә башлыйлар. Ләйләне бай феодал Ибн Сәламгә ярәшәләр, ләкин кыз бу хәлдән кайгырып, авыруга сабыша, туй шуңа күрә кичектерелеп тора. Әтисе кызының хәлен яхшырту өчен ни генә эшләми, төрле мәҗлесләр җыя, аларның берсендә Кайс та катнаша, ләкин сөйгәнен күрүгә, һушыннан язып егыла, егетнең бу гамәлен янәдән кыз нәселен мыскыллау итеп кенә кабул итәләр. Кайс, төшенкелеккә бирелеп, чүлгә китә, гомерен тугрылыклы эт белән үткәрә. Кыргый җәнлекләр аулаучы Нәүфәл аны үз канаты астына ала,

Ләйлә белән кавыштыру юлындагы эш-гамәлләре нәтиҗә бирми. Нәвои әсәрендәге Мәҗнүн, әти-әнисенең, туганнарының үгетенә ризалашып, Нәүфәлнең кызына өйләнә, ләкин тормышлары тоташ газапка гына әйләнә. Бу газаптан аларны үлем генә коткара. Поэма ахырында Ләйлә белән Мәҗнүн җаннары бергә кушылып, якты дөньядан китәләр.

Нәвои поэмасы – эмоциональ фоны, җир тормышына якынайтылган булуы белән дә аерылып тора. Ләйлә биредә үз бәхете өчен көрәшә алырлык хатын-кыз итеп сурәтләнелә. Поэма кабиләара низагларга, искергән традицияләргә, хатын-кызның тормыштагы тигезсез халәтенә протест буларак яңгырый. Әсәр саф мәхәббәткә, илаһи сөюгә дан җырлый.

**“Фәрһад вә Ширин” (1484)** – шулай ук әфлатун мәхәббәте темасына багышланган әсәр. Бу поэма Низами тәэсирендә язылса да, бөтенләй оригиналь яңгырашка ия. Иң зур аерма – Фәрһад образы белән бәйле. Ул Нәвои әсәрендә - Кытай хаканы улы, ә гади эшче, ташчы егет түгел. Шулай да ул искиткеч тәрбияле, патша малайларына хас булмаганча гади, кешелекле, иң матур сыйфатларны гына үзендә туплаган образ. Әсәрнең исеменнән үк аңлашылганча, бу поэмада аңа урын үзәктән бирелә. Ул тумыштан ук гыйлемгә гашыйк, балачактан ук бөтен фәннәрне дә үзләштерә, аның белән гыйлемлелектә кем дә ярыша алмый, хәтта Аристотель дә аның шәкерте генә. Корьәнне яттан белә, Сократ – аның иң якын дусты. Фәрһад кечкенәдән төзелеш, рәсем сәнгате белән кызыксынып үсә, этисе аның өчен салдырган сарайларны төзүдә ул үзе дә катнаша, киләчәктә зур архитектор дәрәҗәсенә ирешә.

Фәрһад – мәңгелек мәхәббәт авыруына дучар була, ул Ширинне сөюеннән һәм аның җавапсызлыгыннан чиргә сабыша. Нәвои фикеренчә, “Фәрһад” исеменең һәр хәрефе уңышсыз мәхәббәтне аңлата: ф- аерылышу, а – аһ-зар, р – авыр газаплар, көнләшү, һ – дөньядан ваз кичү, д – кайгы-хәсрәт агуы. Егет үзен мәхәббәте хакына корбан итә. Әсәр шулай ук җан мәхәббәтен зурлауга корылган.

Нәвои фикеренчә, мәхәббәт дини, милли тыюларны, чикләүләрне белми. Поэмада гомумән халыклар дуслыгы мәсьәләсе дә күтәрелә, Фәрһад, Шапур образлары аша толерантлык проблемаларын да хәл итә. Җирдәге бәхетле тормыш өчен милләтара, динара ызгыш-тартышларның булмавы мөһимлегенә басым ясала.

Поэма сюжет- композиция ягыннан шактый катлаулы. Анда Низаминың төрле поэмаларыннан сюжет элементлары кертелгән. Әсәрнең башында һәм азагында үзенә юл күрсәтүче әдипләр – Низамины, Әмир Хөсрәү Дәһләвине, Җәмине искә алып, аларга хөрмәтен күрсәтә.

Низамидан аермалы буларак, Нәвои үз поэмасына бик күп фантастик, маҗаралы эпизодлар, фольклор мотивлары, героик сугыш картиналары кертеп җибәрә. Әсәр гыйлем, сәнгать, хезмәт һәм мәхәббәткә югары бәя бирә. Болар – яңарыш әдәбияты билгеләре. Шул ук вакытта Нәвои кешене олылый, һәм кешене теләсә нинди югарылыкларга күтәрә алучы ике зур төшенчәне аерып куя – хезмәт һәм мәхәббәт. Аларның икесенең дә кешене тәрбияләвен, зур эшләргә рухландыруын, зур үрләргә алып менүен әсәр нигезендә раслый.

**“Җиде планета” (1484) –** Низаминың “Җиде гүзәл” әсәренә аваздаш. Шулай ук поэма үзәгендә – Бәһрәмгүр образы бирелә. Сюжетта аерымлыклар шактый күзәтелә, бу әсәрдә сатирик элементлар күп кулланыла.

Иран шаһы Бәһрәмгүр һәм аның сөяркәсе җырчы, музыкант Диларәм арасындагы мәхәббәт тарихы җиде төрле хикәят белән үрелеп бирелә. Бәйрәми тормыш, ауларга йөрергә яратучы шаһ үзе белән һәрвакыт Диларәмне дә ала торган була. Горур табигатьле чибәр кыз бер очрашулары вакытында сөйгәненә илтифатсызлык күрсәтә, мондый мөнәсәбәт белән беренче тапкыр очрашкан ир, ачуыннан, кызны бәйләп, чүлдә калдырып китә. Өйгә кайткач та җанына урын таба алмый, акылына килеп, сөеклесен эзләтә башлый, ләкин Диларәмне таба алмыйлар. Бәһрәм моңа бик кайгыра, үзенә урында, ямь таба алмый, авыруга сабыша. Шаһның ничек тә кәефен күтәрү өчен җиде төстә, җиде планетаны хәтерләтүче җиде сарай

салдыралар. Көн саен бер мосафир китертеп, аңа хикәятләр сөйләтәләр. Кайгысыннан чирләгән Бәһрәмне шу рәвешле дәвалау юлына басалар. Әсәрдә эгоистик рухлы геройның мәхәббәт газабы нәтиҗәсендә миһербанлы, кешелекле, кайгыртучан кешегә әйләнү процессы бирелә. Шулай да үз теләк-омтылышларын авызлыклый алмаган, үз рәхәте өчен күп канкоюлар оештырып, шуннан ләззәт тапкан шаһ ау вакытында һәлак була. Әсәр шундый финалга ия.

Мосафирлар сөйләгән хикәятләрдә Нәвоинең гадел җәмгыять, җирдәге бәхетле тормыш хакындагы идеаллары, кешелеклелек принцибына корылган уй-хыяллары чагылыш таба. Әлеге әсәре белән ул Хөрәсән дәүләте җитәкчеләрен, тимуридларны тәнкыйть итә. Халык мәнфәгатьләрен кайгыртырга, яшәешнең һәр мизгелен башкалар бәхете өчен сарыф итәргә, кешеләрне ярату аша бәхеткә омтылырга чакыра.

**“Искәндәр стенасы” (1485) –** иҗтимагый, фәлсәфи характердагы гуманистик әсәр. Төп герое – Александр Македонский. Әсәр Искәндәр белән Арастуның (Аристотель) диалогына корылган, ул поэмада шаһның киңәшчесе һәм уң кулы итеп бирелә. Шушы образлар аркылы Нәвои яшәү мәгънәсе һәм янәдән идарәчелек проблемасын күтәрә. Идарә, хакимлек һәм аларның кеше тормышына тәэсире “Хәмсә”дәге барлык поэмаларда да диярлек игътибарга алына. “Җиде планета”да мәхәббәт һәм хакимлек – яраша алмаслык көчләр итеп бирелсә, соңгысында хакимлекнең кеше шәхесенә, аның характеры эволюциясенә тәэсире күзәтелә. Нәвои Искәндәр мисалында хакимлекнең кеше шәхесенә җимергеч, кире тәэсирен раслый. Яшьлегендә аң-белемгә омтылган, фән биеклекләренә ирешергә хыялланган өметле егет үзенең бөтен талантын, зирәклеген канкоюлы сугышларга исраф итә, тормышын шуннан башка күзалдына да китерә алмый башлый. Бик күп сәяхәт итә, бик күп җирләрне басып ала, биләмәләрен арттыра, басып алган халыкларның да яшәешен кайгырта. Мәгъриб халкын яклап, яэҗүҗ-мәэҗүҗ кабиләләре белән көрәшә, аларны саклар өчен стена төзи, бу исә – символик мәгънәгә ия.

Гомер ахырында Искәндәр байлык һәм хакимлекнең вакытлы гына, ә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелекнең, рухи байлыкның мәңгелек булуына инана. Әнисенә язган хатыннан аның шундый тормыш алып баруына үкенүе аңлашыла. Нәвои бу әсәре белән тагын бер кат халык бәхете өчен яшәү генә, эшләгән, кылган изге гамәлләр генә кешене үлемсез итә дигән фикеренә басым ясый. Идарәчеләрне, гомумән һәр кешене бер көнлек ләззәт, кыска вакытлы шатлык, байлык артыннан артыннан кумыйча, үзеңнән соң исемең калырлык гамәлләр кылырга чакыра.

“Хәмсә”сеннән тыш, Нәвонең **“Кырык хәдис”** дип аталган, Мөхәммәт пәйгамбәр хәдисләренә таянып, алардагы тема-проблемаларны күтәреп язган хезмәте дә билгеле. Ул, нигездә, Г.Җәминең шул ук исемдәге фарсы телендә иҗат иткән әсәрләренең төрки телдәге әдәби эшкәртмәсе. Янәдән, фарсы телендә язылган “Диван Фани” дигән лирик шигырьләр, “Алты зарурият”, “Дүрт фасыл” исемле касыйдәләр җыентыгы бар. Шулай ук әдәбият тарихы, нәзарияе юнәлешендә дә хезмәтләр калдырган.

**Түбәндәге сорауларга җавап бирегез:**

1. Фөзули иҗатының асыл сыйфатларын атагыз?
2. Фөзули газәлләренең үзенчәлеге нәрсәдә?
3. Шикаятнамә нинди жанр?
4. Нәвои иҗатына кыскача сыйфатлама бирегез.
5. Нәвои һәм сәясәт, Нәвои һәм әдәбият тәңгәллекләре үткәреп, фикерләрегез белән уртаклашыгыз.
6. Нәвои “Хәмсәсе”нең төп идеясен ачыклагыз.
7. Фәрһад образының эшләнешендәге аермалыкларны билгеләгез.

**Курсның төп төшенчәләрен туплаган глоссарий**

**Азадә –** фарсы әдибе Әбелкасыйм Фирдәүсинең “Шаһнамә” эпопеясындагы иран шаһы, ау остасы Бәһрәм Гүрнең сөеклесе. Бәһрәм Гүр- Азадә сюжеты Шәрык дөньясында бик популяр була. Әдәби әсәрләрдә генә түгел, рәсем һәм сынлы сәнгатьтә дә еш очрый, савыт-сабаларга, келәмнәргә аларның рәсемнәрен бик яратып төшергәннәр.

**Антропоцентризм**– үзәккә кешене кую, кешене олылау дигәнне аңлата. Ренессанс әдәбиятының үзәгенә һәрвакыт Кеше куела. Кешенең акылына, хисләренә мәдхия укыла. Кеше Аллаһ белән бер дәрәҗәгә күтәрелә.

**Ахриман** – “Шаһнамә” эпопеясыннан – начарлык Алласы.

**Ахурамазда -** “Шаһнамә” эпопеясыннан –яхшылык Алласы.

**Афак –** Низами Ганҗәвигә бүләк ителгән кол кыз, соңыннан Низаминың сөекле хатыны, аның күп әсәрләренең прототибы.

**Әбу-Нәүвас (762-813)** – чыгышы белән фарсы, гарәп телендә иҗат иткән габбасыйлар чоры шагыйре, һәр яклап яңалык тарафдары. Әсәрләренең иң күбесе – күңел ачуларга һәм шәрабка багышланган. Тардият- аучылык жанрына нигез салучы, көчле сатирик. Гомеренең көзендә Аллаһка якыная, гөнаһларын таный, ярлыкау сорый, шул рәвешле зөһдият жанрына да мөрәҗәгать итә.

**“Әйям әл-гарәб” -** бәдәви кабиләләр көнкүрешеннән алынган вакыйгалар турында тарихи хикәятләр тупламы.

**Әл-Әхвәс-** Өммәвиләр чоры шәһәр лирикасы вәкиле. Төп жанры- газәл. Үзәктә - гашыйкларның мәхәббәт кичерешләре, газаплары, ләззәтләре. Аның мәгъшукалары арасында бик күп коллар да була. Шулай да аның аларга хисләре саф һәм чиста, эчкерсез сөюе белән башкалардан аерылып тора.

**Әл-Әхтәл** (640-710)- таглиб кабиләсеннән, христиан дине вәкиле. Өммәвиләр чоры сарай шагыйре, ягъни “сәяси көрәш поэзиясе” тарафдары. Ул бик күп яуларда сугыша, трибун дәрәҗәсенә күтәрелә, шуның өчен аңа халифә “өммәвиләр шагыйре” дигән титул бирә. Мәдхиядән тыш, сатира һәм хәмрия жанрларында яза. Хәмер – аның тормышында зур урын алып тора,

әгәр аерым касыйдәләр дә язса, аны “шәраб җырчысы” дип тә атарга мөмкин булыр иде.

**әл-Вәлид ибн Язид-** Өммәвиләр чоры шәһәр лирикасы вәкиле, халифә (733-743). Төп темасы – кешенең эчке дөньясы. Ул аны күңел ачу вакытында да, кайгы-хәсрәттә дә сурәтли. Аның шигырьләре җиңел, хисчән, чын күңелдән язылган. Аны “оятсыз шагыйрь”ләрнең юлбашчысы дип тә атыйлар. Ул өммәвиләр һәм габбасыйлар поэзиясен бәйләп торучы шагыйрь.

**“Әл-Мөгаллакат”- (нәзакәтле, шедевр мәгънәсен аңлата)** җаһилият чорының иң камил саналган, энҗегә тиң җиде касыйдәсен беләштергән антология. Авторлары- исламгача чорның танылган бәдәви шагыйрьләре- Имрелкайс, Гантара, Ләбид, Зөхәйр, Тарафа, әл-Харис ибн Хиллиз, Амр ибн Кульсум. “Әл-Мөгалләкат”ны – төзүче Хаммад – әр-Равийә.

**Әл-Мөхәлхил** – Адий ибн Рабига. Җаһилият чорының күренекле шагыйрьләренең берсе, таглиб кабиләсеннән. Шагыйрьләр патшасы – Имрелкайсның абыйсы. Аның исеме гарәп дөньясында популяр, тарихи фактка нигезләнгән “Басуса дөясе өчен сугыш” әсәре белән бәйле.

**Әр-Рәшид** - габбасыйлар халифәсе (763-809), “Мең дә бер кичә” әкиятләренең төп һәм уңай геройларының берсе.

**Әт-тәүхид фәлсәфәсе –** Аллаһның барлыгын һәм берлеген танучы фәлсәфә.

**Әфлатун** – грек фәлсәфәчесе Платонның гарәпчә әйтелеше. Шәрык һәм төрки халыклар арасында шул әйтелеш таралыш алган.

**Әш-Шанфара** -– Сабит бин әл-Аус әл-Аздий. Җаһилият чорының күренекле сукбай шагыйрьләренең берсе. Фәхр, хамаса жанрында язылган күп кенә шигырьләр калдырган, 68 бәеттән торган “Ләмиятүл-араб” иселе касыйдә авторы.

**Багдад** – 755-1258 елларда габбасыйлар халифәтенең башкаласы, Урта гасырларда мәдәни, гыйльми мәркәз, дөнья кендеге саналган, “патшалар шәһәре” дип йөрткәннәр. Рәсми исеме – “Мадинат әс-Салам” - “Тынычлык шәһәре” дигәнне аңлата.

**Бәдәви** - Гарәбстан ярымутравының төньяк өлешендә яшәүче күчмә халык, бу урынчылыктагы чүлне - бадия (чүл), ә анда яшәүчеләрне әһле бәдәви (чүл кешеләре) дип атаганнар. Бәдәвиләр – кыю, кырыс, сугышчан холыклы, үз сүзләрендә нык торучан, горур табигатьле кешеләр. Төп таянычы- кылыч. Алар бик кунакчыл, үзләре турында мактау сүзе ишетергә яраталар, яхшы фикер калдырырга тырышалар. Иптәшенә бик ярдәмчел, аннан да шуны таләп итә. Качакларга, мосафирларга якты чырай күрсәтәләр, сыйлыйлар, кунарга калдыралар. Ярдәм сорап килгән кешенең үтенечен үтәр өчен хәтта сугышка да күтәрелергә мөмкин. Дошманыннан һәрвакыт үч ала, беркайчан да гафу итми.

**Бәдәвиләр лирикасы** –икенче төрле гозрәитләр лирикасы – өммәвиләр чорында саф мәхәббәткә баш июче, “мәхәббәт- сагыш, кайгы һәм ул котылгысыз” дигән карашны алга сөрүче, илаһи мәхәббәт тарафдарлары. Бәдәви лирикасының күренекле вәкилләре: Җәмил ибн Магамар, Ләйлә әл-Әхъялийә, әл-Мәҗнүн әл-Әмири, Кайс ибн Зарих һ.б.

**Бәлх** – Хөрәсән дәүләте шәһәре, Бактриянең (хәзерге таҗик һәм пушун халыкларының бабалары яшәгән борынгы дәүләт, территориясе хәзерге Үзбәкстан, Таҗикстан һәм Әфганстан җирләре бергә очрашкан урынны тәшкил итә) борынгы башкаласы.

**Бәһрәм** – сасанидлар династиясенең легендар шаһы, ау остасы , коланнар (онагра – партояклы булмаган ат төре) аулау белән мавыкканлыктан Бәһрәм Гүр дигән тәхәллүс бирелә (Гүр – коланның фарсыча әйтелеше). Шәрык Дон-Жуаны булып танылган бу шәхес сөеклесе Азадә (Диларәм, Фетнә) белән бик күп әсәрләрнең сюжет тукымасына кертелгән. Әдәби әсәрләрдә генә түгел, рәсем һәм сынлы сәнгатьтә дә еш очрый, савыт-сабаларга, келәмнәргә аларның рәсемнәрен бик яратып төшергәннәр. Шулай ук Бәһрәмне беренче робагый авторы дип санаучылар да бар.

**Бәһария** – язгы чәчәкләрне мактауны максат иткән, касыйдәнең бер жанр формасы. Шәрыкта аны “яз җыры” дип тә йөрткәннәр.

**Васыф** – касыйдәнең лирик башламнан соңгы тасвир өлеше, икенче төрле әйткәндә, пейзаж лирикасы.

**Габбасыйлар** – өммәвиләрдән соң хакимияткә килеп, биш гасырдан артык (750—1258 еллар ) халифәлек иткән гарәп халифәләре династиясе. Беренче халифә - Габдулла ибн Мөхәммәд әс-Сәффах, соңгысы – әл-Мөстасим 1258 елда монголлар тарафыннан үтерелә.

**Газәл-** гарәп шигъриятендә дөньяга килгән, фарсы, төрки әдипләре тарафыннан яратып кулланылган, 12 бәеттән артмаган поэтик форма, төп юнәлеше – лирик нигезле мәхәббәт җырлары, еллар узган саен иҗтимагый-фәлсәфи эчтәлекле газәлләр ешрак очрый.

**Гали** (Гали ибн Абу Талиб) – сөнниләрнең дүрт "тугрылыклы халифә"ләренең берсе (656-661 елларда идарә иткән). Мөхәммәд пәйгамбәрнең кияве, шигыйлар Галине Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң мөселманнар белән идарә итү өчен күктән иңдерелгән дип саныйлар, изгеләштерәләр.

**Гантара** - Антара ибн Шаддад ибн Амр ибн Мугавия әл-Әбси, 525- 615) әбсит кабиләсеннән, исламгача чорның танылган шагыйрьләренең берсе, "мөгалләка" авторы.

**Гасабийя** - үз кабиләңә нык бирелгәнлек, тугрылык.

**Гаттар** (Шәйх Фәрид әд-дин Гаттар) - чын исеме Әбу Хәмид Мөхәммәд ибн Әбу Бәкр Ибраһим (1150 - 1230) – фарсы суфый шагыйре һәм фәлсәфәчесе, күпсанлы поэмалар һәм шигырьләр авторы. "Кошлар әңгәмәсе", "Киңәш китабы", "Изгеләр тормышы" кебек китаплары Шәрыкта бик популяр була. Аның үзәккә - илаһияткә омтылыш куелган әсәрләре тирән фәлсәфи фикерләр белән сугарылган.

**Гозрә** – Вамыкның мәгъшукасы, матурлык һәм мәхәббәт символы. "Гозрәидләр лирикасы" аның исеме белән бәйле.

**"Гөлестан"** (гюлистан) – гөлләр бакчасы. С.Ширази әсәре.

**Гомәр ибн әбу Рабига –** көрәеш кабиләсеннән, Ямән хакименең улы. Өммәвиләр чоры шәһәр лирикасы - ирекле эчтәлекле, төрле мәҗлесләрне,

эротик күңел ачуларны натуралистик планда тасвирлаган әдәбият вәкиле. Тормыш, яшәеш мәгънәсен бары матурлыкта һәм күңел ачуларда гына күргән, күзенә матур күренгән бер генә хатын-кызга да гашыйк булмыйча һәм шигырь язмый калмаган.

**Гуманизм** – кешелеклелек дигәнне аңлата. Гуманистик әдәбият кеше кыйммәте, кешелекле мөнәсәбәт мәсьәләләрен үзәккә куя. Кешегә карата кешелекле мөнәсәбәт, кешенең төрле яклап үсешен, шәхес ирегeн, кеше бәхетен, кеше кадерен иң югары кыйммәт итеп караучы тәгълимат. Шәрык ренессанс әдәбияты гуманистик принципларга корылган.

**Дини-әхлакый әдәбият** - Коръән фәлсәфәсенә нигезләнгән, Аллаһның барлыгын һәм берлеген танырга өйрәтүче, Аллаһка сәҗдә кылуны, кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, әдәп-әхлак, миһербанлыкка, шәфкатьлелеккә, гаделлеккә һәм башка изгелекләргә өндәүче әдәбият.

**Дәрвиш** (фарсыча - “ярлы” д.аңлата)– заһид, суфый.

**Җаһилият чоры-** (җаһил – надан д. сүз, ягъни наданлык чоры). Гарәп дөньясындагы исламга кадәрге чорны – җаһилият чоры дип атау гадәткә кергән.

**Җәми** – Мәүлана Нуретдин Габдрахман ибн Әхмәд (1414-1492) – фарсы яңарыш әдәбиятының ишекләрен ябучы атаклы шагыйрь һәм суфыйчылык әдәбиятының теоретигы, Нәвоинең рухи остазы.

**Җәмил ибн Магамар -** өммәвиләр чоры бәдәви лирикасының күренекле вәкиле, хатын-кыз матурлыгын тасвирлаган нәсибләре аны дөньяга таныта, илаһи мәхәббәт тарафдары.

**Җәмшид** – легендар шаһ, иран мифологиясенең танылган геройларыннан берсе, ул халыкны металл эшкәртергә, тукымалар ясарга, йортлар төзергә өйрәткән. Җәмшид идарә иткән 700 елда халык бик рәхәт һәм муллыкта яшәгән, хәтта үлемсезлек хөкем сөргән.

**Җәрир (653-733) -** Өммәвиләр чоры сарай шагыйре, ягъни “сәяси көрәш поэзиясе” тарафдары. Ул - үз кабиләсенең патриоты, өммәвиләрне, аларның туганнарын, дусларын мактый. Мәрсияләре арасында сарай кешеләренә

багышланганнары да, үз туганнарына, якыннарына юлланганнары да бар. Җәрирнең бөтен сатирасының угы Фараздакка юнәлгән. Чөнки бу ике шагыйрь – кан дошманнар. Башкаларны хурлаганда, үзен мактап, дошманнарын тагын да кимсетә.

**Җиһангир** – дөньяны яулап алучы, баскынчы.

**Заххак** – Фирдәүсинең "Шаһнамә" поэмасыннан, иран шаһы Җәмшитне тәхеттән төшергән мифик идарәче, Иблиснең хезмәтчесе, Заххакның җилкәсеннән үсеп чыккан тынгысыз еланнар яшь егетләрнең мие белән туклана. Мең еллап идарә иткәннән соң бу елан патшаны бастыралар.

**Зәрдәштилек** - зароостризм – Авеста- ягъни утка табынучылар дине, фарсылар исламга кадәр шул динне тотканнар.

**Зөһдият** – фәлсәфи характердагы аскетлыкны алга сөрүче юнәлеш.

**Имрелкайс –** "шагыйрьләр атасы", исламгача чорның танылган бәдәви шагыйрьләренең берсе, "мөгалләка" авторы.

**Искәндәр** – Александр Македонский.

**Кааб ибн Зөһәйр** - ислам таралган чорның танылган, шөһрәтле шагыйре. Исламны тәнкыйть итеп, борынгы бабалары диненә кайтырга чакыручы юнәлеш тарафдары. Ислам динен, Мөхәммәд пәйгамбәр тәгълиматын аның белән көрәштә җиңелгәннән соң гына кабул итә. Соңыннан ислам дине, Мөхәммәд пәйгамбәр мәнфәгатьләрен кайгырта, иҗаты белән дингә хезмәт итә.

**Касыйдә-** мактауга һәм тасвирга корылган гарәп әдәбиятындагы иң борынгы һәм композициясе ягыннан иң катлаулы поэтик форма. Касыйдәләр бер-берсе белән аз бәйләнештә торган берничә структур кисәктән, өлештән тора. Касыйдәнең аерым өлешләре бары жанр формалары гына булып торалар, бары Урта гасырларда гына мөстәкыйльлек алалар. Касыйдә нигезен бәетләр (икеюллыклар) тәшкил иткән. Аларның рифмалары а а, б а, в а... принцибы буенча төзелгән. Касыйдәләр, классик шигырь формасы буларак, гаруз вәзеннәренең берсенә нигезләнеп язылганнар.

**Каюмарс** – легендар иран тарихындагы беренче идарәче, кешеләргә цивилизация бүләк иткән шәхес.

**Ләйлә әл-Әхъялийә** - өммәвиләр чоры бәдәви лирикасының күренекле вәкиле, илаһи мәхәббәт җырчысы. Иң яхшы әсәрләре сөйгәне Тәүбәгә багышланган. Ул әл-Хәнсәдән кала гарәп әдәбиятында иң көчле шагыйрә санала.

**Мачин** – көньяк Кытай.

**Мәгърифәт** - суфыйчылыкның өченче баскычы, Аллаһны акыл белән түгел, ә йөрәк белән танып-белүне, интуиция ярдәмендә тоюны аңлата. Бу халәтне, башкаларга аңлашылмаган бу серле гыйлемне Хак Тәгалә сөекле кешеләренә үзе җибәрә.

**Мәдхия** – панегирик жанр, гарәп касыйдәсенең төп жанр формасы. Мәдхия күп вакыт кабилә башлыкларына, идарәчеләргә, әмирләргә багышлана. Гарәп әдәбиятында беренче мәдхия җаһилият чорының сукбай шагыйре Тааббата Шарран иҗатында күренә. “Мөгалләка”лар да үзләрендә шактый гына мәдхияләр саклаганнар. Урта гасырларда мөстәкыйль жанр булып яши башлый.

**Мәйханә**- шәраб, исерткеч эчемлекләр сатыла торган урын.

**Мәүлана** - “әфәнде ”. Зур дәрәҗәләргә ирешкән галим- голяма, шагыйрьләр, казыйлар, руханилар, суфыйчылык җитәкчеләренең исемнәре алдыннан әйтелә торган шәрәфле исем

**Мөрид** – суфыйчылыкның тәрикать юлына баскан, остазының сүзеннән чыкмаска, аның юлын дәвам итәргә сүз биргән мөршиднең укучысы.

**Мөршид** – рухи остаз, суфыйларның җитәкчеләре.

**Нәвои**- Мир Низаметдин Гыясетдин Алишер Нәвои (1441-1501)- үзбәк яңарыш дәвере шагыйре, фикер иясе һәм дәүләт эшлеклесе. Ул - бик үткен телле, тәнкыйди рухлы иҗатчы. Үзенең әсәрләрендә ач күзле хөкүмәт вәкилләрен кискен тәнкыйть итә, аларның ришвәт алуларын, халык җилкәсендә яшәүләрен фаш итә, гади халык мәнфәгатьләрен беренчел куя. Әдипнең иҗаты зур һәм күпкырлы: 30 лап күләмле әсәрләре- поэма, төрле

диваннары, 3000нән артык газәлләре һәм башка тезмә әсәрләре билгеле. Нәваи иҗатының кульминацион ноктасы - аның “Бишлеге” – “Хәмсә”се.

**Нәкаид** - өммәвиләр дәверендә аеруча популярлашкан сатирик рухлы касыйдәләр, нигездә, дошман кабиләләргә адреслана, ә каршы як, әсәрнең бөтен үлчәмнәрен саклаган хәлдә, җавап кайтарырга тиеш була.

**Нәкъшбәндия** – суфыйчылыкның Бохара шәехе Баһаветдин Нәкъшбәнди нигезләгән юнәлеше, төрки-татарлар шушы юнәлешкә карый, алар зөһедлек һәм тәкъвалыкны, дәрвишлекне, хәнакада яшәүне мәҗбүрият итеп куймыйлар. “Нәкъшбәндия” юнәлеше кешене гел изгелек кылуга тартуы белән аерылып тора, Мөхәммәд пәйгамбәр юлын дәвам итүчеләр санала. Алар гадел, кешелекле булырга, ярлыларга, фәкыйрьләргә ярдәм итәргә чакыралар, кешеләрне үз хезмәтләре белән көн күрергә чакыралар

**Нәсиб** - касыйдәнең лирик башлам өлеше.

**Нәүширван** – Хөсрәү I Ануширван (531-579) – “Гадел” кушаматы тагылган Сасанидлар династиясеннән булган иран шаһы, ул идарә иткән чорда салымнар кими, халык иркен яши. Риваятьләргә караганда, ул үзенең идеаль дәүләт турындагы фикерләрен тәхетенә чокып эшләткән була.

**Низами** – Әбу Мөхәммәд Ильяс ибн Йосыф ибн-Заки ибн-Муайад Низами Ганҗәви (1141-1209)- Шәрык, азәрбәйҗан әдәбиятының бөек шагыйре, фикер иясе, әсәрләрен фарсы телендә иҗат итә. Ул фарсы эпик поэзиясенә сөйләм телен һәм реалистик өслүб алып килгән, әдәби әсәр тудыруның яңа стандартларын эшләп биргән сүз остасы, һәрберсе тиңдәшсез саналган биш поэманы берләштергән “Хәмсә” авторы

**Өммәвиләр** - дүрт тургылыклы халифәдән соң 661 елда властька килгән династия, беренче халифәләре Могавия (661-680) - Сүрия наместнигы. Башкаланы Дәмәшкъка күчерәләр, барлыгы – 14 халифә идарә итә, соңгысы – Мәрван II (744-750), 750 елда Әбу Мөслим восстаниясе нәтиҗәсендә габбасыйлар тарафыннан тәхеттән бәреп төшереләләр.

**Равий** – нинди дә булса мәгълумат таратучы, телдән сөйләүче чичән кеше. Җаһилият чорының әдәби истәлекләре равийлар эшчәнлеге нәтиҗәсендә генә сакланып калган.

**Рәджәз -** гарәп шигыренең иң гади үлчәме, башка шигъри үлчәмнәргә нигез салучы.

**Ренессанс чоры -** иҗтимагый тормыш, мәдәният һәм әдәбиятның югары үсеш алган дәвере.

**Ринд –** (бродяга ) – сукбай.

**Рисә –** элегия, мәрсия һәм 50-100 бәетне үз эченә алган касыйдәләр, исламгача чор гарәп поэзиясенең төп композицион формасы.

**Рөстәм** – иран халкының җиңелмәс батыры, каһарманы, Фирдәүсинең "Шаһнамә" поэмасының баш геройларыннан берсе.

**Рәхш** – Рөстәмнең пәһлевандай аты.

**Рудакый-** Әбу Абдулла Җәгъфәр ибн Мөхәммәд ибн Хәким ибн Габдрахман ибн Адәм Рудакый Сәмәрканди (860-941)- фарсы яңарыш әдәбиятының нигез ташларын салучы, фарсы шигъриятенең солтаны, күренекле шагыйрь, җырчы һәм музыкант. Рудакый иҗатының төп кыйбласы - шәхеснең азатлыкка омтылышын яклау, мәхәббәт культына дан җырлау, кешене олылау.

**Сәгъди Ширази -** Әбу Мөхәммәд Мөслихетдин ибн Габдулла Сәгъди Ширази (1203/1210 – 1292) фәлсәфи-дидактик, фәлсәфи-лирик юнәлешне үз иткән күренекле лирик, фарсы яңарыш әдәбияты классигы, суфыйчылык әдәбияты вәкиле. Гаделлек идеалларын күтәргән "Гөлстан"һәм "Бостан" поэмалары, күпсанлы газәлләр авторы.

**Сәдҗ-** рифмалашкан проза, гарәп шигырь төзелешенең башлангыч формасы.

**Сәяси көрәш поэзиясе** – өммәвиләр чорындагы сарай мәдхиячеләре шигъърияте. Бу сарай җырчылары өммәвиләрне данга күмеп, аларның дошманнарын тәнкыйтьләп, алардан туктаусыз көлеп, әсәрләрен күпләп тәкъдим итеп торалар. Бу юнәлеш, максатыннан чыгып, "сәяси көрәш поэзиясе" дип тамгалана. Һәм ул юнәлешне Әл-Әхтәл, Фараздак һәм Җәрир исемле шагыйрьләр "өчлеге" тәэмин итә.

**Суфыйчылык әдәбияты** - Аллаһка мәхәббәт тәрбияләү, аңа якынаерга, ахыр чиктә аның белән бергә кушылырга омтылуны максат иткән, үзәгендә - илаһияткә омтылган камил кеше образы торган әдәбият.

**Тарафа** —Тарафа ибн әл-Габд ибн Суфьян ибн Мәлик әл-Бәкри – бәкер кабиләсеннән, VI йөз уртасында яшәгән күренекле шагыйрь, "мөгалләка" авторы.

**Тарикать –** суфыйчылыкның икенче баскычы, шәех, ишан- ягъни рухи остаз җитәкчелегендә Аллаһ юлына басуны аңлата, бу баскычтагы суфый мөрид дип исемләнә.

**Тардият** – аучылыкны гәүдәләндерүче шигърият.

**Тәэббата Шарран** - Сабит ибн Җабир. Җаһилият чорының күренекле сукбай шагыйрьләренең берсе. Горур сугышчы, мәдхияләр авторы. Үзен сурәтләү объекты белән һәрвакыт тигез куя һәм, беренче чиратта, аны кеше буларак түгел, ә үз кабиләсенең данлыклы көрәшчесе төсендә югары күтәрә.

**Туранлылар**- төрки кабиләләр.

**Фараздак (641-732)-** Өммәвиләр чоры сарай шагыйре, ягъни "сәяси көрәш поэзиясе" тарафдары. Шулай да Гыйрак хакимияте каршында бер дә хөрмәте булмый. Сәбәбе – усал теле һәм үзгәрүчән характеры. Өммәвиләр, хакимият кешеләре аннан гомумән куркып торганнар. Үзе булган һәр урында мәдхия һәм һөҗү язып, кемнедер сөендереп, кемнедер көенергә мәҗбүр итә. Фараздак фәхрия, мәдхия, мәрсия, һөҗү, васыф, газәл жанрларында иҗат итә. Ул һәрвакыт үз кабиләсе җырчысы булып кала, аннан читләшми, сәясәт белән дә кабиләсе мәнфәгатьләрен кайгырту өчен генә кызыксынган.

**Фәридун** – Җәмшит нәселеннән булган, тиңдәшсез байлыкка ия легендар иран шаһы. Фирдәүсинең "Шаһнамә" поэмасыннан.

**Фәрһад** –Низами, Нәвои әсәрләренең баш каһарманы, Ширинга гыйшык тотучы ташчы егет (Низамида), ә Нәвои әсәрендә ул – архитектор, кытай хаканы улы.

**Фәхр-** фәхрия , үз-үзеңне мактау, исламгача чор касыйдәсенең төп өлешен тәшкил итә.

**Фирдәүси** - Хәким Әбелкасыйм Мансур Хәсән Фирдәүси Туси- фарсы яңарыш әдәбиятының күренекле вәкиле, исламгача булган Иран тарихын яктырткан дөньякүләм яңгырашка ия “Шаһнамә” эпопеясының авторы.

**Фөзули –** мәүлана Мөхәммәт ибн Сөләйман Фөзули (1494-1558)- шагыйрь һәм фикер иясе, азәрбәйҗан яңарыш әдәбиятының соңгы вәкиле. Төп жанры – газәл. Ул аны әдәбиятның иң югары жанры дип саный. Бу жанрны иҗтимагый-фәлсәфи эчтәлек белән баета. Шулай да газәлләрендә мәхәббәт темасы әйдәп бара. Ләкин суфый шагыйрь буларак, ул күбрәк илаһи мәхәббәт турында яза. Азәрбәйҗан әдәбиятына шикаятнамә жанры алып килә.

**Хакани** - Әфзалетдин Хакани (1120-1199) – күренекле азәрбәйҗан әдибе, азәрбәйҗан ренессанс әдәбиятына нигез салучы.

**Хакыйкать** - суфыйчылыкның соңгы баскычы, Аллаһка якынаю, аның белән бергә кушылу. Һәр суфыйның төп һәм ахыр максаты шул.

**Хассан ибн Сабит** - ислам таралган чорның Дәмәшкътагы гассанидлар сарае шагыйре. Ул исламның хак юл икәнлегенә чын күңелдән ышанып, үз теләге белән динне кабул итә, пәйгамбәргә әсәрләре белән ярдәм итә, Мөхәммәд тә аны бик хөрмәт итә, шагыйрьнең үзен данга күмә.

**Хафиз Ширази** – Шәмсетдин Мөхәммәтхафиз (1325-1390) - фарсы яңарыш әдәбиятының көчле лирикларының берсе, газәл остасы. Бу жанр Хафиз иҗатында кульминацион ноктасына җитә. Аның газәлләрендә конкрет кеше мәхәббәте фәлсәфи югарылыкта бирелә. Үзенең әсәрләрендә Хафиз икейөзле дин әһелләреннән көлә, аларга каршы чыга. Хафиз хәмерне, тормыш матурлыгын, мәхәббәт һәм дуслыкны да зурлап җырлый. Аның иҗаты - үтә каршылыклы.

**Хәвәран** –көнчыгыш Иран

**Хәйям** - Ибраһим Гомәр Хәйям (1048–1123) – галим, философ, фарсы яңарышының күренекле шагыйре, робагыйлар остасы.

**Хәлия** – үз хәлеңне язу, язмышка зарлану, касыйдәнең жанр формасы.

**Хәмрият** – шәраб поэзиясе

**Хәмсә** – бишлек, биш поэманы берләштергән зур шигъри җыентык, беренче “Хәмсә” авторы – Низами, аның эшен дәвам итеп, җавап рәвешендә, һиндстанлы Әмир Хөсрәү Дәһләви (1253—1325), фарсы- таҗиклардан Габдрахман Җәми (1414—1492), үзбәкләрдән Алишер Нәвоиләр (1444—1501) үз “Хәмсә”ләрен тудыралар.

**Хәнака** (ханках) – суфый дәрвишләрнең гомуми торагы. Кайбер юнәлештәге суфыйларга анда яшәү мәҗбүри куелган.

**Хиджаз –** Гарәбстандагы Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләре урнашкан өлкә.

**Хөрәсән** – төньяк-көнчыгыш Иран.

**Хөсрәү**– Хөсрәү Пәрвиз (590-628) - сасанидлар династиясенә караган иран шаһы. Низами, Нәвои әсәрләрендәге Ширинга гашыйк булган баш каһарман.

**Һарун әр-Рәшид** - габбасыйлар халифәсе (763-809), “Мең дә бер кичә” әкиятләренең төп һәм уңай геройларының берсе.

**Чин** – төньяк Кытай.

**Шәригать -** суфыйчылыкның беренче адымы, аның нигезендә - гыйлем, гамәл һәм ышану ята. Бу баскычтагы суфый илаһият кануннарын, ислам һәм шәригать нормаларын өйрәнә.

**Шәрык ренессансы** - гарәп дөньясында бөек Коръән тәгълиматы белән туган, башка мөселман динле халыклар арасында иҗтимагый тормыш, мәдәният һәм әдәбиятның югары үсеш алган дәвере. Шәрык яңарыш әдәбияты Аллаһны да, кешене дә олылауга корылган, гуманистик мотивлар беренче планда тора.

**Шәһәр лирикасы** – өммәвиләр чорындагы утрак тормышлы гарәпләр лирикасы. Ирекле эчтәлекле, төрле мәҗлесләрне, эротик күңел ачуларны натуралистик планда тасвирлаган әдәбият. “Гомәридләр лирикасы” дип тә йөртәләр. Вәкилләре: Гомәр ибн әбу Рабига, Әл-Әхвәс, әл-Вәлид ибн Язид һ.б.

**Шигыйлар (**шииты**)** – ислам динендәге бер юнәлеш, аның тарафдарлары Галине (Гали әбу ибн Талиб, Мөхәммәд пәйгамбәрнең кызы Фатиманың ире, дүрт тугрылыклы халифәнең берсе) Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң

мөселманнар белән идарә итү өчен күктән иңдерелгән дип саныйлар, изгеләштерәләр. Шигыйлар, нигездә, Иран, Азәрбәйҗан, Бахрейн, Гыйрак һәм Ливан территориясендә яшәүче мөселман халыклары.

**Шикаятнамә –** зар- мәгънәсендә, әдәбиятка жанр буларак Фөзули алып килә.

**Шикия** – сөйгән ярны мактау, касыйдәнең жанр формасы.

**Ширин-** Низами, Нәвои әсәрләренең баш каһарманы, патшабикә.

**Шугубиячеләр** (шугубиты) – нигездә иранлылардан (фарсылар) торган, сәяси һәм мәдәни тигезлек өчен көрәшүчеләр, ислам дине кабул иткән халыкларның тигез хокуклы булуларын таләп итәләр, хәтта фарсыларның һәм гарәп булмаган башка халыкларның өстенлеген дәгъвалыйлар һәм бу юнәлешкә шугубия хәрәкәте дигән исем бирелә. Әдәбиятта бу юнәлешне алга сөрүчеләр булып Бәшшәр ибн Бурд һәм Әбу Нәүвас санала. Алга таба башка фарсы әдипләре тарафыннан үстерелә.

**Элеккеге традицияләрне торгызу өчен көрәшүче әдәбият-** гарәпләрнең элеккеге авторитар рольләрен кайтаруны таләп иткән консерватив, реакцион, үткәндәге традицияләргә кайтуга йөз тоткан юнәлеш, яңалык өчен көрәшүчеләрнең төп дошманнары. Күренекле вәкилләре: Әбу Тәммам, әл-Бухтури, әл-Җәһиз.һ.б.

**Яздигерд** (420 елда вафат) –Сасанидлар династиясеннән булган иран шаһы.

**Яңалык өчен көрәшүчеләр әдәбияты - г**аббасыйлар чорындагы әдәбиятта “яңа өслүб”тә язучы әдипләр дулкыны. Алар үзләрен яңалык өчен көрәшүчеләр дип атыйлар. Бәшшар ибн Бурд, Әбу Нәүвас, Әбу әл-Әтәхийә һ.б. шушы дулкынны тәшкил итүчеләрнең иң танылганнары.

## Курска кагылышлы гомуми информацион ресурслар

### Төп әдәбият


1. Авхадиева А.И. Арабская литература джахилийского (доисламского) периода: Учебное пособие. – Казань, 2001. – 36 с.
2. аль-Фахури Х. История арабской литературы [пер. с араб.]. В 2 томах. Т. 1. – М.: Изд-во иностранной литературы, 1959.
3. Андреева И.И. Древние и средневековые литературы народов СССР. - Ч.1.
4. Аравийская старина: Из древней арабской поэзии и прозы. – М.: Наука, 1974.
5. Бертельс Е.Э. Избранные труды. Суфизм и суфийская литература. - М.: Издательство "Наука", 1965. - 522 с.
6. Брагинский И.С. 12 миниатюр. От Рудаки до Джами. 2-ое изд., дополн. - М.: Худ.лит., 1976. - 302 с.
7. Восточная поэзия. - М.: Терра - Книжный клуб, 2002. - Т.1. - 511 с.; Т.2. - 511 с.
8. Ганиева Р.К. Литература Востока (классический период). Расширенная программа лекционного курса. – Казань, 2004.
9. Ганиева Р.К. Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. - Казань: Изд-во КГУ, 1988. - 173 с.
10. Гибб Х. Арабская литература. Классический период. – М.: Изд-во Восточной литературы, 1960.
11. Золотая поэзия Востока.- Симферополь: Реноме, Харьков: Свитовид, 2001.-368 с.
12. Кныш А.Д. Мусульманский мистицизм: краткая история. Пер. с англ. М.Г. Романов. – СПб.: Издательство «ДИЛЯ», 2004.
13. Куделин А.Б. Арабская литература: поэтика, стилистика, типология, взаимосвязи. – М., 2005.

14. Куделин А.Б. Средневековая арабская поэтика (вторая половина VIII-XI веков). – М.: Наука, 1983.
15. Мец А. Мусульманский Ренессанс. – М.: Наука, Восточная литература, 1973.
16. Очерки истории арабской культуры V-XV веков. – М.: Наука, 1988.
17. Рейснер М.Л. Литература Ближнего и Среднего Востока: учебно-методическая разработка. - Казань, 2003.
18. Таджикско-персидская поэзия X-XV вв. - Казань, 1990. - 184 с.
19. Фильштинский И.М. История арабской литературы. V- начало X века. – М.: Либроком, 2010.
20. Фильштинский И.М. Арабская литература в средние века: Словесное искусство арабов в древности и раннем Средневековье. – М.: Наука, 1977.
21. Хабибуллина А.З. Литература народов Востока в Средние века: учебно-методические материалы для студентов. – Казань: Казан. гос. ун-т, 2007. – 32 с.
22. Шидфар Б.Я. Абу-ль-Аля аль-Маарри. – М.: Наука, 1985.
23. Шидфар Б.Я. Абу Нувас. 2-е изд. – М.: Изд. дом Марджани, 2011.
24. Шидфар Б.Я. Образная система арабской классической литературы (VI-XII вв.). 2-е изд. – М.: Изд. дом Марджани, 2011.
25. Широян С. Г. Великий арабский поэт и мыслитель Абу-ль-Аля аль-Маарри. – М., 1957.

**Өстәмә әдәбият:**

1. Ганиева Р.К. Философско-эстетические основы тюркских литератур средневековья // Татарская литература: традиции, взаимосвязи.

2. Исламов Р.Ф. Урта гасыр төрки шигърияте үсешендә Шәрифнең "Шаһнамә"се. - Казан: Фикер, 2001. - 279 б.
3. Идрис Шах. Суфии. М.: «Локид-пресс», 2001. — 448 с.
4. Истории странствующих суфиев.- М..: ЭКСМО, 2004.- 400 с.
5. Куделин А.Б. Образ восхваляемого в средневековом арабском панегирике / Поэтика средневековых литератур Востока: традиция и творческая индивидуальность. – М.: Наследие, 2011.
6. Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и восточная классика. - Казань: Изд-во КГУ, 1993.- 364 с.
7. Миңнегулов Х. Ю. Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар.- К.: КДУ нәшр., 1988.- 198б.
8. Миннегулов Х. Ю. Записи разных лет (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи). Казань: Идел-Пресс, 2010. - 407 с.
9. Миннегулов Х. Ю. Татарская литература и восточная классика / Вопросы взаимосвязей и поэтики / Казань.: Изд-во КГУ, 1993. - 384с.
10. Монроу Дж.Т. Устный характер доисламской поэзии / Арабская средневековая культура и литература. М.: Наука, 1978. – С. 93-143.
11. Очерки истории арабской культуры V-XV веков. – М.: Наука, 1988.
12. Рахманалиев Р. Империя тюрков. Великая цивилизация. Мусульманский ренессанс и тюрки.
13. Рзакулизаде С. Понятие “Ренессанс” и проблема Восточного ренессанса // Закономерности развития восточной философии XIII – XVI вв. (регион ислама) и проблема Запад-Восток, 1983.
14. Сибгатуллина А.Т. Суфичылык серләре. - Казан: "Матбугат йорты" нәшр., 1998. - 368 б.
15. Сибгатуллина А.Т. Илаһи гашыйклар юлыннан (суфичылык турында очерклар). - Казан: "Кыйбла" нәшр., 1999. - 144 б.
16. Соловьев В. Арабская литература. Краткий очерк. – М.: Наука, 1964.

17.Фильштинский И.М. Арабская литература в средние века: Словесное искусство арабов в древности и раннем Средневековье. – М.: Наука, 1977.
18.Халидов А.Б. Грязневич П.А., Большаков О.Г. Бациева С.М., Шумовский Т.А. Очерки истории арабской культуры V-XV вв. – М.: Наука, 1982.
19.Хисматулин А. А. Духовные истоки суфизма // Хисматулин А. А. Суфизм. — СПб.: «Азбука-классика»; «Петербургское востоковедение», 2008. — 192 с.
20.Шиммель А. Мир исламского мистицизма. Пер. с англ. Н.И.Пригариной, А.С.Раппопорт. -М.: Алетейа, Энигма, 2000.
21.Яхин Фәрит. Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. – КаКазан: ТДГИ нәшрияты, 2000. - 266 б.

## Текстлар:

.

18.Абдуль Кадыр Иса. Истина суфизма. Издательский Дом «Ансар», 2004. — 288 с.
19.Абу-ль-Аля аль-Маарри. Избранное. Пер. с араб.. – М.: Изд-во «Художественная литература», 1990.
20.Арабская поэзия средних веков. – М.: Худож. лит., 1975
21.Аравийская старина: Из древней арабской поэзии и прозы. – М.: Наука, 1974.
22.аль-Исфахани, Абу-ль-Фарадж. Книга песен. – М.: Наука, 1980.
23.Бакырган китабы: XII-XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. - 240 б.

24. Баласагунский Юсуф хас-Хаджиб. Наука быть счастливым. - М.: Худ.лит., 1971 - 157 с. -Перевод Наума Гребнева.
25. Баласагуни Юсуф. Благодатное знание. - Л.: Советский писатель, 1990. - 560 с. (Перевод С.Н.Иванова).
26. Гомәр Хәйям. Робагыйлар /Н.Арсланов тәрҗ.. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1986. - 143 б.
27. Джами. Саламан и Абсаль. - Душанбе: Ирфон, 1967. - 122 с.
28. Джами Абдуррахман. Лирика. - М. - СПб.: Диля, 2001. - 320 с.
29. Ибн аль-Араби. Мекканские откровения (Аль-Футухат аль-Маккийа). СПб., 1995. — 283 с.
30. Из классической арабской поэзии. Пер, с араб. С.В. Шервинского; Вступ. ст., примеч., подстрочный пер. И.М. Фильштинского. – М: Худож. лит., 1979.
31. Илһамнар чишмәсе. Дөнья шигьриятеннән. Әхмәт Исхак тәрҗемәләре.- Казан.:Тат.кит.нәшр., 1985. - 344 б.
32. Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. - Казан: Тат.кит.нәшр., 1989. - 221 б.
33. Литература народов СССР. Составитель Л.И.Климович. Часть первая (азерб, таджик., туркмен.лит.). - М.: Просвещение, 1971. - 520 с.
34. Навои Алишер. Лирика. - М. - СПб.: Диля, 2000. - 320 с.
35. Навои Алишер. Фархад и Ширин. - Ташкент: Изд-во лит. и искусства им. Гафура Гуляма, 1985. - 351 с. (Перевод Льва Пеньковского).
36. Навои Алишер. Лейли и Меджнун. - Ташкент: Худ.лит., 1957. - 176 с. (Перевод Семена Липкина).
37. Нәваи Низаметдин Галишер. Фәрһад һәм Ширин // Мирас. - 2002. - №10-12; 2003.- №1-12; 2004. № 1-4.
38. Низами Гянджеви. Собр соч. В пяти томах. Лирика. Сокровищница тайн. - М.: Худ.лит., 1985. - Том первый. - 302 с.
39. Низами Гянджеви. Хосров и Ширин. - М.: Худ.лит., 1985. - Том второй. - 478 с.

40.Низами Гянджеви. Лейли Меджнун. - М.: Худ.лит., 1986. - Том третий. - 366 с.
41. Низами Гянджеви. Семь красавиц. - М.: Худ.лит., 1986. Том четвертый. - 366 с.
42.Низами Гянджеви. Искандер-наме в двух книгах. - М.: Худ.лит., 1986. - Том пятый. - 782 с.
43.Физули. Лирика. - Баку: Язычы, 1985. - 77 с.
44. Руми Мавляна Джалалетдин. Избранные рассказы из "Маснави" / М. Дж. Руми ; канонич. ред. А. Хабибуллин ; лит. ред. С. Хабибуллина ; пер. А. Урманов. - М. : Изд. группа САД, 2010. - 171 с.
45.Саади. Гулистан. - М.: Худ.лит., 1957. - 322 с.
46.Саади. Бустан.Лирика. - М.:Худ.лит., 1962. - 527 с.
47.Фирдәүси Әбелкасыйм. Шаһнамә / Мәсгуд Гайнетдин тәрҗемәсе.- Казан: Тат.кит.нәшр., 2003. – 231 б.
48.Хафиз Шамсиддин. Лирика. - СПб:Диля, 2000. - 320 с.
49.Шейх Назим Аль Хаккани. Океаны милости. Полирование зеркала сердца. Изд-во «Старклайт», 2012. — 402 с.

## Интернет ресурслар

http://www.coollib.net

http://www.royallib.ru

http://www.vostlit.info

http://www.az-love.com

http://www.vostlit.info

http://www.azeri-info.com

http://www.turan-info.

http://www.briefly.ru

http://www.obshelit.ru

http://www.sattor.com

http://www.newskif.su

http://www.pero-simurga.ru

http://ru.wikipedia.org

http://www.publ.lib.ru

http://www.sufimovement.ru/library.htm

http://uchebnik-online.com/131/1121.html

http://www.sufi.su

http://arabliterature.ru/

http://ru.wikipedia.org/

http://al--mutanabbi.narod.ru

www.livelib.ru

www.allbest.ru

www.gramotey.com

www.tyurk.ru

Путь суфия - Путь сердца // http://www.sufi.su

Руми Мавляна Джалалетдин. Избранные рассказы из "Маснави" http://www.kitaphane.crimea.ua/ru/rumi-mavlyana-dzhalaletdin-izbrannye-rasskazy-iz-masnavi.html

Джалаледдин Руми http://whoy.ru/blog/43478010439/Dzhalaleddin-Rumi

Насими http://www.opklare.ru/m/nasimi_-_analiz_tvorchestva

Стихи азербайджанских поэтов http://forum.rcmir.com/topic1919743_30

Стихи Насими http://www.stihi.ru/2008/03/01/171

Творчество Саади http://www.people.su/96490

"Гулистан" - "Сад роз”"Саади (на персидском с дословным переводом на русский язык) http://www.russianplanet.ru/filolog/vostok/saadi/

Творчество Хафиза http://mmorpgbb.ru/foegwoeg/

Хафиз Ширази http://fakty-o.ru/Хафиз_Ширази

Хафиз Ширази http://yablor.ru/blogs/

Абдурахман Джами http://www.fway.org/sufism-44/61-2009-03-15-07-23-41/373-2009-03-20-09-40-54.html

Абдурахман Джами http://www.comunicom.ru/home/93-2011-07-30-12-02-12.html

Суфизм. Ступени возвышения http://www.youtube.com/watch?v=dkqA9nUrcTo

http://al--mutanabbi.narod.ru Анализ творчества Аль-Мутанабби

Шидфар Б.Я. Образная система арабской классической литературы (VI–XII вв. // http://www.orientalstudies.ru/eng/images/pdf/b_shidfar_2011.pdf

Словесное искусство древних арабов (VI — середина VII в.) // http://www.textologia.ru

Верования арабов доисламского периода // http://www.azerislam.com/?lngs=rus&cats=40&ids=427

Гибб Х.А.Р. Арабская литература // http://bookitut.ru/Arabskaya-literatura.html

Гумеров И.Г. История арабской литературы // http://tulpar.kpfu.ru/course/view.php?id=107

Арабская культура // http://dic.academic.ru/dic.nsf/bse/64704/(БСЭ)

Доисламская Аравия : религиозный, культурный, политический фон // http://www.ahmerov.com/book_1126_chapter_3_DOISLAMSKAJA_ARAVIJA_religioznyjj,_kulturnyjj,_politicheskijjfon.html (Библиотека Инокентия Ахмерова).

Татьяна Касьянова (Novikovskaya) "Доисламская арабская поэзия" // http://www.litsovet.ru/index.php/material.read?material_id=266203

Рзакулизаде С. Понятие “Ренессанс” и проблема Восточного ренессанса // Закономерности развития восточной философии XIII – XVI вв. (регион

ислама) и проблема Запад-Восток, 1983. // http:// www.livelib.ru ("Сохраняем знания")

Культура в эпоху восточного Ренессанса (IX – XIIвв., XVв.) // http:// www.allbest.ru

Конрад Н.И. Запад и Восток. Статьи, 1969. // http:// www.twirpx.com/ file/ 626803

Рахманалиев Р. Империя тюрков. Великая цивилизация. Мусульманский ренессанс и тюрки // ttp:// www.historylib.org / 54 ("Историческая библиотека")

## Имтихан сораулары

1. Көнчыгыш ренессансы, тарихы, бәхәсләр. Шәрык ренессансының асыл сыйфатлары.

2. Шәрык ренессансының социаль җирлеге, мәдәни үзенчәлекләре, фәлсәфи-эстетик нигезе.

3. Шәрык әдәбиятларындагы төп юнәлешләр. Илаһият һәм кеше фәлсәфәсе.

4. Шәрык әдәбиятында кеше кыйммәте мәсьәләсе.

5. Гарәп әдәбиятындагы җаһилият чоры. Гомуми характеристика.

6. Имрелкайс: тормышы турында легендалар һәм "Мугаллакат"ларының үзенчәлеге.

7. Мөхәммәд пәйгамбәр - мөселман цивилизациясе һәм ислам диненең юлбашчысы.

8. Гарәп әдәбиятындагы ренессанс тарихы.

Әл-Мөтәнәбби һәм гарәп мәдхияләре.

10. Әл-Мәгарринең фәлсәфи лирикасы.

11. Фарсы әдәбиятындагы ренессанс тарихы.

12. Рудаки иҗатындагы яңарыш мотивлары.

13. Фирдәүсинең "Шаһнамә" эпопеясе: язылу тарихы, жанр һәм композиция үзенчәлекләре.

14. Фирдәүсинең "Шаһнамә" поэмасы. Мифологик катлам.

15. "Шаһнамә" поэмасының баһадирлар бүлеге. Рөстәм образы.

16. "Шаһнамә"нең тарихи шәхесләр бүлеге. Маздак, Бәһрәмгүр образлары.

17. Әбугалисина - галим, философ, табиб, шагыйрь.

18. Гомәр Хәйәм иҗатына гомуми сыйфатлама.

19. Г.Хәйәм иҗатында шәраб мотивы.

20. Г.Хәйәм иҗатында гыйсъянчылык мотивлары.

21. Суфыйчылык әдәбиятындагы юнәлешләр. Мәкамнәр, баскычлар.

22. Җәлалетдин Руми иҗаты.

23. Җ.Руминың "Мәснәви" поэмасындагы фәлсәфи карашлар.

24. Нәсими иҗаты. Илаһият һәм инсаният фәлсәфәсе, "хәрефчелек" хәрәкәте.

25. Габдрахман Җәми иҗаты.

26. Г.Җәминең "Сәлмән вә Әбсәл" поэмасындагы платоник карашлар.

27. Г.Җәминең мәхәббәт фәлсәфәсе.

28. Сәгъди Ширази иҗаты.

29. С.Ширазиның "Гөлстан" һәм "Бостан" поэмалары.

30. С.Ширази лирикасында хөр шәхес образы.

31. Хафиз газәлләре.

32. Төрки әдәбиятлардагы ренессанс тарихы.

33. Низами - азәрбәйҗан ренессансының бөек шагыйре.

34. Низаминың "Ләйлә вә Мәҗнүн" поэмасындагы платоник карашлар.

35. Низаминың "Искәндәрнамә" поэмасы: идея- тематик анализ.

36. Низаминың "Җиде гүзәл" поэмасында мәхәббәт фәлсәфәсе.

37. Алишер Нәвои иҗаты.

38. Нәвои иҗатындагы традицион образлар.

39. А.Нәвоинең "Фәрһад вә Ширин" поэмасы: идеяләр дөньясы, проблематикасы, образлар системасы.

40. Мөхәммәт Фөзули иҗаты, аның мәхәббәт фәлсәфәсе.